С (Жик)
А 12

И. АБДУЛЛИН

Йолдызлар атыла

ЛИСТОК СРОКА ВОЗВРАТА

КНИГА ДОЛЖНА БЫТЬ
ВОЗВРАЩЁНА НЕ ПОЗЖЕ
УКАЗАННОГО ЗДЕСЬ СРОКА

Колич. пред. выдач. ....

С (Башк)
А 12

И. Абдуллин

Йолдызлар атыла

ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
Казан 1964

С2²(Баш.)
А12

НБ РБ
0000170714

ҮЗЕМ ТУРЫНДА БЕР АВЫЗ СҮЗ

Минем туган җирем — Башкортстан белән Татарстан чигеннән салмак кына агучы, саф сулы сахра елгасы Ыктан ерак түгел урында — Җирекле дигән авыл.

Җирекледә минем телем ачылды. Җирекледә мин беренче мәртәбә, кулыма каләм алып, пьеса яздым.

Профессиональ театрда куелган беренче пьесам «Ал яулык» дип атала. Менә шул вакыттан бирле (1938 ел) мин язуны ташламадым. Дөрес, бүленүләр, озын-озын тыныш алулар да булды — техникумда уку, армия, сугыш, аннары институт. Белəгемнең һәм йөрәгемнең көченнән килгәнчә унбиш зур күләмле, кырыктан артык бер пәрдәлек пьесалар яздым. «Баҗалар», «Без аерылышмабыз», «Гөлмәрфуга», «Ямьле Агыйдел буйлары», «Вәгъдә онытылмый» пьесалары Татарстан тамашачыларына да таныш.

Әдәби гомеремнең күп өлешен драматургиягә сарыф итсәм дә, минем янә бер яраткан жанрым бар — проза. «Ташка басылган» беренче әсәрем дә хикәя иде. Дистәгә якын хикәяләр һәм повестьлар китабым чыкты. Байтак кына хикәяләрем рус, украин, казах, төркмән һ. б. телләрдә һәм шулай ук чит илләрдә басылгалады.

Әйтергә ярый, хәзер мин гомеремнең июленә килеп җиттем — миңа 42 яшь. Үтелгән юлымның кечкенә отчеты итеп татар укучыларына шушы китабымны тәкъдим итәм. Әгәр гомеремнең августы да бәрәкәтле булса, Сезнең алда янә отчет ясармын әле.

Ибраһим Абдуллин,

Уфа.

79903

Башк. республиканская
БИБЛИОТЕКА
им. Н. К. КРУПСК
98

ЙОЛДЫЗЛАР АТЫЛА

Зәкуан, кулларын чалбар кесәсенә тыгып, сызгыра-сызгыра вахтадан кайтып килә. Төн уртасы булуга карамастан, ул урам яңгыратып җырлар да иде, ояла шул! Тавышы моңлы түгел. Их, табигать, төсне-буйны җәлләмәгәнсең, акылдан мәхрүм итмәгәнсең, ә менә моңлы тавышны нигәдер кызгангансың. Юмарт та һәм саран да син, табигать. Ә шулай да аның табигатькә үпкәсе юк. Язмышына да зарланмый ул. Дөрес, Зәкуанның гомере чуерташлардан гамьсез сикерә-сикерә аккан чишмәнеке кебек җиңел булмады. Соң ата-анасыз үскән баланың гомере кайчан җиңел була инде...

Дөрес, балалар йортында аның тамагы тук, өсте бөтен булды, какмадылар, сукмадылар. Тик Зәкуан бер генә нәрсәдән, бердәнбер нәрсәдән мәхрүм иде — ата-ананың мәхәббәтле күзләрен, җылы сүзләрен, йомшак кулларын белми үсте ул.

Сугыш башланыр алдыннан аның атасы Литвада хезмәт итә иде. Петлицаларында ике шпал, җиңнәрендә йолдыз иде аның. Батальонный комиссар. Кызыл Байрак һәм Кызыл Йолдыз орденнары да бар иде Харис Локмановның. Берсен Хасан сугышында, икенчесен Халхингол кампаниясендә алган.

Озын, мәһабәт кеше иде аның атасы. Күрәсең, холкы да яхшы булгандыр һәм аны яратканнардыр. Һәр ял саен аларның кечкенә ике бүлмәле квартиралары офицерлар белән шыгрым тулы була торган иде.

Нинди шаулы, күңелле үтә иде ул кичләр. Менә хәзер дә, күзне чытырдатып йомсаң, бөтенесе күз алдына килеп баса. Әйтерсең, кичә кич кенә булган хәл.

Кунаклар җырлыйлар, көлешәләр, алгы якка чыгып, парлашып бииләр, бәхәсләшәләр. Ә аның атасы, я чем-кара мыегын борып, яңагына таянып, елмаеп утыра, я искәрмәстән нindидер сүз әйтә. Кунаклар шаркылдап көлешәләр. Азак ул сикереп тора. Кунаклар шым була. Атасы уң кулын суза, сул кулын күкрәге янына куя да, үзе көйләп, әкрен генә биеп китә. Кунаклар кул чаба башлый. «Перовский» дип атала ул бию. Атасының иң яраткан, бәлки, бердәнбер биюе булгандыр ул «Перовский». Бу биюдә дәрт тә, көч тә, горурлык та бар. Ә әнисе,— ял көнендә дә, кино-театрга барганда да яшел гимнастеркасын, зәңгәр юбкасын һәм кечкенә генә хром итеген, башка хәрби врачлар кебек, ефәк күлмәккә, биек үкчәле туфлигә алмаштырмаучы әнисе — кунаклар барында аз гына да утырып хәл җыймый иде. Кайчак, офицерлар аңа булыша башласа, ул: «Сез — кунаклар, димәк, хуҗаның ишәкләре. Урыннарыгызга шагом-марш»,— дип команда бирә торган иде. Ә кайчак аның әнисе, сызгырырга яратучы тәбәнәк, юан майор бүләк иткән алтын рюмкага кызыл вино сала да югары күтәрә. Бүлмә шым була.

Дан приказ ему на запад,
Ей в другую сторону;
Уходили комсомольцы
На гражданскую войну...

Зәкуанның әнисенә кунаклар да кушыла. Ә әнисе, рюмканы буфетка куеп, иpләп кенә кухняга чыгып китә. Аны беркем искә алмый. Чөнки бүлмәдә җыр гына хуҗа.

Уходили, расставались,
Покидая тихий край,
Ты мне что-нибудь, родная,
На прощанье пожелай...

Зәкуан да җырга кушыла. Бераздан өстәлгә я пилмән, я бәлеш кертеп куела. Кунаклар аның әнисен, аның оста кулларын мактый-мактый ашыйлар. Әнисе исә буфетка сөяләдә, кулларын кушырып, ишетелер-ишетелмәслек итеп «Ҭаштугай»ны сыздыра. Кемдер ашавыннан туктап, аның әнисе ягына борыла, урындыгының аркасына йодрыкларын куеп, ияген тери, кемдер башын артка түнкәйтеп, күзләрен йома, кемдер учлары белән маңгаен каплый. Ашау онытыла. Сүзләр бүленә. Матур тынлык урнаша. Әйтерсең, кешеләр үзләренең яшәүләрен дә онытталар. Бүлмәдә ерак Уралдан килгән моң гына яши.

Ялан гына җирнең кәккүге юк,
Үз Уралкаема кайтаем...

Кайта алмадың, әнкәй... кайталмадың шул, эткәй... Сугышның беренче көнендә үк аның әнисе эшли торган госпитальгә фашистлар бомба ташладылар. Ә этисе таң белән казармага китте дә башка кайтмады.

Башта Зәкуан дәһшәтнең коточкыч икәнен аңламады. Тәрәзә төбенә утырып:

Дан приказ ему на запад,
Ей в другую сторону...—

дип җырлап утырды. Ачыкты. Җылыйсы килде. Түзде. «Ул бит комиссар малае!» Зәкуан берәр нәрсәдән шикләнеп-икеләнеп торса, шулай дип гайрәтләндерә торган иде аны әтисе. Зәкуан әтисенең пилоткасын киеп, әнисенең гимнастеркасын ябынып, диванга ятып йоклады. Икенче көнне аны өченче катта торучы Анита әби үзләренә алып менде. Ашатты-эчерде һәм төнлә ниндидер хуторга илтеп куйды. Башкорт Зәкуан литовец Казиска әйләнде. Бу сергә ул байтак вакыт үткәч кенә төшенде. Әгәр фашистлар аның комиссар малае икәнен белсәләр, я атып үтерерләр, я Германиягә озатырлар иде. Литваны фашистлардан азат иткәч, Зәкуанны Башкортстанга балалар йортына җибәрделәр. Ләкин ул башкортча бер авыз сүз дә белми иде. Туган тел булганга микән, әллә аның телләр өйрәнергә сәләте бармы, Зәкуан башкортча сөйләшергә бик тиз өйрәнде һәм укырга да башкорт мәктәбенә керде. Ә менә кем булырга: әтисе кебек, офицермы, әллә врачмы? Унынчыны бетергәнче ул эзләнде, икеләнде һәм кинәт, һич уйламаганда, нефтьче булып китте. Хәер, «Нигә һич уйламаганда?» Башкортстан — нефть республикасы. Нефть җир астыннан чыккан хәзинәләрнең иң асылы һәм кирәге. Ике йөздән артык продукция алына нефтьтән! Ул я яктылыкка әйләнә, я капрон булып, хатын-

кызларның тәненә ята, я моторларга җан бирә, я каучук кыяфәтенә керә, теләсә тимерне, теләсә агачны алмаштыра, бодай үстерә, терлекләрне симертә... Файдалы казылмаларның патшасы ул нефть... Шулай булгач, безнең эздән китмәде бердәнберебез дип ачуланма, әти, үпкәләмә, әни...

Ул инженер булмакчы иде дә, бер балл җитмәде, институтка керә алмады. Ләкин бер балл аның дәртен сүндерә алмады, ул бораулаучылар курсына китте. Ул үзен җиңел тормышка хәзерләмәде һәм андый тормышны белмәде дә. Ләкин буровойдагы эш аны шүрләтте. Кышларын үзәккә үтәрлек салкын, җәйләрен чыдый алмаслык эссе, өстәвенә өстең-башың мазутка бата, нефть исеннән сару кайный, баш әйләнә. Ах кыйммәткә төшәсең икән, «кара алтын». Әллә... үзең теләп армиягә китәргә дә, хәрби училищега керергәме? Бу әтисенең васыятен үтәү дә булыр иде... Әгәр ул исән булса, улының бу адымын хуплар идеме? Юк. Башлаган эшен ярты юлда ташлаучыны яратмагандыр ул. Ярты юлдан кире борыла торган булса, аны полкташлары шундый яратмаслар иде. Әтиеңнең истәлегенә чүп төшермә, Зәкуан. Син бит комиссар малае, комсомолец... Һәм Зәкуан үзен-үзе җиңде. Нефть исенә дә күнекте, кышкы-җәйге чилләләргә дә гадәтләнде. Алай гынамы, Зәкуан бораулау эшенең ямен, тәмен аңлый башлады. Йөзләгән металл вышкалар арасында ул үзләренекен бик тиз эзләп таба һәм нигәдер алар вышкасы биегрәк тә, ягымлырак та тоела. Ә турбобур үз җаена эшләгәндә?.. Нинди

музыка туган кебек тоела һәм Зәкуан әнисенең яраткан җырын сызгырырга тотына. Сугыштан соңгы яшьләрнең күбесе бу җырны юньләп белми дә — һәр заманның үз моңы, үз җыры була бит, ә Зәкуан өчен аннан да ягымлырак һәм кадерлерәк нәрсә юк. Әнисенең бердәнбер истәлеге ул. Чөнки Зәкуан төсе-башы белән хас этисе, әнисе... үзенең матурлыгын, талантын кызына, Зәкуанның карендәшенә, бирергә теләгәндер дә, өлгерәлмәде, сугыш аларның гомерләрен һәм хыялларын кинәт өзде.

Беркайчан да шыңшымаучы, һәрвакыт көр һәм ачык йөзле Зәкуанга бригадада бик тизияләштеләр. Яшьрәкләр аңа ошатыбрак йөрергә, аныңчарак сөйләшергә тырыштылар, ә озын гәүдәле, озынча йөзле, кара чәчле һәм зәп-зәңгәр күзле мастер Шәфиев аны бөтен бригада алдында: «Зәкуан Локманов— минем уң кулым, ягъни мәсәлән, беренче замым»,— дип атады.

Һәм менә бер атнадан, 613 нче скважинаны очлагач, аларга «коммунистик хезмәт бригадасы» исемен кушачаклар. Өченче бораулау конторасында ике бригада бу мактаулы һәм җаваплы исемне яулап алды инде. Алар бригадасы да, бәлки, яз көне үк бу исемгә лаек булыр иде дә, верховой Янтурин эшне бозды. Буровойда, вахтада, ул үзен менә дигән тота. Кирәк булса, «ыһ» та итми рәттән ике смена эшли. Иптәшлеккә дисәң, җанын фида кылырга хәзер, тик... бутылка эченә бикләнгән «яшел елан»ны күрсә, жеби дә төшә. Башта аны үгетләп тә, әрләп тә карадылар, үзен аракы шешәсенә

утыртып стена газетасына да төшерделәр — ярдәм итмәде. Шуннан бригада киңәшмәгә җыелды: ни эшләргә? Бер эче киткән сыер бөтен көтүне пычрата бит.

— Җәмәгать,— диде өлкән эшче «Озын мыек» Шәяхмәтов.— Һәркемнең бер китек ягы була. Без дә фирештә түгел. Ул эш вакытында эчми, эчсә, тавышланмый-шауламый, кулларын бот арасына кыстыра да ята да йоклый. Ни эшлисең, каны агуланган инде. Минем кара акылымча, Янтуринның бу гыйлләсе эшкә мишәйт итә торган нәстә түгел. Шулай булгач, без...

Аңа сөйләп бетерергә ирек бирмәделәр. Кызу канлылыгы өчен «шарикоподшипник» кушаматы алган моторист Витька Речкин аны кискен бүлде.

— Утыр, утыр, Шаяхмәтов. Синеңчә, коммунистик хезмәт ударнигы исемен алуы сабан туе! Синеңчә, процентың шәп булса, җитте? Шаярма. Коммунистик... димәк, кеше коммунистларча... коммунизмдагыча эшләргә, яшәргә, ял итәргә тиеш. Ә Янтурин әле коммунизмда яшәргә хәзер түгел. Минем тәкъдим: бер ай сынау срогы. Төзәлсә төзәлә, төзәлмәсә — выжт! Эзе дә булмасын. Ул бала түгел. Үзенә үпкәләсен.

— Беттеңме,— диде мастер, һәрвакыттагы кебек авызыннан трубкасын алмый.— Бетсәң, тыңла. Мин Янтуринны якламыйм һәм акламыйм. Һәм синең тәкъдимеңә дә кушылам — бер ай срок. Ләкин, коммунизмда яшәүче (яки яшәячәк) кешеләрчә уйламыйсың, Виктор. Коммунизмда бөтен коллектив бер кеше өчен, ә бер кеше бөтен коллектив

өчен янарга һәм җавап бирергә тиеш. Без Янтурин өчен бөтен бригада белән янабыз. Ә син нигә безнең өчен янмыйсың, Янтурин? Теләмисеңме, булдыра алмыйсыңмы? Сөйлә. Аңлат.

— Ә ул дөньяга янарга түгел, чи утын кебек, пыскып ятарга килгән,— дип кычкырды иң артта тәмәке тартып, тешләре аркылы төкереп утырган яшь эшче.

— Шәйнур!— диде аңа мастер.— Я, Янтурин, телең бармы?

— Юк, йоткан,— дип тагы кычкырды Шәйнур һәм Янтурин каршысына килеп басты.

— Алкоголикмы син, түгелме?

— Шәйнур...

— Юк, ул ачык әйтсен: алкоголикмы, түгелме? Алкоголик булса, аны агитация дә, выговор да, хәтта төрмә дә төзәтә алмаячак. Әнә психбольница. Кер. Дәвалан. Безгә канителең тимәс. Я, әйт, алкоголикмы, түгелме? Түгел булсаң, сөйлә. Сүз бир.

Янтурин сүз бирде һәм сүзендә торды. Менә өч ай инде ул аракыны иснәп тә карамый. Хәтта туй-бәйрәмнәрдә дә нарзан, боржом эчеп утыра. Анысы бик ярап беткән эш түгел дә түгеллеген, нишлисең, үз хәлен үзе беләдер инде.

Шулай итеп, бер атнадан аларның кырык бер метрлы металл вышкасы өстендә кызыл йолдыз кабыначак. Элегрәк тә шундый тәртип булган — бригада планын арттырып үтәсә, вышка түбәсенә кызыл йолдыз кабызганнар. Ни өчендер соңгы елларда бу гүзәл гадәт онытылган. Ә хәзер ул йолдызга ия

булу өчен җирне бораулау нормасын гына түгел, ә кешелек нормаларының бөтенесен дә үтәргә кирәк. Кыскасы, кеше «коммунистик өлгерү аттестатын» ала. Бөек һәм... җаваплы исем. Аны яулап алуга караганда да, тузан-керсез саклый белергә кирәк. «Сакларбыз, әти. Саклармын, әни...» Ул еш кына шулай ата-анасы белән сөйләшә, киңәшләшә, шатлыгын бүлешә, кайгысын уртаклаша.

Әллә Нәркәсне чакырып, шатлыкның яртысын аңа да бирергәме? Югыйсә берүземә артык күп, күкрәккә сыймый. Юк, борчымыйм инде. Йоклыйдыр. Бәлки йокламыйдыр. Ул бит чигү чигәргә ярата. Их, нинди матур чигә ул... Магазиндагы әзер рәсемнәрне сатып алып, алар өстеннән җеп йөгертеп чыкмый, ә үзе иҗат итә. Аның чиккәнен тыныч кына карап торып булмый. Ул, художник кебек, йотылып, онытылып эшли — әйтерсең, бармакларыннан җеп урынына җыр агыла. Яратам мин сине, Нәркәс... Син бит минем бер генәм. Минем башка беркемем юк. Кайчан мине бәхетле итәрсең икән?.. Мәңгегә. Әллә, урау булса да, алар урамыннан үтим микән? Бәлки йокламыйдыр. Бәлки авыз эченнән генә көйли-көйли чигү чигеп утырадыр.

Кинәт «Айй!!» дигән кызлар тавышы ишетелде. Зәкуан тавыш ишетелгән якка ташланмакчы иде, әле генә атылган йолдызның чыбыркы кебек утлы эзен күреп калды да тынычланып, елмайды.

— Наил, Наил... тагын атылды,— диде баягы ярсу тавыш. «Ә шулай да табигатьнең иң гүзәл ае май түгел, август»,— дип уйла-

ды Зәкуан һәм, үзе дә сизми, Нәркәсләр урамына борылды. «Августта җиләк-җимеш пешә, иген өлгерә. Августта йолдызлар атыла. Ә нигә августта йолдызлар еш атыла икән?..» Зәкуан җылы, каракучкыл зәңгәр күккә карый. Төпсез ераклыкта, яктылык миллиард елларда гына килеп җитә торган ераклыкта, томанланып төшсыман «каз юлы» үтә... Анда бөтенләй икенче дөнья, икенче галәм. Чын булса, анда көннәр дә, еллар да чиксез озын ди. Мәсәлән, андагы җитмеш ел, җиде йөз елга тигез ди. Кызык һәм акыл җитмәслек гаҗәп...

Зәкуан, туктап, борылып-борылып күккә карый. Караган саен, күк яңара, матурая төсле тоела. Күк... Бер караганда җылы, икенче караганда салкын, бер караганда, кулны сузсаң тиярлек якын, икенче караганда, хыял җитмәслек ерак. Туган якның җире генә түгел, күге дә башкача... Куенын биргән Литва да аның йөрәгенә якын, әмма анда күк бөтенләй икенче төрле... Җидегән йолдыз да, хәтта ай да Уралдагыча түгел кебек. Әйе, һәр халыкның үз җире генә түгел, үз күге дә бар. Гоголь Украина күген мактап җырлаган, Илья Чавчавадзе грузин күген өзелеп яраткан... Ә бораулаучы Зәкуан Урал күгенә гашыйк.

Ул Девон урамыннан борыла, Нәркәсләр ишек алдына керә. Ишек алды тын. Юкәләр, каеннар һәм чаганнар йокыга талган. Биш катлы йорт та йоклый. Тик бер-ике тәрәзәдә генә ут яна. Ә Нәркәсләр тәрәзәсендә... Икенче кат, почмактан өченче, дүртенче... бишенче тәрәзәдә, кухняда, ут бар. Кемнең-

дер ашыкмый гына кыймылдаганы күренә. Кем икән? Дәү әнисе булмас. Ул күптән йоклыйдыр. Әтисе... Сәгать бердә ул нишләп кухняда йөрсен. Аннан шәүлә дә озын түгел. Димәк, я Нәркәс, я әнисе. Ни булса була... Ул, бала-чага уйный торган таучыктан ком алып, тәрәзәгә сибә дә агач күләгәсенә кача. Тәрәзә пәрдәсенең почмагы шунда ук күтәрелә һәм кулына үтүк тоткан, өстенә халат кигән Нәркәс күренә. Зәкуан, тиз генә күләгәдән чыгып, Нәркәскә кул болгый. Нәркәс аны күрми. Пәрдәнең почмагы төшә. Зәкуан тагын ком сибә. Нәркәс, пәрдәне сыпырып җибәреп, тәрәзәгә ябышырдай булып карый һәм аны күрә. Зәкуан биш бармагын күрсәтә («Биш кенә минутка») һәм урамга чакыра. Нәркәс, учын яңагына куеп, йокларга вакыт, дигәнне аңлата һәм бармакларын тибрәтеп «хуш» ди. Зәкуан үзенекен итә, күккә күрсәтә. Нәркәс аңламый, тәрәзә тупсасына менеп, форточкадан башын тыга.

— Ни бар?— ди Нәркәс, пышылдап.

— Йолдызлар атыла,— ди Зәкуан, пышылдап.

— Алайса, хәзер!

Ул идәнгә сикереп төшә. Зәкуан иркен сулый да ком таучык янына барып утыра. Башта ни ясарга белми уйланып тора. Шуннан кинәт ике куллап юл сала, шырпыларны тезеп, рельслар суза, шырпы тартмасын паровоз итә. Ә вагоннар?.. Ярый, маневрировать итеп йөрүче паровоз ди. Ну, хәерле юл! Тукта. Ә семафор? Ул, өзелеп төшкән юкә яфрагын урталайга бөкләп, чыбыкка кигезә. Менә хәзер семафор да булды. Ту-туутт!..

Юл ачык... Паровоз юлга чыкты. «Кызык, кайчан аның да шушы комда уйнарлык баласы булыр икән? Нәркәскә «сүз салып» карасаң инде?.. Юк, иртәрәк әле, Зәкуан. Янә берәр... Ярты ел көтәргә кирәк.

Ә нигә иртә булсын? Аларның танышуына унынчы августта, ягъни иртәгәдән соңга, нәкъ бер ел була. Бер ел... Ә кичә булган хәл кебек бөтенесе дә күз алдында.

...Зәкуан соңгы сеанстан кинодан кайтып килә иде. Картина аны бик нык ярсытты. Ул, кеше күрмәгәндә, атылып чыккан яшьләрен берничә тапкыр бармак очлары белән сөртеп алды. Хәер, яшереп сөртмәсәң дә гарьлек түгел иде. Аның сул як күршесе — чигәләре агарган майор балаларча елап утырды, ә Ванюша автомашинада барганда Андрей Соколовның муенына сарылып: «Папа, папочка, это ты? Я тебя нашел!» дип кычкыргач, залда берьюлы авыр көрсенү ишетелде. Кинәт йөрәк тибүдән туктады, ә башны, әйтерсең, ике авыр пресска салып кыстылар — чигәләргә көчле кан басымы ургылды, тамакларга таш утырды. Зал олы һәм кече Соколовның яңадан табылган авыр бәхетенә куанып елады. Картина беткәч, халык бераз урыннарыннан кузгалмый торды. Беренче булып, Зәкуанның сул як күршесе, чигә чәчләре агарган майор торды һәм, тамашачылар, нигәдер аңа борылып карадылар. Майор җилкәләрен турайтты, башын горур күтәрде һәм ягымлы елмайды. Бу әдәпле елмаюда Соколовның яңадан табылган бәхетенә канәгатьләнү дә, нәфрәтне җиңгән мәхәббәт тә бар иде.

«Бирелмәскә. Бөгелмәскә!..» Әнә шул сүзләрне күңелдән тугылап, сызгыра-сызгыра кайтып килә иде Зәкуан. Август төне җылы, ягымлы һәм серле иде. Ә йөрәк әле һаман тынычлана алмый. Зәкуан кинәт «Ай-й!!» дигән кызлар тавышы ишетте. Ул тавыш килгән якка ташланды һәм... күккә сокланып торучы ике кызны күрде.

— Қайда, кем? Хулиганнар шаярамы әллә?— дип сорады ул, як-ягына каранып.

Қара чәчен малайларча кистергән кыз:

— Юк, күк шаяра,— диде күгәрчендәй гөрелдәп.— Йолдызлар атыла. Без Веруся белән атылган йолдызларны санап, төне буе йөрергә булдык. Қем күбрәк күрә, шул алданрак кияүгә чыга.

Туфлиенең башы белән тротуарга нидер язып торган сары чәчле Веруся «Қара чәч»нең беләгеннән тотты.

— Қитче... я кешене ышандырырсың.

— Сөйләү минем эш, ышану — аныкы.

— Ә сезгә берәр счетовод кирәкмиме?— диде Зәкуан да шаяртып.

— Штатта каралмаган. Пока!— диде «Қара чәч».

— Ә мин хезмәт хакы алмый гына эшләргә әзермен,— Зәкуанга «Қара чәч»нең ачык һәм хәйләсез сөйләшүе (Ай-һай, сөйләшүе генә микән!) ошады.— Мин бер тиен алмый эшләргә әзермен.

— Ә йөзгә чаклы саный беләсезме?— диде Веруся башын күтәрми, туфли очы белән үзенә генә билгеле сүзне язып.

— Беләм. Хәтта меңгә чаклы. Санаиммы? Бер, ике, өч, дүрт...

— Алабызмы үзен, Веруся?— диде «Кара чәч», Зәкуанга серле елмаеп, аскы иренен тешләп.

— Әллә инде. Булмаса, алыйк.

Зәкуан иркен сулап куйды. Аңа рәхәт тә, җиңел дә булып китте. Әйтерсең, ул ниндидер зур сынау үтте.

— Алайса, эшне «а»дан башлыйк,— дип ул кулын сузды.— Минем исемем...

— Зәкуан, фамилиягез — Локманов,— диде көләргә дә, сөйләшергә дә яратучы кара чәчле, зур кара күзле кыз. Аның өстендә эре кызыл чәчәкле, киң итәкле җиңсез ситсы күлмәк, яланаякларында кызыл «босоножка» иде. Кояшта янган матур, көчле беләкләре кызның спорт яки «кара эш» белән дус булуы турында сөйлиләр. Хәер, ул эшләргә генә түгел, үзен карарга да яратадыр. Тырнакларын шактый озын итеп җиткергән һәм каракучкыл кызыл лакка буяган. Кечкенә генә матур колакларында эләктереп куела торган түгәрәк кызыл алкалар. Озын, көчле муенында арзанлы, ләкин бик нәфис кызыл төймә. Һәр нәрсә үз урынында һәм бер генә нәрсә дә артык түгел. Ә Веруся, күрәсең, авылдан күптән түгел генә килгәндер. Ул әле сары чәчен дә кистерергә өлгермәгән. Зур толымын түгәрәкләп урап куйган, зәңгәр штапель күлмәгенең модасы да искергән.

— Нигә шаккаттыгыз?— диде «Кара чәч», аның сүзсез аптырап торуына гаҗәпләнеп һәм Зәкуанның күзләренә туры, кыю карап. Бу караш (их шул кызлар карашы!) аны бөтенләй камырга, юк, көлгә әйләндерде.

— Ы-ы... Ә-ә... Ә сез минем исем-фамилиямне кайдан беләсез, иптәш?— диде Зәкуан, тотлыга-тотлыга.

«Кара чәч» күгәрчендәй гөрелдәде.

— Мин барысын да беләм.

— Барысын да? Каян?

— Анысы — сер. Хәер, сер түгел. Мин — фирештә. Кичә генә күктән төштем. Йолдыз булып атылып.

— Фирештә?.. Әйе, сез фирештә. Сөйләгез, иптәш... фирештә.— Көчкә Зәкуанга кыюлык керде, ул кулын сузды.

— Ә мин цыганка түгел, фирештә, Зәкуан Локманов.— «Кара чәч» шаярып аның учына сугып алды.— Мин сезнең учтагы сызыкларга карап түгел, күктәге йолдызларга һәм сезнең күзләрегезгә карап анкетагызны тутырам.— «Кара чәч» аның күзләренә карап алды да башын күтәрде.— Яшегез егерме өчтә. Буйдак. Ата-анагыз юк. Сугышның беренче көнендә үк һәлак булганнар. Белемегез — ун класс. Профессиягез — бораулаучы. Эшләгән җирегез... Өченче бораулау конторасы, скважинагызның номеры — 613. Тирәнлеге 1750 метр. Тагын... Бригадирыгызның фамилиясе Ш-Ш-Шәфиев. «Коммунистик хезмәт бригадасы» исеме алу өчен көрәшәсез. Яхшы эшләсәгез дә, кайберәүләрнең нәфесенә хуҗа булалмавы аркасында, сезгә бу исемне бирми килгәннәр. Соңгы мәгълуматларга караганда, озакламый сезнең вышкагыз өстендә дә йолдыз калкачак. Я, кайда хаталандым яки алдадым?—«Кара чәч» Зәкуанның кара күзләренә серле елмаеп карады һәм тагын ялкындай ялмап алды.

Башк. республиканская БИБЛИОТЕКА им. Н. К. КРУПСКОЙ
7993

— Сез бөтенесен дә... энәсеннән җебенә чаклы дөрес сөйләдегез, иптәш...

— Ә сез минем фирештәлегемә ышанмаска иткән идегез.

— Хәзер ышандым инде. Тик...

— Нигә без монда почмак саклап торабыз әле? Киттек.—«Кара чәч» белән Веруся аны уртага алды.— Башта Девон урамыннан барабыз, аннан Ык буена төшәбез. Я, я, нәрсә «тик»?

Зәкуан, «счетовод» буларак, күзен күктән алмады.

— Тик үзегез хакында ләм-мим.

— Фирештәләргә үзләре хакында сөйләргә ярамый. Ходайның шундый распо-ряжение-се бар.—«Кара чәч» сызгыра башлады.

— Исемегез дә серме?

— Исемем дә сер.

— Алайса сезгә ничек дәшергә?

— Икс.

— Күктә математиканы үтәләрмени?

— Күктә югары математиканы да, кулинарияне дә үтәләр.— Табигать сәгатьләре — әтәчләр йокылы тавыш белән кычкыра башлагач, алар хушлаштылар. Зәкуан кызларны Уфа филармониясенең биючеләрен карарга концертка чакырды. «Кара чәч» икесе өчен дә җавап бирде: «Төп-төгәл сигездә парк капкасы төбендә булырбыз. Бер минутка соңласагыз да көтмибез. Бер минут кайчак бер гомер ул».

Алар, кулларын дусларча кысышып, аерылыштылар.

— Тыныч йокы, Зәкуан Локманов,

— Тыныч йокы, иптәш...
— Икс.
— Икс...

Кызлар җитәкләшеп, кулларын селти-селти кайтып киттеләр, ә Зәкуан, телефон баганасына сөялеп, күздән югалганчы аларны озатып калды. «Нигә ул исемен яшерә? Шаярамы, кыланамы, әллә исеме бик борынгыча булуыннан ояламы? Ә ул аны кайдан белә? Хәтта квартирасын да. Гаҗәп. Кем ул? Кайда эшли ул? Зәкуанның Октябрьскида өч ел эшләп аны беркайчан да күргәне юк.

Зәкуан, дүртенче катка, ашыгып, ике баскычны берьюлы атлый-атлый менде дә, ишек төбендә тирән итеп сулады, үз ачкычы белән ишекне ачты, һәм, күршеләрен уятмас өчен, ботинкаларын кулына тотып, бүлмәсенә үтте. «Кызык, концертка килерләр микән? Чишенми генә диванга ятты. Кинәт түшәм зәңгәр август төненә әйләнде, кайдандыр йолдызлар балкып чыкты, абажур-ай калыкты. Зәкуан күзләрен йомды. Колакка «Кара чәч»нең күгәрчендәй гөрелдәп көлүе ишетелде.

— Икс... Икс... килер микән, әллә...— Ул елмайган килеш йоклап китте. Нинди төшләр күргәндер ул бу төнне, белүе кыен. Хәер, гашыйкларның йокысы тынгысыз, төшләре буталчык була бит. Әйе, әйе, гашыйкларның. Чөнки «Кара чәч» аның канына «мәхәббәт агуы» салырга өлгергән иде инде.

Икенче көнне, вахта беткәч, Зәкуан моторист Витька Речкин белән бергә кайтты.

— Витя,— диде ул бик җитди.— Төп-тө-

гәл сигезгә (кара, малай, бер генә минутка соңласаң да үкенерсең, бер минут кайчак бер гомер ул) парк капка төбенә кил. Қасса янында тор. Юньләбрәк киен. Бер сорау да бирмә, кичен үзең аңларсың.

Витя, сорамаса да, аңлады һәм сигезенче яртыда инде парк капка төбендә «ләлә-ләллләл» дип авыз эченнән көйләп йөри иде.

Витя белән Веруся бер-берсенә бик тиз ошаштылар һәм концертның беткәнен дә көтеп тормый, антракттан соң, каядыр чыгып киттеләр. Алар ике атна буе көн саен очраштылар, көненә икешәр сеанс кино карадылар да, юктан гына үпкәләшеп, аерылыштылар һәм башка күрешмәделәр. Ә Зәкуаннарның дуслыгы «үтә кызыл» булмады. Хәтта «Қара чәч» озак кына үзенең исемен дә әйтмәде: Икс, Икс.

Шулай, бакчада, Зәкуан «Қара чәч»кә «Икс, киттек!» дип дәшкәч, скәмьядә утыручылар шаркылдап көлделәр.

— Икс... кс-ксс...

«Қара чәч» бу сүзгә колак салмады, ә Зәкуан оялды, скәмьядә утыручы озын чәчле малайлар һәм кыска чәчле кызлар янына барып, чак әче сүз әйтмәде, «Қара чәч» кенә тыйды.

— Төкер. Эт өрер, бүре йөрер.

— Икс, ә шулай да син ни исемле?

— Бел.

— Яхшы. Тик син баш хәрефен генә әйт.

— Ә-ә-ә... Акылың алтын икән.

— Әллә исемеңне беркайчан да әйтергә исәбең юк?

— Әллә, бәлки...
— Аңламыйм.
— Ә син Маяковскийны яратасыңмы?
— Укыштырам. Кыю шагыйрь.
— Әнә шул шагыйрь болай дигән: «Тот, кто понятен с первого раза, тот, по-моему, просто глуп...»
— Һәр атаклы кешенең сүзен законга әйләндерергә ярамый, Икс. Беренче күрешүдә үк аңлашылган кешеләр дә яхшы булгалый ул...
— Бәлки. Бәхәсләшмим.
— Ә шулай да...
— Үзең бел.
— Һәм беләчәкмен.
— Бел дим шул.
Беркөнне Зәкуан ике йөздән артык кызлар исеме язып алып килде.
«Кара чәч» исемлекне укып чыкты да, башын чайкады: «Юк».
Зәкуан аптырады: я ул алдаша, я...
— Менә нәрсә, әгәр бүген дә исемегезне әйтмәсәгез, сезнең белән ияреп керәм дә, әниегездән сорыйм.
— Әйдә,— диде кинәт Икс, аны җитәкләп.
— Кая?
— Безгә.
— Туктагыз әле... Мин бит...
— Әйткән сүз — аткан ук. Киттек!— Ул, Зәкуанны җилтерәтеп, икенче катка алып менде.— Уфф... өч рәт рәттән тирән итеп тын ал. Булдымы? Менә, кара дерматин белән тышланган безнең ишек. 31. Ятла. Әти звонокка бер баса, әни — ике рәт, мин — өч.

Ә дәү әни сирәк чыга, чыкса да, кнопкага басмый, «я электрның зәхмәте кагылыр» дип курка. Карт инде ул. Бер аягы җирдә, икенчесе гүрдә. Сиксән алтыда. Ашый да намаз укый, намаз укый да йоклый. Бөтен эше шул. Оҗмахка керергә тырыша. Ә син, Зәкуан Локманов, минем кебек өч рәт төртерсең. Сораулар бармы? Булмаса, башыңны күтәр, елмай, йөзеңә акыллы караш чыгар...

Зәкуан Иксның звонокка сузылган бeләгеннән тотты.

— Кергәч тә мин сиңа Икс дип дәшермениме?

— Юк, Нәркәс, диген.

— Нәркәс?

— Исең китмәсен. Бездә гел гөл дә чәчәк кенә. Әнием Миләүшә, дәү әнием — Сөмбел.— Ул гөрелдәп көлде дә ак төймәгә башта чәнчә, аннан атсыз, азак, урта бармагы белән төртеп алды. («Ах, Нәркәс, һәрнәрсәнең кызыгын, шигърриятен табасың. Миңа гына булсаң ярар иде».)

Ишекне Кашапов ачты. Өченче контораның өлкән инженеры ул.

— Саумысез... («Бу монда ни эшләп йөри икән?»)

Бик таләпчән, хәтта усал кеше ул. Эшне аз гына җиренә җиткермәсәң дә утлы табада биетә. Зәкуан аны ярата да һәм курка да.

— Әти, таныш бул... («Әти?! Эләктем».) Таныш бул, әти, граф, юк, фон...

— Граф та, фон да түгел, ә бораулаучы Локманов.— Кашапов дусларча аның җилкәсенә суккалап алды.— Рәхим ит, Локманов.

Зәкуан оялуыннан ни эшләргә белмәде, колак яфраклары ялкынга әйләнде, маңгаена салкын тир тибеп чыкты («Тфү, кулъяулыкны да төшереп калдырганмын».) Шушы минутта идән ярылса, ул «ыһ» итми, төшеп китәр иде.

— Уз, уз, Локманов. Нигә аптырадың? Беренче очрашу түгел лә. Кичә генә буровойда серләшеп утырдык түгелме? («Яхшы сер! Юк өчен ярты сәгать пеште».) Анасы, Миләүшә, кунак килде, сыеңны хәзерлә.

Зәкуанны ачык каршыладылар, тәмле ашлар белән сыйладылар һәм җылы озаттылар. Тик бу җылылык йөрәк җылылыгына түгел, ә батареядән килгән җылылыкка охшый иде.

Хәер, тагын нинди җылылык көтәргә? Нәркәс ике елдан врач була, ә ул мазутка батып йөрүче рядовой бер бораулаучы. Мастер булса да бер хәл иде. Дөрес, ул аена икешәр мең сум ала. Һәйй... Хәзер юньле кыз акчага алданамыни... Каникулы беткәч Уфага китәр дә... вәссәлам.

Юк, онытмады. Хатлары еш килде. Хатлары озын булды. Ни-нәрсә генә булмый иде дүртәр-бишәр битле хатларда. Япониядәге тайфун, Америкадагы шарлавык, «кар кешесе», яңа дару, яңа картина, яңа роман, спорт һәм фән яңалыклары... Бөтен хатларны бергә җыйсаң, энциклопедия чыгарырга мөмкин. Тик анда ярату, сагыну турында бер авыз сүз дә юк, хәтта тел төбеннән дә сизелми иде.

Аңламассың бу Нәркәсне. Нинди уй белән йөри икән? Уфада яратканы бар микән?

Әлбәттә. Зәкуан каникул вакытындагы «запасной игрок». И-их беләсе иде уйларын, аңлыйсы иде серләрен...

— Сабый...

Зәкуан дерт итеп китте һәм паровоз-семафорны беләге белән этәреп җибәрде дә сикереп торды. Аның каршысында, кулларын ефәк плащының кесәләренә тыгып, елмаеп Нәркәс басып тора иде.

— Хәерле кич, Нәркәс.

— Сәлам, Зәки Локманов.— Ул Зәкуанны борынгы исем, дип Зәкигә әйләндерде. Зәкуанны бу әзрәк борчый борчуын, ләкин хәзергә түзә әле, дәшми, берәр әйтер әле әйтүен каты итеп. Нәркәс Зәкуанның учына шап итеп үзенең учын салды да шунда ук тартып алды. Зәкуан, һәр очрашкандагы кебек, бу юлы да каушап китте.

— Гафу ит, Нәркәс...

— Ни өчен?

— Кулыңны катырак кыстым ахры. Тимер тотып өйрәнгәнмен.

— Катырак?— Нәркәс кулын сузды.— Я, бөтен көчеңә кыс әле. Камыр куллы һәм исәнләшкәндә кулны иренеп кысучылардан минем «Син ир кешеме?» дип сорыйсым килә. Кыс, кыс. Син юри генә кысасың, Зәки. (Чынлап та, Зәкуан җәлләп кысты. Бөтен көченә кысса, ул Нәркәснең бармакларын укмаштырыр иде.) Ә хәзер мин кысам.

Нәркәс Зәкуанның кулын шундый кысты, Зәкуан чак кычкырып җибәрмәде. Кем инде шушы нечкә, кечкенә бармакларда шундый көч яшеренгән дип уйлар.

— Я?

— Бирeләм, Нәркәс. Син миннән дә көчлерәк.

— Минем бик көчле кеше буласым килә, Зәки.

— Син әле дә көчле.

— Физик көч ул аюда да бар. Минем бөтен яктан да көчле буласым килә. Ни эшләп без монда торабыз әле! Берәр җирдән урап киләбезме?

— Синең ихтыярың.

— Алай димә, Зәки. Синең бит мине чакырганчы үз планың булгандыр. Лев Толстой: «Минем гомергә, бер елга, бер айга, бер көнгә, бер сәгатькә, хәтта, бер минутка да планым бар»,— дигән.

— Граф Толстой ачуланмасын, мин плансыз килдем, Нәркәс. Шатлыгымны уртаклашырга.

— Уртаклаш. Нинди шатлык ул?

— Әйдә шушы ком өстенә утырыйк. Тукта, мин пинжәкне салам.

— Салма. Комнан берни дә булмый.

Алар балалар тауучыгына утырдылар.

— Сөйлә. Нинди шатлык ул?

— Бер атнадан безнең вышка өстендә кызыл йолдыз калкачак.

— Беләм,— диде Нәркәс, аны комга егып.— Беләм. Озакламый синең мастер булачагыңны да беләм.

— Мастер?— Зәкуан торып утырды.

— Нигә аптырадың? Әллә үзеңә ышанмыйсыңмы?

«Ничек инде үзеңә ышанмаска? Ышанам, тик алар бригадасында аннан да тәҗрибәлерәк бораулаучы бар. Башта аны аттеста-

циялэячэклэр. Зэкуанга яңа елга чаклы күтэргэ туры килер эле... Ничево, яңа елга ерак түгел инде. Нибары... биш ай... үлмэгэнгэ килэ дэ җитэ ул».

— Э син ышанасыңмы, Нэркэс?

— Ышанам.

— Мин дэ сиңа ышанам, Нэркэс.

— Э мин үземэ ышанмыйм. («Димэк, ул үзен-үзе алдап йөри».)

— Нигэ ышанмыйсың?

— Профессорлар... Эти-энием, мине артык несерьезный, дип эрли, егетлэр җилбэзэклегемнэн куркалар.

— Дөрес түгел, Нэркэс. Син...

— Нэрсэ мин?— Нэркэс аның күзлэренэ тутырып карады.— Нэрсэ мин? Башлагач эйтеп бетер.

— Син искиткеч шэп кыз. Синең йөрэгең тулы нур. Синең тамырларыңнан кан урынына кояш нурлары агыла. Мин синең янында аз гына торсам да үземне яхшырак, акыллырак тоя башлыйм. Мин сине яратам, Нэркэс. Бик нык,— Зэкуан, җавапны йолдызлардан ишетергэ телэгэндэй, күккэ карады.

— Мин дэ... өзелеп... үлеп...

Ул Зэкуанның җилкэсенэ башын куеп елап җибэрде.

«Мин дэ... өзелеп... үлеп...» Юк, бу авазлар җирдэн түгел, күктэн ишетелде.

Бу сүзлэр җилкэнгэ эйлэнеп, аны бэхет диңгезеннэн очырып алып китте. «Мин дэ... өзелеп... үлеп...» Җилкэн кинэт канат була һэм аны йолдызлар янына алып менеп китэ. Зэкуан кесэлэренэ, куенына йолдызлар ту-

тыра. Бөтенесе дә, бөтенесе дә Нәркәскә, Нәркәскә генә...

Бер ел ул шушы сүзне ашкынып, өметләнеп һәм шикләнеп көткән иде. Хәзер дөньяда аның кебек бәхетле, аңа тиң кеше юк. Их дөнья... Колачларым җитсә, мин сине кочаклар идем. Йолдызлар, ишетәсезме — Нәркәс мине ярата. Нигә күз кысасыз, ышанмыйсызмы? Юкка. Хәер, минем өчен барыбер,— Зәкуан, Нәркәсне күтәреп, балалар тавы тирәли әйләнеп йөрде, чәченнән, маңгаеннан, битләреннән, күзләреннән өзлексез үпте.— Ә мин курыккан идем, шикләнгән идем.

— Нидән?— Нәркәс сикереп җиргә төште.

— Шаярып кына йөрисеңдер, дигән идем.

— Димәк, син дә мине җилкуар дип уйлагансың.— Ул көрсенеп куйды.— Нигә мин шундый җиңел икәнмен...— Ул комга утырды.

— Син җиңел түгел, Нәркәс, син шат. Син бәхетле. Шуңа күрә син күбәләктәй гамьсез.

— Ә син?

— Мин дә бәхетле, Нәркәс.— Ул да комга утырды.— Әйдә күпер салабыз.

— Әйдә...

— Ә син... Миңа тормышка чыгар идеңме, Нәркәс?

Шундый шаян, беркайчан да каушый белмәүче Нәркәс, кинәт югалып калды. Ни булды аңа? «Яратам» сүзен шунда ук әйткән иде бит. Ни булды аңа?

— Дөрес, мин әле бораулаучы гына. Ләкин мин мастер булачакмын. Күр дә тор. Мин әйткән сүземне сүз итми калмыйм ул. Мин

быел кичке институтка да керәчәкмен. Инженер булачакмын. Әллә ышанмыйсыңмы?

— Ышанам. — Нәркәснең тавышы ишетелер-ишетелмәслек кенә чыкты.

— Ышангач?..

— Ай-й!..

— Ни булды?

— Йолдыз атылды, Зәкуан. Йолдыз... — Ул Зәкуанның битеннән чутылдатып үпте дә үзләренә йөгереп кереп китте.

— Нәркәс!.. Нәркә-әс!!

Ишетмәде, борылмады, биттә генә ялкынлы эзе торып калды. Моны ничек аңларга? Төш, төш җиргә, Зәкуан. Кесәләреңне бушат — йолдызларны күккә кире сип. Нәркәсең югалды бит...

Зәкуан баягы юкәне барып кочаклады. Моны ничек аңларга? Исәнләшмәде дә... Димәк, шаярткан. Әлбәттә. Ике елдан ул врач булачак, ә син рядовой бораулаучы. Өс-башыңнан мәңге мазут-нефть исе аңкып тора. Ул костюмын, кулларын иснәп карады. Аңкысын. Аңа китсә, врачлардан да һәрвакыт хлороформ, хлоромин исе бәреп тора. Нефтьтән кыйммәтле хушбуйлар да эшлиләр әле, тик аны хушбуй сөртүчеләр генә белми. Ярый, син хушлашмасаң да, мин хушлашам, Нәркәс. Хуш, «Кара чәч», тыныч йокы. Чү... Ашыкма, өч тәрәзәдә дә ут кабынды бит. Кешеләрнең йөргәне күренә башлады. Андагы хәлне күрер, сүзләрне ишетер өчен ул, төнге күбәләккә әйләнеп, форточкадан бүлмәгә очып керер иде. Чирек сәгатьләп өч тәрәзәдә дә ут янды. Чирек сәгатьләп Зәкуан шул тә-

рәзәләргә карап нидер көтте, ләкин көтеп ала алмады. Берьюлы өч тәрәзәдә дә ут сүнде һәм Зәкуан кулларын чалбар кесәсенә тыгып, башын иеп, сызгыра-сызгыра кайтып китте. Ә нинди дәрт белән, ургылып торган шатлыгына урын таба алмый килгән иде ул бу йорт каршысына. Ул килгәндә, сирәк кенә булса да, кайбер тәрәзәләрдә ут яна иде. Хәзер биш катлы йорт батып баручы корабка охшый — бер генә тәрәзәсендә ут янса иде, ичмасам. Шатлыгымны бүлештем дә кайгы алып киттем...

Ә йолдызлар һаман шаярдылар, алар Зәкуанның кайгысын белмәделәр һәм белергә дә теләмәделәр. Алар бер-берсен куышып уйнадылар, атылдылар.

Бер квартал да үтмәде, Зәкуанны Нәркәс куып җитте.

— Нәркәс!..

— Ризалар!..

— Нәрсәгә?

Нәркәс Зәкуанның соравын ишетмәде.

— Синең «Миңа тормышка чык», дигән сүзең аяз көнне яшен яшьнәгән кебек булды. Юк, мин икеләнмәдем. Мин күптән ул сүзне көтеп йөри идем, ләкин ничек җавап бирергә белмәдем. Хәзер үк «әйе» дип әйтергәме, әллә каникулдан киткәндәме, дип икеләндем. Әгәр йолдыз атылса, хәзер үк әйтәм, атылмаса... дип юрарга өлгермәдем, безнең йорт башындагы йолдыз тәгәрәп китте. Шуннан мин дә атылып өйгә кердем.

— Тилекәем, син әллә аллага ышанасың инде?

— Юк, әлеге дә баягы, шул җилбәзәклек. Экзаменга мин туфли үкчәмә биш тиен акча салып барам.

— «Бишле» алырга ярдәм итәме?

— Көт, укымасаң, итәр. — Ул Зәкуанның чәчен үз тарагы белән, үзенә ошаганча тарады. — Әти-әнине уяттым да: «Мине котлагыз. Иртәгә мин кияүгә чыгам», — дидем. Әтием: «Что-о?» диде дә, икенче якка борылып, башыннан бөркәнеп ятты, ә әнием, мине беренче күргән кеше кебек, йокылы күзләре белән ашардай итеп карады. «Қабатла әле шул сүзеңне, чикерткә?» — диде ул, каршыма басып.

— Иртәгә, унынчы августта, Зәки Локманов белән танышуга төп-төгәл бер ел тула. Ул миңа, русча әйтсәк, сделал предложение, — дидем мин, мөмкин кадәр тыныч сөйләшергә тырышып һәм һәр сүземне өзеп. — Ә мин ризалык бирдем.

Әтиемнең юрган астыннан башы күренде, әнием, учлары белән битен каплап, еларга кереште. Әти миңа «чыгып тор» дигәнне аңлатып, ишарә ясады. Мин кухнядә көттем. Чакырдылар. Әтием, нигәдер, чалбарын да, пинжәген дә кигән, хәтта галстук та таккан.

— Қызым, — диде ул, мине муенымнан кочаклап. — Бу хакта төнге икедә түгел, ә кояш чыккач әйтсәң, ни булыр иде? Әллә хәзер шундый модамы?

Әтиемнең шелтәле тыныч тавышы мине батырайтты да, каушатты да.

— Ачуланма, әти... Мин синең кебек эшләргә булдым.

— Минем кебек?

— Әйе. Син дә бит әниемне иртәнге бишҗтә алып киткәнсең. Кояш чыкканчы көтеп тормагансың...

Әтием җавап тапмады, маңгаемнан үпмәкче булып иелгән иде, әнием, очып килеп, мине аның кочагыннан тартып алды.

— Синең эти-әниеңне тикшерергә хакың юк. Син әле сабый гына. Хәзер үк ят. Ишетәсеңме?

— Юк, ишетмим, — дидем мин, нигәдер әниемне үчекләп.

— Анасы...

— Тик тор. Синнән сорамыйлар, — дип кырт кисте әни әтиемне. — Башта институтын бетерсен, берәр ел эшләсен, аннан күз күрер.

Әтием, үз бүлмәсеннән энциклопедиянең утыз икенче томын алып кереп, нидер эзли башлады. Әйтерсең, «БСЭ»ның утыз икенче томында минем кайчан, кемгә кияүгә чыгуым турында язылган. Гомумән, минем әтием, әнием белән әйткәләшсә, нигәдер, энциклопедияне актарырга тотына һәм бөтенләй тузга язмаган нәрсә турында укый: я диңгез кыслалары, я Африка үрмәкүчләре хакында.

Мин сүземне сүз итәргә булдым. Чынлап та, нигә әниемә унҗиде яшьтә, иртәнге бишҗтә, кияүгә чыгарга ярага, ә аның егерме ике яшьлек кызына ярамый?..

— Алайса мин, әни, рөхсәтсез язылам, — дидем, бәхәсләшүнең файдасы юк дигәнне аңлатып.

— Ә мин синең паспортыңны яшереп куям, бөтен ЗАГСларга шалтыратам, — диде әни, ныграк кычкырып.

Сүзсез торам, аның ачуы кайта.

— Ә мин паспортны яшереп куйдым, — дидем мин, әниемне кочаклап.

Әнием кухняга чыгып китте. Ялгышмы, юриме, чынаяк төшереп ватты, аның ватыкларын санап җыйды да, тынычланып, безнең янга керде.

— Ходайга тапшырам. Тик минем бер шартымны үтисез, — диде ул бер әтиемә, бер миңа серле карап.

— Нинди шарт? — диде Зәкуан, шатлыгыннан Нәркәсне үзе тирәли зырылдатып. — Ул ни кушса, шуны эшлим.

— Әгәр «кызымны никахсыз бирмим» дисә?

— Никах? Адәм ышанмастай сүзне чын булса да сөйләмә!

— Ә син сак бул. Әнием дәү әниемнең бер сүзеннән чыкмый. Ә дәү әнием: «лә илаһа илалласыз» аяк атламый, «бисмилласыз» кулын күтәрми, тәсбихе белән әфтиягеннән аерыла алмый.

— Юк, булмый, ышанмыйм.

— Ә нигә... Уфада минем бер таныш кызым былтыр капитанга кияүгә чыкты. Шаулатып никах укыттылар. Азак мулла ләх исерде. «Афарин», ди дә «Шумел камышны» җырларга тотына. Өенә кайтканда, милиционерга бәйләнеп, вытрезвительгә эләккән.

— Ярый, юк белән баш ватмыйк, Нәркәс. Синең әниең тома сукыр кеше түгел лә.

— Дөрес, юк белән баш ватмыйк.

Ике бәхетле кочаклашып, башларын терәшеп, август күгеннән үзләренең бәхет йолдызларын эзләделәр...

*
* *

Тәки Зәкуан бу төнне йоклый алмады. Хәер, ул йокларга да теләмәде. Нәркәсне озаткач, Ык буена төшеп, яр башында утырды. Сахра елгасы йокымсырап кына ага да ага. Аның башы да, азагы да юк кебек. Моннан мең, ун мең ел элек тә ул шулай аккан, хәзер дә шулай ага. Аның өчен кешеләрнең кайгы-шатлыгы, заманның тетрәве берни түгел. Кышларын ул боз тунына төренә, яз килгәч, гашыйк булган кеше кебек, кемгәдер көчен күрсәтергә тырышып, ярларыннан ярсып чыга. Ә хәзер август. Ул, хәлсез юлчысыман, тавышсыз-тынсыз гына ага да ага, тик йолдызлар гына аның йөзенә төшеп, җемелди. Ә Зәкуан аңа үзенең шатлыгын сөйли. Ык аңлагандай борылмада тавыш чыгарып куя. Зәкуан елмая. Күз иярмәслек арада чишенә дә суга чума, колачларын алга ташлап йөзә, тагын чума һәм бөтенләй яңа кеше булып ярга чыга; иртәнге кояшта тәнен киптерә, колакларына кергән суны чыгарыр өчен бер аягында сикергәли.

— Тынычлыгымны бозды бу юньсез малай, дип ачуланма, елга, яме? Пока!

Ул өенә атлый. Ике сәгатьтән ул Нәркәснең законный ире булачак. Закон дигәннән, аңа закон буенча ике көн отпуск тиеш түгелме соң? Азак. Хәзер тизрәк скважинаны очларга кирәк.

Ир һәм хатын... семья. Бәләкәй генә... микродәүләт. Үз законы, үз тәртибе бар. Кызык... мәзәк...

Бер елдан, күп дигәндә, ике елдан, юк, өч елдан (Нәркәс институтны бетергәч) аларның баласы булыр. Малай туса, Зәкуанның атасының исемен кушарлар, кыз булса — әнисенекен.

Ата-ана сүзе һәрвакыт аның йөрәгендә хәтерләүләр фонтаны уята. Их, менә шушында, аның ике ягыннан атасы белән анасы да барса. Берсе шелтәләр, икенчесе яклар, бәлки икесе дә шелтәләр, яки икесе дә мактар иде... Ата-аналы балалар, үзегезнең чиксез бәхетле икәнегезне бер генә секундка да онытмагыз, кадерен белегез. Ана кояш булса, ата ай ул.

Зәкуан тиз генә яңа костюмын кия, галстук тага, чәчен Нәркәс ратканча тарый һәм...

— Син бүген эшкә бармыйсыңмыни, егет? — дип туктата аны ни өчендер бүген таң белән торган күршесе өлкән оператор Зарипов.

«Әйтергәме, юкмы? Ә нигә яшерергә? Ашыкма, Зәкуан. Бәлки Миләүшә апай әллә нинди, көч җитмәслек шарт куяр да, өйләнә алмассың. Әйтми тору хәерлерәк».

— Мин... паспортка карточкага төшәргә барам.

— Ә-ә, — ди Зарипов, — көзгегә карамый, керпе сакалын коры гына көйгә шытыр-шытыр кырып. — Шундый киенеп-ясангач, мин әллә кәләш алырга барасыңмы, дигән идем.

— Ә нигә, алсам гаепмени?

— Гаеп түгел, әмма ашыкма, энем. Хәзерге заманда егетләр камыт кияргә кабаланмыйлар. Утызың җитсен, аннан янә бер-

ике ел үтсен, аннан янә ике-өч ел караштырып-сынаштырып йөре...

— Һәм азак, синең кебек, буйдак булып калырсыңмы? Консультацияңә рәхмәт, Зарипов абый, ләкин аз гына соңладың. Сәлам!

Зәкуан, Зариповны кочаклап, кырылган яңагыннан үпте дә шар кебек тәгәрәп, баскычтан төшеп китте. «Кызык, ни өчен шушы Зариповны яратмыйлар икән? Төскә-башка коточкыч түгел. Холкы әйбәт. Кешенең яхшы ягын күрә белергә кирәк», — дип нәтиҗә ясады Зәкуан, автобуска утырганда.

— Миңа... 26 нчы мәктәпкә чаклы, — диде ул кондуктор кызга ягымлы елмаеп.

Автобуста алар икәү генә иде. Кызык, ул кызның яраткан егете бар микән? Тиле син, Зәкуан, яратмый яшәп буламыни? Ә соң үзең Нәркәсне күргәнче ничек яшәдең? Юк, яратмый яшәп була, ләкин ничек яшәсәң булмый. Ярканат та дөньяда яши, сандугач та, бөркет тә. Юк, бу кызның әле яратканы юктыр. Бала гына бит. Кызык, ничә яшьтә икән?..

— Егет, хәзер 26 нчы мәктәп.

— Килеп тә җиттекмени? — Ул автобустан чыкканда кызга ике конфет сузды.

— Рәхмәт. Берсен үзем ашыйм, берсен кызыма алып кайтам. Аның үлеп яраткан конфеты.

«Кызыма...» Менә сиңа бала... Ә Зарипов хәзер картайгач өйләнү модада, ди...

Нинди шарт куймакчы була икән, Миләүшә апа... каенанам... гадәтләнгәнче әйтүе кыен булыр әле. Каенана... Нидән алынган икән? Каен анаданмы. Зәкуан туктый, кесәсеннән түгәрәк көзге алып чалбарына сөртә

дә галстугын төзәтә, чәчен артка сыпыра. Ничә тапкыр аның бу биш катлы йортка кергәне, икешәр баскыч аркылы сикерә-сикерә икенче катка күтәрелгәне һәм ак төймәгә өч тапкыр басканы бар. Ә менә хәзер ул әллә ни эшләде. Галстук та кыса, аяк та тубырланды. Нәркәс аны тәрәзәдән күреп калды һәм бармакларын үбеп сәламләде. Зәкуанга кинәт кыюлык ташкыны ургылды һәм ул икенче катка ничек менеп җиткәнен дә сизми калды. Ул ак төймәгә басарга өлгермәде, Нәркәс атылып чыкты. Нинди матур ул! Нинди якты ул — әйтерсең, кояш үзе төшкән! Ап-ак капрон күлмәк, ипләп басмасаң, хәзер сынам, дип торган нәзек үкчәле ак туфли һәм... сумала чәч. Шомырттан да карарак зур ике күл — ике күз. Ике генә төс: ак һәм кара. Беркайчан да килешмәүче ике төс: ак һәм кара. Ә нинди гармония, нинди ярашу. Бик җентекләп карасаң, Нәркәснең дә килешеп үк җитмәгән яклары бардыр, бәлки кашлары да киңрәктер, яңаклары да чыгыбрак торадыр». Торсын, аңа Зәкуанның аз гына да эче пошмый. Ул бит үзе дә исең китәрлек матур түгел. Ничек ди әле халык: матурлык — туйда, акыл — көн дә кирәк. Туй, дигәннән, туйны кайчан ясарбыз икән?..

— Зәки...

— Ә?

— Әнием, беләсеңме, нинди шарт куя?

— Нинди?

Ул арада кыска, юан гәүдәле, зур күзле Миләүшә апа килеп чыкты.

— Изге аягың белән кер, кияүкәем. Уңын атла, уң аягыңны... Һи-һи-һи... Чәй эчик тә,

ЗАГСка барырбыз. Атагыз конторааларыннан туры килергә булды.

Алар залга үттеләр. Шикәр төсле ап-ак ашъяулык җәелгән өстәл артында, чиртсәң кан чыгарлык кып-кызыл чырайлы, күп дигәндә егерме алты-егерме сигез яшьлек зур кара сакаллы кеше тәсбих тартып утыра иде. Ул ялтырап торган шома башына бохар түбәтәе кигән.

— Саумысез, — диде Зәкуан, кабак башлы кешенең камыр кебек йомшак кулын каты кысып.

— Әссәламәгаләйкум...

— Кем ул? — дип пышылдады Зәкуан.

— Дәү әни шарты.

— Аңламыйм.

Миләүшә апа табада чыжлап торган кызгылт-сары «кияү коймагы» алып керде.

— Балалар, утырышыгыз. Хәзрәткә каршы утырыгыз. Бергәләп.

— Хәзрәт?

Нәркәс Зәкуанның пинжәгеннән тартты. Хәзрәт тыңкыш тавыш белән, үшән ат юрткан кебек, бер җайга гына нидер укый башлады.

— Әгузебиллаһи минашшайтан ирраҗим бисмиллаирахман иррахим...

— Нәрсә укый ул? Кем ул? — диде Зәкуан, бернәрсә аңламый кычкырып. Табак битле Миләүшә апа куштанланып елмайды:

— Ул хәзрәт... мулла.

— Мулла?! — Зәкуан сикереп торды. Аның гомере эчендә тере чын мулланы күргәне юк иде. Анда кинәт балалык уянды. Хәзер ул барып, мулланың ябыштырып куелган

кара сакалын куптарып ала да, каз күкәенә охшаган башына «Әй, хәзрәт, карбыз ни хак тора?» дип чиртә. Юк, килешми. Бу балалык түгел, хулиганлык.

— Монда килгәнме ул бәлеш авыз?— дип сорады Зәкуан Нәркәстән.

— Әнникахи сөннәти фәмен рагиба мин сөннәти...

— Никах?.. — Әйтерсең, Зәкуанны бозга ыргыттылар.

— Ш-шш...

— Нәркәс!

— Ш-ш-ш... — Нәркәс аның җиңеннән тарта, күз кыса.

Ул арада Нәркәснең урак кебек бөгелгән дәү әнисе тавышсыз гына килеп керде.

— Ай рәхмәт яугыры бәбекәйләрем... Камсамул булсаң да алланы оныту ярамый ул. Партийные да, камсамулы да барыбер кыямәт көнендә аллаһы тәбәрәкә вә тәгалә алдында җавап бирәчәк. Лә илаһа иллалла. Мәңге бакый иманнан аерма.

«Ә-э... Аңладым, — диде Зәкуан кычкырып сулап. — Ну бу кызны. Дәү әнисенең сүзен сүз итәр өчен юри, ялган мулла алып килгән. Ну килештерә, чукынган малай, тик сакалны гына әллә ничек ябыштырган — артык зур. Драмтүгәрәктә катнашадыр инде. Молодец!»

— Нәркәс Зариф кызы Зәкуан Харис углына үз теләгең белән тормышка чыктыңмы? Чыктым, диген, карендәш, чыктым, диген.

Зәкуан түзмәде, «мулла» янына барды да иелеп пышылдады:

— Я, егет, житте. Қызыгы китә башлады.

Каенана очып килеп киявенең кулыннан тотты.

— Кияүкәем, син шикләнмә, ул указлы, яңача әйтсәк, дипломлы мулла. Быел гына Бохарадан укып кайткан.

«Беләм мин андый муллаларны» дигәнне аңлатып, Зәкуан каенанасына күз кысты да, коридорга чыгып, папирос көйрәтте.

— Зәки... — Аның артыннан ак күбәләк — Нәркәс чыкты.

— Кызык бит, Зәки? Әгузебиллаһи... — Нәркәс мулла булып укый башлады.

— Ничево. Килештерә. Ә дәү әниең изрәп тыңлап утыра.

— Соң ул бит чын мулла.

— Чын? Кит әле.

— Әйе. Честное комсомольское... Әнием таксида алып килгән.

Зәкуан башта ышанмаска, аннан ышанса да сиздермәскә тырышты.

— Ә син каршы төшмәдеңмени?

— Һи-и... Берне түгел, йөзне укысын. Безнең өчен барыбер бит. Аллага да, муллага да ышанмыйбыз.

— Юк, барыбер түгел, Нәркәс, — Зәкуанның ачуы йөзенә чыга башлады.

— Юкка борчылма. Беркем белмәячәк. Хәтта, әтием дә. Минем әни дәү әниемнең сүзеннән чыга алмый. «Аның яшәгән чаклы яшисе калмаган, бүген бар, иртәгә юк. Карт кешене рәнҗетергә ярамый», ди. Дөрес бит?

— Дөрес, Нәркәс, карт кешене дә, яшь кешене дә җәберләргә ярамый.

— Зәки...

— Мин Зәки түгел, Зәкуан, — аның ачуы

тавышына да чыкты.— Син бер кеше дә белмәячәк, дисең. Эш кеше белүдә генә түгел, эш үзебезнең намуста. Ә белсәләр? Булачак врач һәм коммунистик хезмәт бригадасы өчен көрәшүче космомолец никах укыткан дип, бөтен шәһәр көләчәк.

— Соң хәзер ни эшлибез? — диде Нәркәс еламсырап. — Мин ул кадәр тирән уйламаган идем, Зәки... Зәкуан.

— Чумар алдыннан елганың тирәнлеген белергә кирәк, Нәркәс, югыйсә башың белән төпкә бәрелеп, исәнкерәвең... хәтта һәлак булуың бар. — Ул зал ишеген ачты да бер бармагы белән хәзрәтне чакырды.

— Хәзрәт...

Хәзрәт олысыман атлап, кулларын җиңнәре эченә тыгып, коридорга чыкты.

— Тыңлыйм, алла...

— Күпмегә килештең? — диде Зәкуан, аңа реглан формасында тегелгән кара җиләнен сузып.

— Нәрсәне, алла...

— Никах укуны?

— Ә-ә... Түгәрәк... Йөз тәңкә.

— Йөз сум? Мә яртылык.

— Мин күк чәйдән башка нәрсә эчмим, алла...

— Сатулашып торсаң, күк чәйлек тә ала алмассың, ишеттеңме?

— Ишеттем, ишеттем, алла колы...

— Син үзең акча колы... хәзер үк табаныңны ялтырат, югыйсә...

Мулла, «алла» һәм «шайтан» сүзләрен еш әйтеп, сукрана-сукрана чыгып китте.

— Уф-ф... Мөртәт, сорыкорт, кандала,

үзе «Красная Москва» хушбуе сөрткән. Киттек ЗАГСка, Нәркәс.

— Ашыкмагыз, балалар, — диде Миләүшә апа, болар алдына килеп басып. — Сез минем шартымны үтәмәгәч, мин дә сезнең теләгегезне үтәмим.

— Әни?

— Миләүшә апа...

— Минем йорт тулы кызым юк. Шулай булгач, нигә ашыгырга. Институтын бетерсен. Берәр ел эшләсен, аннан ашыкмый, иркенләп берәр инженерга бирербез әле, боерган булса.

— Әни!

— Ә син авызыңны ипләп ач. Җикеренмә. Мин ашасын ашаган, яшәсен яшәгән. Мин синең бәхетең өчен тырышам. Шул мазутка батып йөрүче бораулаучыга чыкмасаң, укымышлырак кешеләргә кырау төшмәгән.

Зәкуан шартлар хәлгә җитте. Миләүшә апа янә бер генә сүз әйтсә, ул, атылган йолдыз кебек, тузанга әйләнәчәк. Әмма ул кешелектән тыш көч салып үзен тотты һәм хәтта елмайды да.

— Димәк, Миләүшә апа, сез кызыгызны кешегә түгел, профессиягә, должностька бирәсез. Белмәгән идем. Гафу итегез.

— Зәкуан... ышанма. Дөрес түгел. Мин синеке, — Нәркәс аны кочаклап үкси башлады.

— Шулаймы? Алайса, син минем кызым түгел. Дүрт ягың кыйбла. — Миләүшә апа йокы бүлмәсенә кереп ишекне бикләде дә акырып еларга тотынды.

— Зәкуан, миңа нишләргә?.. Әйт, миңа нишләргә?

— Әниеңне рәнҗетмә. Ана, нинди генә булмасын, бер генә була ул. Ә мин аңа үземнең кемлегемне танытырмын әле. Хуш, Нәркәс. Миңа бер сәгатьтән вахтага.

Урамга чыгу белән, Зәкуан галстугын муеныннан суырып алды, изүен ычкындырды. Пинжәген салып, иңбашына куйды. Ф-фуу... Иртүк шулай кыздырмаса. Ул агачлар төбендәге скәмьягә утырып папирос көйрәтте һәм бераз тынычлангач әле генә булган хәлне күз алдына китерергә тырышты. «Беркем дә гаепле түгел, үзем генә. Нинди шарт икәнлекне белми торып, ни кушсагыз, шуңа әзермен, дип шапырынмаска кирәк иде. Дон-Кихот! Кайтып, өс-башны алмаштырырга да, буровойга барырга кирәк.»

Капка төбендә аны Нәркәс куып җитте.

— Зәкуан, син, зинһар әниемә үпкәләмә. Ул дәү әниемнең сүзен сүз итәр өчен генә мулла чакырткан.

— Ә син?

— Нәрсә — мин?

— Син бу хакта белдеңме?

— Мин әнием шаяртадыр, дип исәпкә алмадым.

— Кайчак җитдирәк булырга да кирәк, Нәркәс.

— Моннан соң миннән дә җитдирәк кеше булмаячак. — Ул кулларын артка куеп, башын күтәрә төште дә иреннәрен кысты.— Менә, кара. Ышандыңмы? Ышансаң, тыңла.

— Тагын шартмы?

— Түгел, үтенеч. Әнием бу хакта этиемә

бер сүз дә әйтмәскә кушты. Болай да шул алла аркасында алар арасына еш кына шайтан керә.

— Әгәр мин әйтсәм, Нәркәс?

— Ул вакытта син мине яратмыйсың булып чыга.

— Юк, син мине яратмыйсың, Нәркәс, яратсаң...

— Әйтеп беттеңме? Әйдә. — Ул Зәкуанның кулыннан тотты. — Киттек.

— Кайда?

— ЗАГСка.

— Ә әниең?

— Риза. Зәкуан үпкәләмәсен инде, авыр сүзләр әйтеп ташладым бугай. Ярсып киттем, диде.

— Дөресме?

— Ышанмасаң, дөрес түгел.

— Ышанам. Киттек... Юк, китмәдек. Нәркәс, әйдә өйләнүне бер ун көнгә күчереп торыйк. Ашыкма, хәзер аңлатам. Никах — пустәк. Искә алырлык нәрсә түгел. Нииндидер ахмак төш кенә. Саташу.

— Соң сине нәрсә борчый, Зәкуан? — Ул Зәкуанның күзләренә карады. — Я, нәрсә борчый?

— Мин сиңа өйләнгәнче... Юк, мин моны әйтә алмыйм. Нәркәс, төпченмә. Ун көннән... егерменче августта, мин синең законный ирең булырмын. Ярыймы? Калганын азак әйтермен. Сау бул. Бер сәгатьтән миңа вахтага. Теләсәң, кич очрашырбыз.

Зәкуан, вахта машинасыннан төшеп, 613 нче скважина сукмагына борылгач, верховой

Янтурин өскә карап, нидер әйтте. Ул арада буровойдан кешеләр сибелде. Ни күрделәр алар? Зәкуан артына борылып карады. Искитәрлек бернәрсә дә юк. Күптән таныш һәм күнегелгән кала күренеше. Моннан ни бары ун-унбиш ел элек кенә монда дистәләгән барак һәм бер-ике катлы әштер-өштер салынган йорт булган. Ә Зәкуан балалар бакчасына йөргәндә Ык буйларында терлек йөргән, иген үскән. Ә хәзер... теләсә нинди шәһәр белән аяк терәп сөйләшерлек гүзәл бер шәһәр. Дүртәр-бишәр катлы йортлар, дворецлар, бакчалар... Нефть ни арада җирнең йөзен үзгәртте. Юк, дөрес түгел, кешеләр, совет кешеләре үзгәртте. Нишләп соң һаман өерелеп торалар алар? Кулларын болгый-болгый сөйләнәләр. Коллектор Шәүрәнең кулында чәчәкләр... Ул ашыгып атлады. Чү! Моторист Витька Речкин аккордеонда «Каршылау маршы» уйнап җибәрде. Шәүрә, йөгереп килеп, аңа чәчәкләр бәйләме сузды. «Котлыйм!» Бу ни? Мастер Шәфиев трубкасының мөштеге белән мыегын бер унга, бер сулга сыпырды да, Зәкуанны кочаклап үпте.

— Котлыйм, үзем, семьям һәм зур семьям (ул бригадасына күрсәтте) исеменнән котлыйм, кияү.

Речкин Зәкуанның колагына нидер әйтте дә шаркылдап көлде.

«Ни эшләргә, дөресен әйтергәме, әллә шул көйгә үтсенме? Соң алар бу хакта кайдан белгәннәр? Ну халык... Әйтсәң дә кыен, әйтмәсәң дә кыен. Нишлисең, дөреслекне сөйләү һәрвакыт күңелле булмый».

— Иптәшләр, агай эне...

— Ярый, җавап сүзең кирәкми. Бу җыелыш түгел, — диде әлеге дә баягы Витька Речкин аны бүлдереп. — Туең кайчан? Егетләр, минем тәкъдим шулай: җыелышып, Зәкуанга пианино алып бирәбез. Әллә аккордеон да җитәрме? Юк, пианино алабыз. Зәкуан үзе дә әзрәк тамызыр.

— Никах укытмадыгызмы? — диде Шәяхмәтов. — Ярты утыртсаң, живо, шушында ук укып бирәм.

Зәкуан ни көләргә, ни ачуланырга белмәде.

— Иптәшләр, агай-эне...

— Локманов, — аны бу юлы мастер бүлдерде. — Без зур вакыйга алдында торабыз, шулай булгач, отпускы-мазар сорамассың инде.

Витька Речкин, алан-йолан каранды да, Шәүрәнең киткәнлеген күргәч, «Ничево, мастер, хәзер төн озын» дип көлде. — Зәкуан, хәзер синең белән ипләбрәк сөйләшергә туры килер. Өлкән инженерның киявесең бит.

— Виктор...

— Бетте, бетте, Зәкуан Баймович. Киттем вахтаны кабул итәргә. Сәлам!

Зәкуан мастер белән генә торып калды.

— Нигә боексың, энем? Ярый, ярый. Җавабың кирәкми. Баштан үткән хәл. Өйләнгәнче ни эшләргә белми, ашкынып йөрисең дә, өйләнгәч, бигрәк тә беренче көннәрдә, башыңа урын таба алмыйсың ул. Нишлисең, яшьлек, егетлек белән хушлашу җиңел нәрсә түгел. Ярый, оныттык. Башыңны күтәр. Кызың кыз түгел, фирештә. Әә атасы! Бәхетле яшәгез. Миннән теләк шул. Ә мин хәзер кай-

тып, бер-ике сәгать черем итәм. Төне буе керфек какмадым. Каты порода булды. Долотоны ике рәт алмаштырдык. Син, Шәяхмәтовка күз-колак бул. Ул кайчак чаманы онытып ташлый. Долотога нагрузканы унбиш тоннадан да арттырмагыз. Иң күбе — унбиш тонна! Хәзер, үзең беләсең, долотолар элекке кебек түгел, диаметрлары бәләкәй. Сигез дюйм гына. Дрелограммадан күзеңне алма. Хәер, нигә сине өйрәтеп торырга инде. Сменага ун метр бирсәң, бик шатмын. Ярый, уңыш телим. — Ул Зәкуанның аркасына сукты да эре-эре атлап сукмактан түбән төшеп китте.

Башта Зәкуан эш белән мавыгып, беразга бая булган хәлне исеннән чыгарып торды. Турбобур әкрен генә тирбәлде, мотор гүләде, скважинага үз җаена гына балчык эретмәсе акты, ә забойдан су белән буталган порода чыкты. Зәкуан дрелограммага күз салды — нагрузка ундүрт тонна иде. Ул тормозда торган Шәяхмәтовка күз кысты да, тәмәке тартырга буровойдан чыкты.

Көн чалт аяз. Аксыл зәңгәр август күгендә адашып йөрүче ястык чаклы болыт та күренми. Зәкуан ашалган долотога утырды. Нефть тирә-яктагы үләнне көйдереп бетергән. Тик бер әрем генә бирешмичә үсәргә тырышып ята. Аның әче, үткен исе нефть исен җиңеп, борынга керә. Кызык, кешеләргә һәм табигатькә санап бетергесез яхшылык эшләүче нефть бер үк вакытта начарлык та эшли; үлән-чәчәкләрне көйдерә, һаваны сасыта. Ә соң мәхәббәт...

— Зәкуан, энем!..

— Нәрсә, Шәяхмәтов абзый?..
— Кер әле.
— Керәм.
Зәкуан папиросын табаны белән изде, иелеп, батыр әремне иснәде дә буровойга керде.
— Нәрсә?
— Әллә нагрузканы, мин әйтәм, бер-ике тоннага арттырабызмы? Порода йомшара төште.
Чынлап та, әллә арттырыргамы? Төнге сменада әллә ни алдыра алмаганнар. Алган йөкләмә буенча, алар уналтынчы августта скважинаны эксплуатациягә тапшырырга тиешләр. Әгәр төнге смена кебек эшләсәң, егерменче августта да эшне төгәлләп булмаячак. Ә алар бригадасы моңа чаклы әйткән сүзен сүз итми калмый торган иде.
— Юк.
— Бер генә тоннага.
— Юк.
Зәкуан квадратка карый — аның әйләнүе бик әкрен тоела. Әгәр ун урынына унбиш метр бирсәң? Бу ике көнне тартып алу дигән сүз. Зәкуан, колагын салып, тыңлый. Турбобур тигез әйләнә, көчәнми. — Ике көн ике йөз мең сум дигән сүз ул!
— Әллә берәр тонна өстибезме?
Ну шул Шәяхмәтовны... бигрәк тәкатьсез.
— Долотога авырга килмәсме соң?
— Пустяк.
«Ике көн! әгәр ун бригада икешәр көнгә эшен алдан тәмамласа? Ике миллион сум!.. Әгәр ул бригадалар йөз булса».
— Энем, әллә...
— Ярый. Өстә! Фәкать берне.

Бер метрны алар унөч минутта үттеләр.

«Әгәр башка вахталарда ун метр урынына унбишне бирсәләр... Ә нигә егермене түгел! Зәкуан егермене җиңел бирәчәк. Ул чакта эш өч көндә вәссәлам. Яңа рекорд! Менә шул чагында хөрмәтле Миләүшә апа кемнең кемлеген белер. Әнә 811 нче скважинада мастер булып инженер эшли, ә толк?.. Бер айда ике тапкыр авария ясады. Эш дипломда гына түгел, башта да, Миләүшә апа. 613 не тапшыру белән ул начальстводан үзалдына эш сораячак. Беләсезме, ул ни эшләячәк! Башка бригадалардан куылган җыен юньсез эшчеләрдән үз бригадасын төзиячәк.

— Шәяхмәтов абзый...

— Нәмәстә, энем?

— Әйдә җырлыйбыз.

— Мин җырлый белмим, энем. Моңым юк. Бөтен туганнарым җырлый, ә мин мөңгери дә белмим.

— Минем дә моң юк ла ул.

— Әллә тагын берәр тонна өстибезме, энем?

— Юк, юк. Лутче әйдә җырлыйк.

Дан приказ ему на запад,
Ей в другую сторону...

Шәяхмәтов абзый...

— Әүкәй!..

— Миннән шәп мастер чыгармы, ә?

— Синнәнме? Мә, тормозны тотып тор әле. Мин берне көйрәтеп керәм. — Ул тормоздан кулын җибәргәч, тәнен язып, җилкәләрен селкетеп, бөгелеп-сыгылып алды. — Кул ойый. Синнән, Зәкуан энем, күз генә тимәсен, ми-

ровой мастер чыгачак. Синең папиросың җиллерәкме әллә? Минем «Ракета» гына.

— «Беломор». Түш кесәдә.

— Витька әйтә, коммунистик хезмәт ударнигы булгач, тәмәкене ташларга туры килер, ди. Нужәли, тартырга ярамас икән, ә?

— Гомумән, тартуның бер файдасы да юк ул, Шәяхмәтов абзый.

— Соң, энем, гел генә файдалы әйберне эшләп булмый шул.

Ул буровойдан чыгып китте.

«Ә нигә эшләп булмый? Ни өчен кеше начарлык, әшәкелек эшли? Бу аның канында буламы, меңәр еллар буена килгән инстинктмы, әллә тирә-якның тәэсиреме? Фу-у, шундый аяз көндә әллә нинди күңелсез нәрсә турында уйлыйм». Ул дрелограммага карый. Долотога төшкән нагрузка — ун алты ярым. Әллә янә берне, юк, бер ярымны өстәргәме? Кара, шәйләп эшлә, егет. Ул беләген әкренләп җибәрә, педаль алга китә. Алар бүген егерме метрдан да ким бирмәячәкләр. Бу 250 процент дигән сүз! Эш шулай барса, бәлки 300 гә дә җиткерер.

Дан приказ ему на запад...

Ул дрелограммага карый: нагрузка 18 тонна!

Кайгырма, Миләүшә ханым, синең киявең дә озакламый мастер булыр, ә нефть исе бетмәс инде, калыр. Калсын, гарьләнерлек ис түгел әле.

Ялан гына җирнең күккүге юк,
Үз Уралкаема...

— Хәлләр ничек, Зәкуан энем!..
— Шәп.
— Тормозны бирәсеңме?
— Әйдә ял итә бир, Шәяхмәтов абзый.
— Алайса, тагы берне көйрәтим инде.
— Көйрәт. Минекен.

Шәяхмәтов, башта иплән кенә папиросның тәмәкеле башын яргаланып беткән майлы бармаклары белән йомшартты, аннан папиросның мөштеген баш бармагының тырнагына каккалады.

— Зәкуан энем... напрасны син инженерлыкка укымыйсың. Напрасны.

— Нигә? — Зәкуан кинәт уйларыннан арынды һәм айнып китте. Бу сүз аңа энә белән чәнечкәндәй, юк, лепкәгә таяк белән кундыргандай тәэсир итте.

— Обязательно инженер булыргамыни?

— Инженер инженер инде ул. Инженер булсам, менә мин шушылай йөрер идеммени?

— Нигә, тормышыңнан канәгать түгелсеңмени?

— Кәнишне, нәфсенең чиге юк, но... инженер инженер инде ул.— Ул, папиросын кабып, чыгып китте.

Инженер... Иртән Миләүшә апа (каенана!) шул сүз белән аның үзәгенә үткәргән иде, әле монысы. Инженер имеш... Булмаса? Һәм булмаячакмын да, һәм инженердан ким эшләмәячәкмен, яшәмәячәкмен. Ә нигә... теләсәм, инженер да, бәлки... профессор да булырмын. Булырмын шул! Профессорлар мөгезле буламы, әллә күктән төшәме... Шул чагында син ни әйтерсең икән, сөекле кае-

нанам? Югыйсә, кияүне должность-званиесенә карап эзлисең. Йөрәгенә һәм... беләгенә кара, Миләүшә апа...

Ул әкренләп беләген бушатканны һәм долотога нагрузканы арттырганны үзе дә сизмәде.

Ул арада Шәяхмәтов буровойга йөгереп керде.

— Зәкуан... Әллә шаштырып җибәрдеңме?

— Юк, нигә? — Зәкуанның күзе дрелометрга төште. — О-о, егерме ике тонна. — Бер генә секундка аның күзләре томанланды, шунда ук ике куллап тормозны үзенә тартты. Ләкин соң иде инде.

— Бетте, — диде ул, маңгаена атылып чыккан салкын тирне кепкасы белән сөртеп.

— Нәрсә?

— Авария.

— Авария? Китче!

— Шаулама. Әйдә, тормозны әкренләп җибәр әле. Я, я. — Ул тишәрдәй итеп квадратка карады. Квадрат аска да төшми, өскә дә күтәрелми, бер урында зырлап тик тора, вибрация дә арткан.

Зәкуан күзләрен чытырдатып йомып ачты: долото породаны кимерми иде.

— Туктат. Стоп! Туктатыгыз!

— Ни булды?

— Нигә туктаттың? — Аның янына эшчеләр җыелды.

— Инструментны күтәрергә кирәк, иптәшләр.

— Күтәрергә? Димәк, дүрт сәгать җилгә очты дигән сүз.

— Ярый ла дүрт сәгать кенә булса, — диде Зәкуан, кепкасын атып бәреп. — Проходка бетте. Долотога нидер булган.

— Ах нәләт... Шундый күңелле итеп эшләгәндә, — диде Витька Речкин квадратка сугып — әйтерсең, бөтен гаеп анда. Нәрсә булды соң? Кем гаепле?

— Мин, — диде Зәкуан, коры гына.

— Син? Брось! — Витька Речкин, ак тешләрен күрсәтеп, кул селтәде. Ул Зәкуанның ахмаклык эшләвенә түгел, ялгышуына да ышанмый иде. Зәкуан — Витька Речкин өчен идеал иде.

— Ярый, гаеплеләрне азак тикшерербез. Эшкә, егетләр, — диде Шәяхмәтов. Аның күзләрендә «их, инженер түгелсең шул, инженер булсаң, мондый эш эшләмәс идең» дигән сүзләрне ачык укып була иде.

Эшчеләр бер-берсенә күтәрелеп карарга кыенсынып, ашкынып һәм хәл җыймый эшләделәр. Ә шулай да мең җиде йөз метрлы шәмне күтәрү ике сәгатьләп вакытны алды.

Зәкуанның чамалавы акланды — долото зур басымга чыдый алмаган, бер шарошкасы сынып, забойга төшкән. Бу, иң аз дигәндә дә, дүрт-биш сәгатьлек эш иде. Ә күп дигәндә... Бер атналык. Менә сиңа рекорд! Менә сиңа мастер званиесе! Бөтенесенә дә шул чәчәк исеме йөртүче билчән — Миләүшә апа гаепле... Дурак син, Зәкуан. Ул бит азак гафу үтенгән һәм язылышырга рөхсәт иткән иде... Менә нәрсә, Зәкуан, үзеңне аклар өчен, беркайчан да эшләгән хатаңны яки ахмаклыгыңны кешегә якма. Хәтта, бу эштә башкаларның кысылышы, йогынтысы булса да. Үзең

эшләгәнсең, фәкать үзең җавап бирә бел. Мастер килгәнче аварияне бетерә алмасагыз, бөтен җаваплылыкны өстеңә ал. Күтәрә һәм түзә бел.

Өч сәгать буе алар забойда калган долото сыныгын эләктереп чыгарырга тырыштылар. Бу коега төшкән чиләкне багор белән алу кебек. Тик аерма шунда: бу «коеның» тирәнлеге мең җиде йөз метрдан артык, ә диаметры 8—10 дюйм. «Чиләк» тә йодрыктан аз гына зуррак.

— Давай, мастерга шалтырат,— диде Шәяхмәтов, түземлеге бетеп.— Эттәй арыдым, ачыктым.

— Әллә тагы әзрәк маташып карыйкмы?— диде Витька Речкин. — Моның өчен мастер баштан сыйпамас.

— Баштан ул, Витька, бәләкәй чакта гына сыйпыйлар. Давай, Зәкуан, шалтырат. Барыбер беләчәк.

Зәкуан культбудкага телефоннан шалтыратырга китте. Үзе белгәннән бирле Зәкуанның мондый ахмаклык эшләгәне юк иде. Әйе, әйе, ахмаклык, хаталану түгел, ахмаклык. Бер җилбәзәк бичәгә үзеңнең кешелегеңне күрсәтергә тырышу. Йөрәгеңә, хисләреңә хуҗа була алмау. Бая һәр янга калган сәгатьләрнең файдасын исәпләгән идең. Ә хәзер һәр җилгә очкан сәгатьнең бәһасен исәплә. Мастерның квартирасы дәшмәде. Зәкуан будкадан чыккач, күккә карады — ул чалт аяз иде. Күкнең йөзендә кайгы-хәсрәтнең әсәре дә юк иде. Их, күктәй булса иде күңелең. Ярый, суга интеккән тал кебек бөгелмә. Аварияне үзең ясагансың, үзең бетер.

Ул арада мастер килеп җитте. Аның күңеле көр, йөзе якты иде.

— Эшләр ничек, бөркет балалары? Нигә туктадыгыз?

— Эшләр мөшкел, мастер, — диде Шәяхмәтов, тиеш булмаса да бораулаучыдан алдан. — Долотоның шарошкасы сынды.

— Да-а.

Яңалык мастерның кәефен боза алмады, яки бозылса да сиздермәдеме. Егерме алты ел буе мастер булып эшләү дәверендә ул аз авариялэр күрмәде. Баштарак каушый, чәбәләнә, коелып төшә торган иде. Бара-бара ул күнекте, юк, бу дөрес сүз түгел, аварияга күнегеп булмый. Ул нервысына хуҗа була башлады. Халык ул белеп әйтә, авырлыклар кешене чыныктыра. Ә соң юкка чәбәләнүдән ни файда, авария үзеннән-үзе бетми бит.

— Авария бүген бетерелергә тиеш,— диде ул, — югыйсә, графиктан чыгабыз.

613 тәге хәлне ишетеп, өлкән инженер Кашапов та килеп җитте. (Ул гына җитмәгән иде!)

— Ишкәнсез ишәк чумарын, — диде ул, эшчеләрнең кулларын сүзсез генә кысып, ә Зәкуанга йодрык күрсәтеп алды.— Бүген-иртәгә коммунистик хезмәт бригадасы исемен алырга торасыз. Кем шулай гамьсез кылана?

— Мин, — диде ашыгып Шәяхмәтов. — Бораулаучы Локманов тәмәке тартырга чыгып киткәч, долотога нагрузканы арттырып ташлаганмын.

— Ялгышмы, юриме?

— Юри, иптәш Кашапов. Йөрәк ашкынды. Скважинаны тизрәк очлыйсы килә.

— Дөрес түгел, иптәш Кашапов. Түгел. — Зәкуан алга чыкты. Шәяхмәтов аның брезент курткасының итәгеннән тартты.

— Нәрсә дөрес түгел, Зәкуан?— диде Кашапов сагаеп.

— Башта аварияне бетерик, аннан аның сәбәпләрен һәм сәбәпчеләрен тикшерербез.— Мастерның тыныч, иптле тавышы кайный башлаган казанга салкын су салды.

— Ну сине, Шәяхмәтов, — диде Кашапов шелтәләп тә, горурланып та. — Иллене үтсәң дә, егетләр кебек тәкатьсезсең. Ашыккан ашка пешкән, дип синең кебекләр хакында әйткәннәрдер инде. Кара, соңгысы булсын, Шәяхмәтов. Яхшы түгел. Ярый да графиктан чыкмасагыз. — Ул Зәкуанның колагына пышылдады. — Эштән соң безгә кагылып чык.

Төн уртасында гына алар каһәрле шарошканы эләктереп чыгардылар. Унике сәгать вакыт әрәмгә китте. Бу, ким дигәндә, утыз метр проходка иде. Куып җитеп булырмы, юкмы? Булмаса, алар трестта беренчелекне Сидоров бригадасына бирәчәкләр.

Бөтен бригада бу скважинаны ниндидер аеруча дәрт, илһам белән бораулаган иде. Геологлар да, бу бәхетле скважина булырга тиеш, дип вәгъдә иткән иделәр. Дөрес, мәңгелек белән чагыштырганда унике сәгать вакыт кош канат каккан кебек кенә. Ләкин кешенең гомере озын түгел, бу — бер, икенчедән, һәр бригада уникешәр сәгатен югалта башласа, ничәмә мең тонна нефть җир астында калачак... Кыскасы, кайсы гына яктан ка-

расаң да, яхшы түгел. Бер кешенең эгоистлыгы бөтен бригадага, бөтен конторага, әйттерәсең килсә, бөтен илгә зыян китерә. Их, Зәкуан, Зәкуан, комиссар малае. Әтиең моның өчен сине колагыңнан сөйрәп йөртер иде... Бәхетең, ул юк. Бәлки, ул булса, Зәкуан болай да эшләмәс иде. Ә Шәяхмәтов, солдат кебек, үз гәүдәсен пуля астына куеп, командирын коткарып калмакчы була. Юкка. Ул хәзер бөтенесен дә башта Шәфиевкә, аннан бөтен бригадага сөйләп бирер. Җүңелле эш түгел, ни эшлисең, руслар, үзең пешергән бутканы үзең аша, диләр бит.

— Иптәш Шәфиев, минем сиңа сөйлисе сүзем бар.

— Иртәгә. Бар, кайтып хәл җый. Йөзеңә мәет төсе чыккан. Артык борчылма. Моннан соң акыллырак булырсың. Бәлки куып җитәрбез әле, — диде мастер, аны юатып. — Бар, бар.

— Минем бүген, хәзер сөйлисе сүзем бар, иптәш мастер.

— Һәй алла, иртәгә дә качмас әле, — диде Шәяхмәтов аны култыклап. — Гаеп миндә. Җирәк икән, эш хакыннан тотып калырлар. Хәзер башымны ташка оралмыйм инде. Кая, папирос бир.

Алар буровойдан чыктылар.

— Син нәрсә, энекәш...

— Ә син нәрсә, абзый, гаепне үзеңә аласың? Мин синнән моны сорамадым да һәм... бу дөрес тә түгел, теләмим дә.

— Тсс-с... — Шәяхмәтов аның җиңеннән тотты. — Ярсыма, энем. Башта тыңла. Минем җилкә,— ул көрәк кебек кулы белән юан, көч-

ле муенына сукты,— түзәрлек. Хотя, эш җилкәдә генә түгел. Мин мастер булырга җыенмыйм. Срок үткән. Өч елдан, исән булсам, пенсиягә чыгам. Ә сиңа эшләргә дә, эшләргә әле. Ярый, син, аварияне мин ясадым, дип әйттең, ди. Шуның белән ни кырасың? Бу сиңа чүп кенә булачак. Мастерлыкка аттестацияләгәндә үзеңә бәйләнәчәкләр. Үзең беләсең, хәзер бик строгы — энә күзеннән үткәрәләр. Канишне, син алдашырга өйрәнмәгәнсең. Ә мин өйрәнгәнмени? Бу, әйтергә яраса, бәләкәй генә хәйлә. Ә хәйләсез дөнья файдасыз. Юк, энем, мәкаль бер дә искермәгән әле.

— Минем йөрәк әрни, Шәяхмәтов абзый...

— Аңлыйм, канишне. Әрнесен. Әрнемәсә гаҗәп булыр иде. Тсс-с. Витька килә. Бир әле янә бер папирос, канәгатьләнмәдем.

— Нигә мине көтмәдегез? — диде Витька Речкин, аларның уртасына кереп. — Уф-ф, бер болай арыганым юк иде. Ну эш ясадың син, Шәяхмәтов. Ул бит сиңа сабан туенда элеп алып, селкеп салу түгел. Техника! Баш кирәк, баш.

— Витька, давай, син монда сабан туен кыстырма. Мин бит синең футболыңа сүз тидермим, — диде Шәяхмәтов ачуланып. — Беләсең килсә, көрәшү өчен дә баш кирәк.

— Баш, әлбәттә, һәр җирдә кирәк. Ярый, хәтерең калмасын, болай гына әйткән идем.— Витька аның беләген тотып карады. — О-о, тимермени!

— Корыч. Әллә алышып карыйбызмы?— диде Шәяхмәтов яшьләрчә һәвәсләнеп.

— Давай. Әйдә, әнә тегендә, фонарь яктысына.

— Ярый инде, бүгенгә куеп тор. Арыткан. Хушыгыз, егетләр. — Ул «алтынчы» номерга утырып, кайтып китте.

Зәкуан Нәркәсләргә барырга кыймады. Арыткан да. Салкын душта юынды да, урын җәяргә иренеп, диванга ауды. Нинди бәхетле башланган иде бу көн. Дөньядагы бер көч тә ул бәхетне җимерә алмас кебек иде.

Озын бер гомергә җитәрлек вакыйгалар... Ә ни бары бер тәүлек үтте. Өйләнү шатлыгы... Никах бәласе... Миләүшә апаның мыскыллавы... Рекорд куям дип ашкыну, авария, аны бетерү.

Арытса да, йокы килмәде. Әйтерсең, йокы аннан шикләнеп йөрде. «Эгоист һәм өстәвенә куркак син, Зәкуан. Нигә скважинадагы аварияне бетердең, ә йөрәгеңдәгесен бетерә алмадың? Куркак, куркак...» Баш мең кисәккә чатнады, йөрәк әллә нишләде, бер ярсыды, бер тынды. «Фу-фу, әллә акылдан язам инде». Ул, уйларыннан арынырга теләп, балконга чыкты. Ә күк, үткән төндәге кебек, ерак һәм җылы иде. Үткән төндәге кебек, төрле якка серле һәм сихерле «каз юллары» сузылган. Йолдызлар, тәнәфес вакытындагы укучы балалар кебек, шаяралар, куышалар. Ә ай, әдәпле кыз шикелле, мөлаем генә елмаеп, аларны күзәтеп йөри. Юк, алар берсе дә Зәкуанның хәсрәтен аңламый. Ул мендәр, ике одеял алып чыгып урын җәйде дә, кулларын баш астына куеп, чалкан ятты.

Бәлки мин юкка өзгәләнәмдер. Бригада графикка керер, Күчмә Кызыл байрак алыр,

Коммунистик хезмәт бригадасы исемен бирерләр. Күп тә үтмәс, бәхетсез унынчы августны искә алучы да булмас. Әлбәттә. Ярый, башкалар оныттты, ди. Ә соң ул үзе оныта алырмы? Коммунистик хезмәт ударнигы — ул хезмәт ударнигы гына дигән сүз түгел. Бу исемне алу өчен һәр җирдә: эштә һәм өйдә, урамда һәм клубта, ялда һәм юлда коммунист булырга кирәк. Кыланышың, эшең, холкың белән генә түгел, уйларың белән дә коммунист бул. Шулай булмасаң, нигә ул бөек исемне йөртеп, кешеләрне һәм үзеңне алдарга... Иртәгә эшкә баргач та, ул бөтенесен дә сөйләп бирәчәк.

Кичен ул үз-үзенә сүз бирде, ә иртән сүзендә тора алмады. Ярый, сөйләр. Ә нәтиҗә! Витька Речкин: «Хурлык! Мин сине дан өчен иптәшләрен хур итәр, дип уйламаган идем»,— дип кычкырыр. Ә мастер әрләмәстиргәмәс, үгет-нәсихәт сөйләмәс, «и-их, комиссар малае», дип көрсенеп кенә куяр. Юк, лутчы ул әрләсен, каты сүзләр әйтсен, ләкин атасын искә алмасын. Бәлки алмас та... «Әгәр әти исән булса, мин мондый акылсызлык эшләр идемме?»— дип сорады ул үз-үзеннән. Нигә, ахмаклыкны фәкать ата-анасыз балалар гына эшлимени? Әнә, былтыр «Комсомольская правда» газетасында... Их, Зәкуан, Зәкуан, һаман бер юл — аклану юлы гына эзлисең. Тор, киен һәм барып мастерга бөтенесен дә сөйләп бир.

Ул Шәфиевләр ишеге төбендә икеләнеп озак кына торды: керергәме, кермәскәме? Килгәч керергә, кергәч сөйләргә. Мастер төнге звонокка аптырамады. Гомумән, аның өчен

төн белән көн дигән төшенчә юк. Ул, посттагы солдат кебек, һәрвакыт уяу.

Ә шулай да Зәкуанның таң алдыннан килүе аны каушатты.

— Нәрсә, тагын авариямe?

— Юк.

— Нәрсә күңелең китек? Чишен. Түзәргә өйрән, энекәш. Түзә белү — зур нәрсә ул. Чәй куйыйммы?

— Рәхмәт, кирәкми. Иптәш Шәфиев... Гаеп миндә. Аварияне Шәяхмәтов түгел, мин ясадым.

— Синең смена ясагач, син ни, Шәяхмәтов ни — барыбер бит.

— Түгел.

— Соң юри ясамагансыңдыр бит?

— Юри түгелен түгел, ләкин гаеп миндә.

— Ярый, гаеп синдә, ди. Чишен дә залдагы диванга кереп ят.

— Рәхмәт. Мин кайтам.

— Кайтмыйсың, — мастерның тавышы каты чыкты. — Мин сиңа эштә мастер булсам, өйдә әти... Чишен. Шагом-марш. Бар, бар.

Ни чаклы тырышсалар да, бригада графикка керә алмады һәм беренчелек тә аларга эләкмәде. Дөрес, алар скважиналарын унике көнгә срогыннан алда очладылар, ләкин күңел тыныч түгел иде: беренчелек һәм аның символы Күчмә Кызыл байрак кулга кермәде. Моңа Зәкуан гаепле. Эшчеләр моны Зәкуанга сиздерергә тырышмадылар, яки Зәкуанны гафу иткәннәр — дөнья булгач була бит инде. Бу, бер карасаң, әйбәт тә — гафу итә белү өчен дә хуш күңелле булу кирәк; икенче карасаң, начар да — йомшаклык бил-

гесе. Ничек кенә булмасын, авария хакында искә алучы булмады. Һәм менә бүген, унсигезенче август иртәсендә, өч вахта да эшкә берьюлы килде. Йөзләр шат һәм азрак сагышлы. Мотор гүләми, турбобур әйләнми, вышка очында верховой Янтурин күренми. Әйтерсең, скважина үлгән. Юк, ул үлмәгән. Аңа хәзер җан керәчәк һәм ул бик озак еллар кан тамыры кебек тибәчәк. Бүген «613»не промысловикларга тапшыралар. Бу һәрвакыт дулкынландыргыч бер тантанага әйләнә. Нәкъ менә яңа корабны стапельдән төшереп, ерак сәяхәткә озаткан кебек инде. Һәркем шатлана, азрак каушый һәм азрак моңая.

Тапшыру һәм кабул итү актына кул куелгач, ике яктан да кыска һәм җылы сүзләр сөйләнелде.

— Фонтан гомерегез буена җитсен, сулмасын, — диде мастер Шәфиев.

— Тагын шундый бай скважина бораулагыз, — диде оператор Бану Гиниатова.

Ә монтажниклар кырык бер метрлы металл вышканы сүтә дә башладылар. Бөтенесе дә тыныч кына, күңелле генә үткән иде, әлеге дә баягы Витька Речкин эшне бозды.

— И-их, Шәяхмәтов авария ясамаган булса, Күчмә Кызыл байрак безнеке була иде...

Зәкуанның түземлеге бетте.

— Куегыз. Бәйрәм көнне үткәнне искә алып, кәефне бозмыйк. Кемнең тартырга бар?

Бу мастерның яраткан гадәте — эшчеләр үзара төрткәләшә башласа, ул юри эшчеләрдән тәмәке сорый. Тегеләр, бер-берсен узарга тырышып, аңа тәмәке, папирос сузалар, үзләре

көйрәтәләр һәм килешәләр. Юкка гына махорка солдатны дуслаштыра, дип җырламаганнар фронтта.

— Кич сигезгә, бер минутка соңламый, клубка киләсез. Карагыз, өс-башыгыз бәйрәмчә булсын.

— Бирәләрме?— дип сорады берничә кеше.

— Бирәләр.

— Ур-ра!.. Витюшка, ал аккордеоныңны. Коммунистик бригада ударникларының ничек эшләгәннәрен генә түгел, ничек биегәннәрен дә күрсеннәр. Зәкуан, бас «Перовскийга»...

Шушы вакыт тыны-көне беткән Нәркәс буровой янына йөгереп килеп җитте.

— Нәркәс!..

— Кызым...

— А-а, килен... Әйдә, уртага төш.

Нәркәсне сырып алдылар. Ул Зәкуанга чагардай итеп карады да: «Витюк, уйна переплясны» дип кычкырды.

Башта ул аккош кебек йөзде, аннан гармоньчы алдында яшь колындай тыпырдады, озын, матур муенын бер уңга, бер сулга борып, егетләргә утлы караш ташлады һәм берничә тапкыр чүгәләп, «эһ-эһ!» дип кычкырды. Кулларын биленә куеп, ул аякларын юньләп җиргә тидерми кругны әйләнеп чыкты да гармоньчы каршысына басты һәм кулларын артка күчереп, аяклары белән сигезле ясыйясый арты белән барды... «Кемгә басар икән, кемгә?— дип уйлады Зәкуан.— Кемгә булсын, әлбәттә, аңа. Ә алайса нигә аңа кул да бирмәде? Ә син нигә атна буе аңа күренергә дә куркып йөрдең? Куркак! Хәзер аны гаеплә-

мәкче буласың». Һәм ул, я миңа басмас дип, шүрләп, үзе биеп китте.

— Һайт, шулай!

— Вот, молодец!

— Кияү, бирешмә!

— Килен, калышма!

— Өздер-типтер!

— Вышканы аудармагыз!

— Аусын, хәзер барыбер аның кирәге юк.

Зәкуан мәйдан уртасында, урыныннан аз гына да кузгалмыйча, күз иярмәслек тизлектә аякларын тыпырдатып торды, Нәркәс, лампа янындагы күбәләк кебек, аның тирәли әйләнеп йөрде.

Уен-көлке беткәч, эшчеләр өйләренә таралыштылар.

Нәркәс белән Зәкуан җәяү кайттылар. Арадагы үпкәне бию бетергән иде, ләкин ике як та башлап сүз әйтергә кыймады.

— Зәкуан...

— Нәрсә, Нәркәс?

— Әйдә чәчәк җыябыз. Мин август чәчәкләрен нигәдер бик яратам.

— Нәркәс...

— Нәрсә, Зәкуан?

— Син мине аңларсың микән... Мин... сине дә, иптәшләремне дә, үземне дә хур иттем.

— Аварияне син ясадыңмы?

— Ә син аны кайдан белдең?

— Белмәдем, сизендем.

— Син мине гафу ит, Нәркәс...

— Мин нишләптер соңгы көннәрдә кинәт җитдигә әйләндем, Зәкуан. Егерме бер ел уйламаганны бер атнада уйладым. Матур сөйләвем өчен гафу ит. Яшәү океанын җилкәнле

көймәдә генә кичеп булмый икән. Моның өчен зур кораб, атомоход кирәк.

— Димәк, син мине гафу итмисең?

— Авария өчен гафу итәргә була, ә куркаклыгың өчен...

— Аңлыйм, Нәркәс...

Алар сүзсез генә бардылар. Нәркәс, чалмабаш өзеп алып, аңа өрде. Кулда чалмабашның борчак чаклы күксел шәрә башы гына торып калды, уклардан торган чалмасы очып төште.

— Ә хәзер миңа нишләргә, Нәркәс? Бүген кич клубта бу хакта сөйләсәм, бригадага коммунистик хезмәт бригадасы исемен бирмәүләре бар, сөйләмәсәм... алдашу була. Мин ул исемгә лаек түгел.

— Хәзер үк гариза яз да бригададан кит.

— Мин моны эшли алмыйм, Нәркәс. Бу дезертирлык була.

— Дезертирлык иптәшләреңне авыр хәлдә ташлап качу була, ә син иптәшләреңне бәладән коткару өчен китәсең.

— Барыбер.

— Син тагын үзеңә җиңелрәк юл эзлисең, Зәкуан. Әйе, әйе. Сиңа бригададан аерылуы авыр, ә бригаданы хурлыкка калдыру җиңел.

— Юк, җиңел түгел. Мин бит синең алда яхшырак булырга тырышып шушы көнгә төштем.

— Ә миңа синең ничек күренүең түгел, ничек булуың кирәк,— диде ярсып Нәркәс.— Кызганычка каршы, байтаклар иң элек ничек күренү хакында ныграк уйлыйлар. Кешенең эче дә, тышы да бер төсле булырга тиеш.

— Аңлыйм. Син хәзер мине куралмыйсың. Мин дә синең урында шулай булыр идем. Хуш.

— Кая киттең?— Нәркәс анын кулыннан тотты.

— Вахтовойга утырам.

— Ашыкма. — Ул, юл уртасына чыгып, яшел күзле таксины туктатты.

— Нәркәс, минем янда акчам юк.

— Минем бар.

— Уфа урамына, — диде Нәркәс шоферга.

— Нигә, сез күчтегезмени?

— Әйе.

— Ничәнче йорт?

— Номерын хәтерләмим.

— Син шаяртасың.

— Шаяртам. Мин бит җилбәзәк.

— Нәркәс...

— Азак. Шофер, әнә теге биш катлы йорт янында туктагыз. Паспортың яныңдамы, Зәкуан?

— Янымда. Нигә?..

— Укы. — Нәркәс биш катлы йорттагы вывескага күрсәтте.

— ЗАГС... Соң, минем өстә спецовка бит.

— Күңелнең пакьлыгы киемнең тазалыгына карамый.

— Нәркәс... Бәгырем...

ЗАГС бүлмәсе матур җыештырылса да җансыз иде. Ике почмакта ике фикус, стенада Нарыш тавы һәм баласын имезеп торган ана сурәтләре. Өстәлдә былтыргы «Здоровье», «Работница», «Азат хатын» һәм чәчәкләр үстерү хакындагы журналлар ята.

Зәкуаннар керү белән, өченче яшьлеген яшәүче, чаманы онытып бизәнүе аркасында үз яшеннән олырак күренүче ханым радиолага яңа пластинка куйды — Лолита Торрес испан телендә мәхәббәт турында җырлады. Аны «Төнге Урал» алмаштырды, инде ир белән хатынга әйләнгән Зәкуан белән Нәркәсне «онытмагыз чакырырга бәбәй туегызга да» дигән дәртле, шаян җыр озатып калды.

Такси китмәгән иде.

— Сез безне көттегезме? — диде Нәркәс шоферга, аптырап та, сөенеп тә.

— Әйе. Раз ЗАГСка кердегез, значит, чыгарга да тиешсез. Котларгамы?— Кысык күзле, киң битле, гел генә елмаеп торучы шофер машина ишеген ачты. — Рәхим итегез.

— Сез безнең кияү егете булырсыз инде, — диде Зәкуан, шоферның кулын кысып. — Туйга обязательно чакырабыз. Кайда торасыз?

Кич клубка алар дүртәүләп, каенатасы, каенанасы, Зәкуан һәм Нәркәс бардылар. Миләүшә апа юл буе, песи кебек, шым гына утырды, ә Кашапов өзлексез такылдады, үзенең яшьлеген, өйләнгәч булган мәзәкләрен сөйләп көлдерде.

— Сентябрьдә Шәфиев Себергә китә. Ике елга. Сине аның урынына калдырабыз, Зәкуан. Ризасыңмы?

Сүзсез барган Миләүшә апаның кинәт теле ачылды:

— Риза булмыйни. Кем мастерлыктан баш тартсын инде. Шулай бит, кияү.

— Нигә телеңне йоттың, Зәкуан?— диде Кашапов. — Әллә шүрлисеңме?

— Юк...
— Шулай булгач!..
— Иптәш Кашапов...
— Иптәш түгел, ә каенатай. Я?
— Сез...
— Сез түгел, син...
— Егетләр, әйдәгез җырлыйк! — Нәркәс атасының һәм Зәкуанның муеныннан кочаклап алды. — Зәкуанның анасы, синең кодагыең, яраткан җырны, әти.

Дан приказ ему на запад,
Ей в другую сторону,
Уходили комсомольцы
На гражданскую войну...

— И-их, беркайчан да, бер җирдә дә кан түгелмәсә иде. Врач булырга җыенам, ә кеше каны күрсәм — коелам да төшәм.

— Кызым, тапкансың сөйләр сүз,— диде Миләүшә апа борылып, аның кулын сыйпап.— Мондый көндә йолдызлар, чәчәкләр хакында сөйләшергә кирәк.

Кичәдә музыка һәм көлү-шаяру күп булды. «Коммунистик хезмәт бригадасы исемен кушарга» дигән карарны, кызыл ледерин папкага салып, мастер Шәфиевкә тоттырдылар. Музыка туш түгел, гимн уйнады. Һәрвакыт тыныч, хәтта гамьсез Шәфиев дулкынланды, тамагына утырган төенне көчкә-көчкә генә йотты.

— Рәхмәт, иптәшләр. Рәхмәт, дуслар. — Ул сафта тезелеп торган бригада членнарына таба борылды. — Сезнең аркада без бу горур исемне ала алдык. Карагыз... — ул йодрыгын төйнәп алды, елмайды.— Себердә маңгай

күзләрем белән күрмәсәм дә, күңел күзем белән күзәтеп торырмын. — Дөньяда беркайчан да эшче кешегә мондый бөек исем бирелмәгән. Карагыз, егетләр... Зәкуан, тот. Мин сиңа, үземә ышанган кебек, ышанам.

Зәкуан сул кулы белән кызыл тышлы папканы алды, уң кулы белән мастерның кулын кысты.

Витька Речкин:

— Хас Кремльдә, орден тапшыргандагы кебек, — дип пышылдады.

— Иптәшләр...

— Сөйлә, сөйлә, яшь мастер. — Шәфиев Зәкуанның җилкәсенә авыр кулын җиңел итеп куйды.

Зәкуанның күзе Нәркәскә төште. Ул иренә бетмәс-төкәнмәс мәхәббәт белән карап тора иде — әйтерсең, ул мәхәббәт мең елга җитәрлек. Зәкуаң елмайды. Нәркәс янында торган Миләүшә апа да елмайды. «Мондый көндә чәчәкләр, йолдызлар хакында гына сөйләшәләр» дигәнне аңлата иде аның күзләре.

— Иптәшләр... Мин бу папканы... дөресрәге, бөек исемне иптәш Шәфиев кулыннан алганчы шуны әйтергә телим. Үзегез беләсез, без авария ясадык. Ләкин берегез дә аның сәбәбен белми. Юк, сез мине бүлдермәгез. Мин бүгенге тантананың ямен җибәрергә җыенмыйм. Мин сезгә йөрәгемне ярып салам. Һәм сездән скидкасыз сорыйм: Мин коммунистик хезмәт ударнигы булырга лаеклымы?

Һәм ул авария сәбәбен сөйләп бирде. Дөрес, ул монда никах хакында бер сүз дә әйтмәде, әмма Миләүшә апа шунда ук, битен

каплап, клубтан чыгып китте. Шыгрым тулы зал берничә секунд тып-тын торды. Тик стена сәгате генә ачуны китереп текелдәде. Һәм, кинәт, кырмыска оясына таяк тыгып бутадылар. Берьюлы унлаган кеше кычкырып сөйли башлады. Берьюлы унлаган кул һавага күтәрелде.

— Сүз бирегез.

— Председатель, мин сөйлим...

Җыелыш төн уртасына чаклы дәвам итте. Зур, принципиаль мәсьәләләр тикшерелде бу кичтә. Кешеләр бер-берсенең җитешсезлекләрен сөйләп кенә чикләнмәделәр, үзләренең кимчелекләре турында да ихлас сөйләделәр.

— Иптәшләр, — диде җыелышны ябып, партбюро секретаре (заманында ул да комиссар булган) Федоров. — Бу күпләргә, юк, барыбызга да гыйбрәт булырлык кичә. Скважинадагы метраж белән генә мавыкмыйк. Хәзер бу безнең өчен буй җитмәслек проблема түгел. Без коммунизм төзибез. Без бөек җидееллыкны штурмлыйбыз. Димәк, без кристалл кебек сафлык өчен көрәшергә тиешбез. Дөрес, коллектив — бөек көч, әмма һәркем үз-үзен дә тәрбияләргә, камилләштерергә тиеш. Дөньяда иң хак һәм шәфкатьсез судья үзеңә үзең. Иң элек син үзеңне үзең хөкем ит. Шулай булмаганда коллектив хөкеменең нәтиҗәсе бәләкәй. Без бүген шушы хөкемнең шаһиты булдык. Дөрес, бораулаучы Локмановның гаебе зур, ләкин без аңа бертөрле дә җәза бирмик. Ул үзенә үзе приговор чыгарган инде. Ә мастерлыкка аттестацияләргә сабыр итик. Янә бер скважина бораууласыннар әле. Аннары күз күрер. Сезне зур, җаваплы, гүзәл

исем белән котлыйм һәм эшегездә уңышлар телим, иптәшләр.

Һәм менә алар: Зәкуан һәм Нәркәс җитәкләшеп кайтып килә. Август төне зәңгәр һәм ягымлы. Тирә-якта электросварка очкыннары чәчрәп китә, паровозның нигәдер ачуланып кычкырганы ишетелә, тау итәгендә мотор гүли, су буенда кызлар көлә. Кемдер, радиоласын тәрәзә төбенә куеп, Сәйдәшев маршын уйната һәм кайдадыр имчәк баласы елый. Җирдә гадәттәге катлаулы һәм буталчык тормыш дәвам итә. Ә күктә... анда тормыш бар микән? Бәлки, Марста яки әнә теге «Каз юлындагы» йолдызларның берсендә, Зәкуан белән Нәркәс кебек, ике гашыйк җиргә елмаеп карап, серләшеп йөриләрдер. Бәлки, анда күптән коммунизмдыр һәм аварияләр дә юктыр.

— Кызык, барып күрсәң иде...

— Нәрсәне, Зәкуан?

— Коммунизмны, Нәркәс.

— Обя-за-тель-но күрәчәкбез. Әйдә җырлыйбыз, Зәкуан.

— Әйдә...

Агыйделгә басма салдым,
Каенын сайлап кына;
Яннарыңа кайтачакмын
Кош булып сайрап кына, Зәкуан...

Әйе, августтан да матуррак ай юк бу дөньяда. Табигать тә, кешеләр дә өлгерә. Ә битен сабынлап юган күк, моңа шатланып, салют бирә, йолдызлар ата. Бәхет йолдызлары...

БЕР МӘХӘББӘТНЕҢ ЯЗМЫШЫ

— Гәүһәр Мозафаровна үзендәме?

— Әйе.

— Кәефе ничек? Вакытлы-вакытсыз йөрисең дип тиргәмәсме?

— Юк ла.

— Нигә шул чаклы ышанычлы әйтәсез?

— Чөнки аның өстәлендә шомырт чәчәге тора.

— Торса ни?

— Шомырт чәчәге язны аңлата. Димәк... аның күңелендә дә яз. Яз... Яз да була, көз дә була, су читләре боз була... Кәрегез.

— Их, ел буе яз булса иде...

* * *

Сугыштан соңгы язларның берсе иде. Әле «хәбәрсез югалган»нар да кинәт кайтып төшеп, гаиләләрен, дус-ишләрен шаккатыралар; әле дары һәм окоп исе сеңгән шинельләр дә пальтога алыштырылмаган, әрем, сарут баскан кысыр яланнар тулысынча сөрелеп, чәчелмәгән; әле көтү өметләре өзелмәгән.

Яз килә иде. Шаулап, очынып, ярлардан ярсып чыгып, сахраларга гөлләр сибеп, күңелләргә хисләр түгеп яз килә иде. Әнә шундый көннәрнең берсендә алар район культура йор-

тының сәхнәсендә очраштылар. «Галиябану» аларны очраштырды. Район *җир бүлегенең* баш агрономы Гәүһәр Низамова Галиябануны, ә юл бүлегенең тракторчысы Зәки Өметбаев Исмәгыйльне уйнады. Район газетасының секретаре Гомбагашев: «Долой драмалар. Фронтовикларның нервлары болай да теткәләнеп беткән. Аларга эчең катарлык җиңел комедияләр генә кирәк», — дип постановканы сүгеп чыкса да, халык «тәнкыйтьче»нең сүзен бар дип тә белмәде. Көненә мең тапкыр үлемнең ач күзләренә караган солдатлар, елый-елый күз яшьләре кипкән солдаткалар Хәлил белән Галиябануның бәхетсез мәхәббәтләренә чын күңелдән ышанып, тетрәп утырдылар. Галиябану Хәлилнең җансыз гәүдәсенә ташлангач, кемдер аның аяк очына зур бәйләм шомырт чәчәге ыргытты. Тамашачылар аягүрә басты. Буран кебек көчле алкыш күтәрелде. Ә бераздан Галиябану сәхнә артында тар, тынчу урында, үзенең «кан дошманы» Исмәгыйльгә ташланды һәм, сөлек кебек, аның иреннәренә ябышты.

— Сиздермәм дигән идем. Белдермәм дигән идем. Йөрәгемә сеңдереп, югалтырмын дип, көненә йөз тапкыр ант иткән идем. Түзә алмадым... Гафу ит...

Бик буйсына инде мәхәббәт синең антыңа. Ул чәчәк кебек бит, ташларны урталай ярып, кояшка омтыла. Гәүһәрнең сүнеп барган йөрәгенә көчле кан ургылды, сагышлы күзләренә, әйтерсең, язгы йолдызлар төшеп утырды.

Ул райсоюздан ведомость буенча алган авыр, тупас кирзовый итекләрне сөйрәп, дым-

лы, йомшак басуларда йөрде, арыды, ачыкты, әмма күзләрдә нур, күңелдә җыр иде. Ат булмаса җәяү, төн уртасында йөгерә-атлап, район үзәгенә кайтты. Урау булса да, Зәкиләр урамыннан үтте, аларның йорты каршында үскән шомыртның чәчәген өзеп, түшенә, чәчләренә кадады һәм ишетелер-ишетелмәслек итеп, үзе өчен генә җырлады:

Өй артында шомыртым,
Яннарында чияләр.
Чияләр дә миңа карап,
Их, бәхетле, дияләр...

Инде күптән эштән кайткан Зәки чишенми генә кроватьта ята. Тәрәзәләрдән өйгә ай нуры түгелә. Колакта көн буе гүләгән трактор тавышы тора. Күз алдында очы-кырые күренмәгән юллар сузылган. Алар, учтагы сызыклар кебек, төрле якка таралган. Килер бер көн — ул юллар күңел кебек киң, өстәлсымак тигез булырлар. Ә хәзергә әле алар сикәлтәле, чокыр-чакырлы...

Арыткан, ләкин йокы алмый. Күрәсең, бөтен замандагы гашыйклар да шулай йокысыз интеккәннәрдер. Ул тора, песи кебек сизгер йоклаучы анасын уятмаска тырышып, иплэп кенә тәрәзәдән чыга. Башка, беләкләргә шомырт чәчәгеннән салкынча чык коела. Тынлык. Гүзәл, зәңгәр тынлык. Чү. Бакча коймасы янындагы скәмьядә кемдер утыра түгелме соң. Әйе. Йоклый. Рәхәтләнеп йоклый. Бахыркай, өенә дә кайтып җитә алмаган. Арыгандыр. Кем икән ул? Гәүһәр бит ул. Гәүһәр... Бахыркай...

Зәки иплэп кенә аның янына утыра. Аның тигез, рәхәт тын алганын тыңлый. Гәүһәр,

төш күрепме, әллә аның барлыгын сизепме, сискәнеп китә һәм сикереп тора.

— Зәки...

— Гәүһәр...

— Зәкием...

— Гәүһәркәем...

Алар кочаклашалар һәм башларын берберсенең чигәләренә куялар. Тагын тынлык урнаша. Тик еракта гына ялгыз трактор, төнге тынлыкны бозмаска тырышып, әдәпле гүли һәм су буеннан көр, ачык тавышлы кызның гамьсез көлгәне ишетелеп кала.

— Арыдыңмы?

— Үлеп.

— Утырабызмы?

— Утырабыз.

— Гәүһәр...

— Эндәшмә...— Ул Зәкинең киң, ышанычлы күкрәгенә башын куя. — Йөрәгең нинди шат, ярсып тибә, Зәки. Яле, йодрыгыңны төйнә. О-о, нинди зур икән синең йөрәгең...

— Гәүһәр...

— Эндәшмә.

Зәки, аны беренче тапкыр күргәндәй, зур, соры күзләренә сокланып та, гаҗәпләнеп тә карый. Гәүһәр дә күзләрен йоммый, Зәкинең киң, текә, маңгаена, вакытын белми агарган бөдрә чәчләренә, акыллы, сагышлы кара күзенә карый һәм аның муеныннан кочаклый, битен аның битенә куя.

— Беләм. Синең ни әйтергә теләгәнеңне беләм, бәгърем. Тиздән. Озакламый. Чәчү беткәч тә өйләнәбез. Ә быел чәчүне, син беләсеңме, былтыргыга караганда бер атнага элегрәк бетерәбез. Син авызыңны ерма, аю, бер ат-

нага элек дигән сүз—йөзәр меңләгән пот игенне артык алу дигән сүз ул. Руслар: «Весенний день год кормит», — диләр. Ә бер-ике елдан без сугышка кадәр алган уңышны алачакбыз. Нефтьчеләргә рәхмәт. Алар ярдәм итә. Я кем безнең беленер-беленмәслек сыртлар астында нефть диңгезе ята дип уйлаган инде, ә? Девон карт диңгезе...

— Академик Губкин уйлаган, аның шәкертләре,— ди Зәки, Гәүһәрнең бодай саламы төсле йомшак, дымлы чәченнән сыйпап.

Гәүһәрнең атасы зәңгәр күзле, сап-сары чәчле татар булган, ә анасы Оренбург ягы башкорты. Менә шуңа күрә Гәүһәр ни зәңгәр, ни кара күзле түгел, ә соры күзле — әйтерсең, кара буяу белән зәңгәрне салып бутаганнар. Чәче дә ни атасыныкына, ни анасыныкына охшамаган. Дөресрәге, аз гына атасы ягына да, аз гына анасы ягына да тарткан, әйтерсең, икесенең дә күңелен күрергә тырышкан. Ике төрле милләттән туган бала, чын булса, талантлы һәм матур була диләр. Аларның балалары да матур һәм акыллы булачак. Анасының күзләре, ә маңгае, чәче әтисенеке төсле... Хәер, кызларга артык киң маңгай килешми. Гомумән, артык булса, беркемгә дә килешми. Әйдә, кызлары аналарына, малайлары аталарына охшасын — гади арифметика. Юк, гади түгел, ә шактый буталчык һәм ...Гәүһәр татлы хыялларыннан уянып китте.

— Ә син миннән курыкмыйсыңмы, Гәүһәрем, асыл ташым?

— Синнән?..— Гәүһәр башта аның тел төбен аңламады.— Куркам. Мин бит сине

үлеп, шашып яратам. Й түзә алмам... Мин бит хатын кеше...

— Юк, мин ул яктан әйтмим,— диде Зәки, аның кечкенә кулларын үзенең киң учларына яшереп. Аның күзләре гадәттәгедән дә сагышлырак иде.— Син — районның баш агрономы, ә мин — нибары тракторчы.

Гәүһәр кабат аның муенынннан ике куллап урап ала да күзләренә текәп карый.

— Мәхәббәт өчен киртә-корталар юк, Зәки. Без бит синең белән Ромео һәм Джульетта дәверендә дә, Галиябану заманында да яшәмибез. Чәчү беткәннең икенче көнендә үк туй ясыйбыз. Туйсыз гына өйләнү — майсыз ботка белән бер ул. Шулай бит? Яратам мин туйларны. Бала чакта ук, и-их, белсәң иде, безнең авылда нинди кызыклы туйлар була торган иде. Мин: «Кайчан мин дә кыз булып җитәрмен», дип әчемнән яна идем. Берәрсенең өйләнүе бөтен авылга бәйрәм була иде. Җәл, хәзерге яшьләр ул йолаларны онытала. Бәлки, шунлыктан да хәзер кайбер гаиләләр, оешмаган балчык кебек, бик тиз тарала. Дөрес, булмаган мәхәббәтне тантаналы-шаулы туй гына саклап тота алмый, әмма кычкырып әйтелгән кагыйдәне эчтән әйтелгәнгә караганда бозуы авыррак. Ә беләсеңме, элек килен төшкәндә ничек эшләгәннәр? Капкадан килен керү белән таш ташлаганнар. «Килен таш кебек кузгалмаслык булсын», дигәннәр. Ә ишек тупсасын үткәч, «килен мендәрсымак йомшак булсын», дип идәнгә мендәр ыргытканнар. Мин синең ташың да, мендәрең дә булырмын, Зәки. Мин бит яхшы агроном гына түгел, мактанмыйм,

начальство шулай ди, яхшы хатын да була алам. Зәки, ә сине минем кыз булмавым борчымыймы? Кызлар белән буа буарлык заманда егет башы белән тол хатынга өйләнде, тилекәй, дип синнән көлмәсләрме, ә?

Зәкинең уйлары бөтенләй әллә кайда иде.

— Ә?.. Көлүче кешенең авызына сугып булмый, Гәүһәр. Аларга түгел, миңа синең белән яшәргә.

— Син нинди акыллы һәм... җитди. Нигә син артык җитди, Зәки? Көлгәндә дә синең күзләрең уйчан була. Син миннән курыкма. Мин эштә генә баш агроном булырмын, ә өйдә син минем патшам һәм аллам булырсың. Мин беркайчан да сиңа каршы сүз әйтмәм. Без синең белән озак һәм тату яшәрбез. Җитмешәр ел торсак та, синең кырык ике, минем кырык биш ел башланмаган гомеребез бар әле. Ә без синең белән йөзәр ел яшәрбез, Зәки. Синең укырга исәбең бармы? Өйләнешергә йөрибез, ә сорашканым юк, син ничә класс бетердең? Уннымы?

Зәкинең йөрәге ешрак тибә башлады. Гәүһәр моны сизенде.

— Сиңа ни булды? Үзәгеңә үтәрлек сүз әйттемме? Гафу ит, Зәки. Укырсың, институт та бетерерсең. Әле бит сиңа соң түгел. Теләсәң, читтән торып укырсың. Чөнки мин сине сагынырмын... Син сагына беләсеңме? Ирләр бит каты бәгырьле булалар.

Зәки аны бер кулы белән кочаклый, аркасыннан иплән кенә сөя.

— Дөрес, Гәүһәр. Без бер-беребезне бик аз беләбез. Бигрәк тә син мине аз беләсең.

— Юк, күп беләм. Әйтерсең, мин сине туган көнеңнән алып беләм. Әйтерсең, мин сине белми бер көн дә яшәмәгәнмен. Синең һәр сулышың, һәр адымың, һәр йөрәк тибешең миңа таныш һәм... якын.

Ул, балалар кебек, ышанып, аңа сыеша.

— Дөрес, бүгенге тормышым сиңа таныш, ә менә үткән гомерем... караңгы.

— Хатының бар идеме?

— Юк.

— Төрмәдә утырдыңмы?

— Юк.

— Ә нәрсәң караңгы соң? Синең бер кара җирең дә юк, Зәки, уйлап чыгарма, хәтта чәчең дә агарып бетеп бара.— Ул Зәкинең салкын яңагыннан чут итеп үбеп алды да, берәрсе ишетмәде микән дип, тирә-ягына каранды.— Я, нәрсәң караңгы? Фронтта начар сугышмагансың. Өч медалең, бер «йолдыз»ың бар. Ә уку турында көяләнмә. Куып җитәрсең. Әйдә, инженер-механиклыкка укы. Ә? Син машиналар яратасыңмы, әллә мине генәме? Ә?

— Ә мин күптән инде инженер-механик,— диде Зәки кулларын тезләренә куеп.

— Инженер? — Гәүһәр кулларын аның кулларына куйды.

— Ышанмыйсыңмы?

Гәүһәр авыз ачарга да өлгермәде, Зәки, тәбәнәк койма аркылы сикереп, бакчага керде.

— Зәки...

Гәүһәрнең кинәт йөрәге кысылып китте. «Нишләп соң әле «инженер» сүзе аны шундый ярсытты? Соң бар кешегә дә инженер

булырга димәгән бит. Әлбәттә, ир белән хатын икесе дә бер дәрәҗәдә булса күңелле. Ә инде хатыны баш агроном, ире гади тракторчы булса... ничектер килешми. Киресенчә булса ярый әле, болай... Гармонично түгел. Дөрес, Зәки бик культуралы, күпне белүче кеше, ләкин... ир, белеме белән генә түгел, дәрәҗәсе белән дә хатыныннан ким булырга тиеш түгел».

— Рәхим ит,— диде Зәки тәрәзәдән сикереп төшү белән һәм Гәүһәргә паспорттан аз гына зуррак, катыргы тышлы кенәгә сузды.

Гәүһәр кенәгәне ачып, ай яктысында укыды: «Присвоено звание инженера-механика по сельхоз машинам...» 25 июль, 1941 ел...

Гәүһәр телдән калды, дөресрәге, теле аңкавына ябышты. Моны ничек аңларга? Югары белемле кеше гади тракторчы булып эшли. Дөрес, тракторчы булып эшләүнең дә бер гарьлеге юк, ләкин ил... авыл хуҗалыгы инженер-механикларга шундый мохтаҗ вакытта... Аңламыйм. Иртәгә үк, дөресрәге, бүген үк начальство белән сөйләшергә кирәк.

Ә Зәки аның уйларын укып утыра иде.

— Начальство бу хакта белә, Гәүһәр.

— Белгәч, нигә сине специальностең буенча файдаланмыйлар? Ичмасам, МТСта баш механик итеп...

— Ярамый,— диде Зәки, авыз чите белән генә елмаеп һәм дипломы белән учына сугып.— Ярамый.— Ул скәмьягә утырды.

— Ни өчен ярамый? — Гәүһәр ачу катыш сорады.

— Чөнки мин «пленник»... Ике ел буе үлем лагерьларында газап чигеп йөрдем. Освенцим, Дахау...

— Пленник?..— Бу сүз Гәүһәргә лепкәсенә балта түтәсе белән тондырган кебек тәэсир итте, ләкин ул шаккатуын сиздермәде һәм ачык тавыш белән ышанычлы итеп сорады:— Үзең теләп пленга төшмәгәнсеңдер дип ышанам.

— Мин контузиядән һуштан язганмын. Башта мине үлек дип күмеп китмәкче булганнар. Николай исемле дусым коткарып калган. Немец солдатларыннан ялынып сораган. Ул чакта мин 95 килограмм килә идем. Немецлар миннән яхшы эшче-кол чыгар дип кызыкканнар. Лагерьга барганда качарга теләгән идек, барып чыкмады. Николайны атып үтерделәр, ә мине һушымнан язганчы овчаркалардан талаттылар.

Гәүһәр тынычлана төште.

— Шулай булгач? Монда синең тырнак очы чаклы да гаебең юк.

— Юклыкка юк, ләкин мин моны исбат итәлмим. Дөрес, пленга төшү хурлыклы эш, ләкин башыңа төшкәч, нишлисең. Бар кешегә дә лагерьдан качып, кара табыңны юарга туры килмәде шул.

Инде Гәүһәр аны юата башлады:

— Соң син бит ул табыңны азак югансың. Орден-медальләрең бар...

— Ләкин ул минем биографиямдә юып та, кырып та бетерә алмаслык эз булып калачак.

Гәүһәргә Зәки шундый кызганыч, мескен

тоелды, башын аның күкрәгенә куеп, чак-чак елап җибәрмәде.

— Иртәгә, дөресрәге, бүген үк, МГБга барабыз. Барыбер синең гаепсез икәнлегеңне исбат итәчәкбез.

— Буш эш,— Зәки көрсенеп кул селтәде.— МГБда утырган кеше минем бер генә сүземә дә ышанмый. Гомумән, берәр кешегә ышана микән ул...

— Юк, язмышыңа баш иярга ярамый.— Гәүһәр сүзләренә көч бирер өченме, әллә түзә алмыйчамы, сикереп торды.— Райкомның беренче секретаре яхшы, кайгыртучан кеше. Туп-туры аңа барырбыз. Ул ярдәм итәр. Обязательно.

— Мин арыдым, Гәүһәр... Контузия дә елдан-ел көчәя... Төннәр буе керфек какмый чыгам. Йокыга китсәм, һаман Дахау, Освенцим белән саташам. Ял итәсе урында шабыр тиргә батып, хәлсезләнеп уянам. Көндез үзебезнекеләр... ышанмыйлар. Иң хәтәре дусларың, иптәшләрең, үзебезнекеләр ышанмый, кырын карау ул, Гәүһәр. Хуш, Гәүһәр. Әнә таң сызылып атып килә. Чит илләрдә, ят җирләрдә шул таңны күрер өчен нинди тилмердек без...

— Юк, юк. Мин беркая да бармыйм, Зәки. Мин синеке. Мәңгегә. Бүген үк язылышабыз.

— Башта ашыкмый гына уйла, Гәүһәр. Безгә хәзер 17—18 яшь түгел. Азак үкенерлек булмасын. Мин үземнең генә түгел, синең дә бәхетле булуыңны телим.

Гәүһәр, челтәрле коймага таба борылып, күкрәге белән ятты.

— Син... Син үзең миннән куркасың, Зәки. Әйе, әйе. Син егет кеше, ә мин тол хатын. Ә тол хатын, кызларга караганда йөз, мең тапкыр сафрак булса да, шик тудыра. Тол булуыма мин үзем гаеплемени. Барысына да каһәрле сугыш гаепле...

Ул койма баганасына башын куеп үксергә тотынды. Хәзер инде аны Зәки юата башлады.

— Гәүһәр...— Ул аны үзенә борды да, учлары белән яңагыннан тотып, башын күтәрде.— Шулай әйтергә ничек телең бара? Нигә үзеңне шулай кимсетәсең! Хәзер бит безнең илдә тол хатыннар миллионлаган. Күпләренең башка беркайчан да ирләре һәм... шәхси бәхетләре булмаячак. Ләкин алар бу зур бәхетсезлекне горур һәм түземчән кичерәләр. Бар, күз нурым, азрак ял ит. Ишетәсеңме, әнә сандугач та таң серенадасын башлады... Хас романнардагы кебек.

Иртән Гәүһәр райкомга бара алмады. Аны районның иң ерак почмагындагы, Ык буендагы колхозга командировкага җибәрделәр һәм «Иртә культураларны тәмамламый, райцентрга аяк басма», диделәр.

Ул колхозда телефон юк иде, ә авыл Советына (ун чакрым) ике генә тапкыр барырга туры килде. Анда да юл бүлегендә идән юучы хатыннан башка кеше булмады. «Зәки, мөгаен, әллә ниләр уйлыйдыр инде. Аның урынында булсам, мин дә уйлар идем. Юкка борчылма, бәгърем, мин синеке, мәңге-бакый синеке. Безне аерырлык көч юк бу дөньяда...»

Гәүһәр, ару-талу, йокы белми йөгерде, эрләште, үгетләде һәм... колхоз чәчүне гра-

фиктан бер көнгә элек тәмамлады. Гәүһәргә кайтырга рөхсәт иттеләр.

Кайту... Дөньяда туган җиреңә кайтудан да шатлыклырак тагын ни бар икән... Әгәр сине анда сөйгәнең дә ярсып көтсә, бу шатлык кына түгел, бәхет...

Иренең танкта янып үлүе турында коточкыч хәбәр алгач, Гәүһәр өчен якты дөнья кара гүргә әйләнгән иде. Бөтен нәрсәне: кояшны, йолдызларны, күкне кара сөрем баскан һәм ул сөрем беркайчан да таралмас төсле иде. Ләкин гүр туфрагы иң хәтәр кайгыларны да суыта. Үлем белән килешергә туры килде. Һәр килешү кешегә ниндидер тынычлану китерә. Ул гына да түгел. Гәүһәргә кинәт, яшь чактагы кебек, яңа, зур мәхәббәт килде. Ул бу мәхәббәтне әҗәл даруы кебек саклаячак, әрәм-шәрәм итмәячәк һәм вакламаячак. Бу аның икенче һәм соңгы мәхәббәте.

Район үзәгенә якынайганда, аны МГБ бүлеге начальнигы Шомбаев куып җитте. Бу бик уңайлы һәм вакытлы очрашу иде. Шомбаев, Гәүһәрне танып, русча кычкырды (ул беркайчан да һәм беркем белән дә туган телендә сөйләшми иде).

— А-а, гроза предколхозов. Физкульт привет! Откуда?

— Сәлам,— диде Гәүһәр башкортча.

Гәүһәр, ни өчендер, аны яратып бетерми иде, ә Зәки сүзләреннән соң бу тагын да көчәйде. Шомбаев кәгазь кебек ап-ак йөзле, ач яңаклы, һәрвакыт елмаеп торучы аксыл зәңгәр күзле кеше. Аның тавышы нәзек, йомшак, хром итекләре көзгедәй ялтырап тора. «Кы-

зык, минем тарантаска күчеп утырыгыз, дип әйтер микән, юк микән. Әйтмәсә, үземә күчәргә туры килер. Мондый уңайлы вакытны тагын да кайчан туры китерәсең...»

— Гәүһәр Мозафаровна (ул район үзәгендәге җитәкче кешеләрне генә түгел, бөтен колхоз, авыл Советы председательләре, аларның секретарьларының да, счетоводларының да исемнәрен һәм аталарының исемнәрен белә), минем янга күчеп утырыгыз да, атыгызны кире җибәрегез. Курыкмагыз, Нәфисә Гумеровна (аның хатыны) көнче түгел. Гомумән, җирән чәчлеләр көнче булмый ул. Сынаганым бар. Һи-һи-һи...

Гәүһәргә шул гына кирәк иде — ул йомшак рессорлы, канатлы тарантаска күчеп утырды да аны китерә килүче малайны кайтарып җибәрде.

— Ә миң ирем булса көнләшер идем,— диде Гәүһәр, дилбегәне майордан алып һәм күк айгырга ирләрчә сызгырып.— Фьюют... малкай. Кешеләр түгел, кошлар да көнләшә белә. Тапалган булса да әйтим, көнләшү — яратуның күләгәсе. Көнләшү мәхәббәт белән яшьтәш — бер көндә туган. Тик берсе кешене тилмертә, икенчесе — тилертә, берсе ачуландыра, икенчесе ахмакландыра.

Майор, башка вакытта фәкать эш турында гына сөйләшергә яратучы баш агрономның кинәт теле ачылуына аптырады да, сөенде дә. Әллә...

— Гәүһәр Мозафаровна, сезнең ирегез ничәнче елны үлгән әле?

— Кырык беренче... Тиздән биш ел була.

— Шуннан соң үзегезгә тиңдәшне очратмадыгызмы?

— Юк. Дөресрәге, мин көттем. Ирем белән бер ротада сугышкан танкист кайтып, иремнең фуражкасын тапшырмыйча, аның үлүенә ышанмадым.

— Героический кеше... Башка берәү булса, бәлки, кулын күтәрер иде, ә ул хурлыклы пленга караганда танкысында янып үлүне артыграк күргән.

Шомбаев, пистолет формасында эшләнгән трофейный зажигалкасын чылт итеп яндырып, папирос көйрәтте.

Гәүһәр: «Ә сез шулай эшли алыр идегезме?» — дип сорарга уйлаган иде дә, тыелды. «Зәки дә кулын күтәрмәс иде. Һәм күтәрмәгән дә. Аны бит һушыннан язгач кына эләктергәннәр. Юк, Зәки беркайчан да кулын күтәрмәс, башын имәс».

— Плен дигәч искә төште,— дип хәйләләште Гәүһәр, болай да очып барган айгырга дилбегә кагып.— На-аа... Юл бүлегендә эшләүче Зәкине... Өметбаевны да пленда булган диләр, дөресме?

— Нигә кинәт аны хәтерләдегез әле? — Шомбаев, авызыннан папиросын алып, аңа чиертте.

— Болай гына... Кыш көне «Галиябану» спектаклендә бергә катнашкан идек.

— Ә-ә... Әллә мин берәр якыныгызмы дип торам. Слава богу. Әйе, ул ике ел да өч ай да алты көн, юк, җиде көн немецларда булган. Англичаннар коткарганнар.— Ул, минем хәтер шәпме дигәндәй, Гәүһәргә карап елмайды.

— Үзе теләп төшмәгәндер бит?— Гәүһәр маңгай астыннан майорга карады һәм, нигәдер, куркып көтте.

— Үзе юк, ди. Ләкин коры сүзгә генә ышануы авыр.

— Әгәр аның шаһитләрен үтереп бетергән булсалар?

Майор ачык җавап бирмәде.

— Уфада бер пленный үзен подпольный партийный оешманың җитәкчесе дип алдап йөрткән һәм, кайсыбер беркатлы бәндәләрне ышандырып, партиягә үрмәләгән. Күптән түгел фашлаганнар. Чит кеше фамилиясе белән йөргән. Белоруссиядә ниндидер местечкода бургомистр булып эшләгән икән, сволочь. Аны фашлаган оперуполномоченныйның погонына бер йолдыз өстәгәннәр. Былтыр гына майорны алган иде... Дилбегәне бирегез әле. на-аа, «Бөркет»... Юрта төш, барыбер сиңа безнең сүзләр кызык түгел.

«Аны дошманны фашлаудан бигрәк, погондагы йолдызлар кызыктыра ахры», дип уйлады Гәүһәр.

— Әйтегез әле, ә сез... Зәкигә... Өметбаев сүзләренә ышанасызмы? Аның бит карашы шундый якты, саф...

«Ышанам» дип әйтсә, Гәүһәр, һич тайчанмый, аның кәгазь кебек ак, чандыр битеннән үбеп алыр иде.

— Безнең эштә сентиментальностька урын юк, Гәүһәр Мозафаровна. Сабый баланыкы кебек күзле кешеләрнең дә чырайларын сытмый кеше үтергәннәрен күргәнем бар минем. Бәлки, шул ук Өметбаев та үзебезнекеләргә

аткандыр, бәлки, ул сезнең ирегезнең үлүенә сәбәпчедер...

Гәүһәр гөлт итеп кабынды һәм шартлау хәленә җитте. Ләкин үзен вакытында тыеп калды.

— Бәлки... дыр... Бөтен йомгакны да дыр-га таянып эшләргә ярамый, иптәш майор.

Майор үпкәләмәде, ә гадәттәгечә елмаеп җавап бирде.

— Дөрес. Шуның өчен без аларның бөтенесен дә махсус исәптә тотабыз. Ватанның иминлеге шуны таләп итә.

«Алдыйсың, сине Ватан иминлегеннән бигрәк, шәхси иминлегең ныграк борчый», дип уйлады Гәүһәр һәм кычкырып әйтте:

— Ләкин бер дошманны тоту өчен, йөз, мең кешегә шикләнеп карау гаделсезлек. Хата.

— Юк, сез үзегез хаталанасыз, Гәүһәр Мозафаровна («Нигә ул аз гына да кыза белми икән. Бигрәк салкын канлы»). Бөтен кешегә ышанып төп башына утырганчы, һәркемгә сагаеп карау хәерлерәк һәм... хәвефсезрәк. Миңа моны минем элекке начальнигым каныма сеңдерде. Ә ул — күпне күргән бүре — утыз җиденче елны егерме алты халык дошманын фаш иткән кеше. Шәп полковник. Озакламый генералны алыр ахры.— Шомбаев Гәүһәргә елмаеп карап алды.— Сезнең әллә теге... Өметбаев белән роман-фәлән бармы? Җиңәш итмәс идем. Герой хатыны... пленникка гашыйк булган. Синхронно түгел, Гәүһәр Мозафаровна. Сезнең белемегез, төсбашыгыз һәм положениегез белән...

— Трр...— Гәүһәр дилбегәне тартты һәм юртып барган айгырны туктатты.— Романмы, хикәяме, анысын белмим. Әмма сезгә кеше сүзенә... совет кешеләренә ышанырга киңәш бирер идем, иптәш майор. Ватан иминлеге өчен. Хушыгыз.

Гәүһәргә хатын-кызлар хушбуе һәм итек кремы исе килеп торган кеше янында утырып баруы авыр һәм күңелсез иде. Ул тарантастан сикереп төште.

— Көтмәгән идем. Сезне шулай түбәнлеккә төшәрсез дип көтмәгән идем, иптәш Низамова. Я, сау булыгыз,— дип башын какты да атына кычкырды:— Һа-ап, «Бөркет».

Гәүһәр төнге юлда ялгыз торып калды, тик йолдызлар гына аңа *пошынма, Гәүһәр, башыңны күтәр, Гәүһәр, дип күз кыстылар,* тик телефон баганалары гына, аны юатырга теләп, сүзсез җыр җырладылар.

«*Их, Зәки, Зәки... Нигә син пленга эләктең икән?..* Беләм, сиңа анда коточкыч авыр булган, ләкин... ләкин минем ирем үлемне пленнан артыграк күргән бит. Нигә син дә... Нәрсә, үлгән булсаң, яхшырак булыр иде, димәкчесеңме?.. Нинди шәфкатьсез син, Гәүһәр. Исән калуың яхшырак, Зәки, исән...» Ул, Зәки чәче кебек йомшак, нәфис арыш ужымына ятып, тәгәри-тәгәри елады. Ә йолдызлар ачу китереп, күз кыстылар, телефон баганалары әчпошыргыч озын һәм ялыктыргыч бер көйгә җырладылар.

Шушы минутларда райком секретареның кечкенә һәм җыйнак кабинетында Гәүһәрнең язмышы хәл ителә иде. Яшел пустау җәелгән өстәл янында Уфадан килгән вәкил, район

Советы башкарма комитеты председателе Мәгасумов һәм райкомның беренче секретаре Кулагин утыра. Өстәлдә Мәгасумовның өч битле гаризасы ята. Гаризаның уң як почмагына, өстә: «Бишенче тапкыр», дип язылган.

Уфадан килгән вәкил, гаризаны алып, инде ничәнче тапкырдыр күз йөртеп чыга. «Сугыш вакытында, кадрлар аз чакта, кулымнан килгәнчә тырышып эшләдем (ике орден алдым). Хәзер картайдым. Ашказаным да интектерә. Минем башкача бу постта эшләвемнән файда аз булачак. Шуның өчен...»

— Ә сез үзегезнең урынга кемне тәкъдим итәсез, иптәш Мәгасумов?

— Низамованы.

— Низамованы? — Кулагин кулындагы юан кызыл карандашны яшел пустауга ташлый.— Ул әле бала гына.

— Федор Иванович, ә син үзең... егерме ике яшеңдә волком секретаре түгел идеңме соң?

— Мин... Мин ни... Мин — ир кеше.

— Ә Низамова ни җитте ирләргә бирешерлек түгел.

Уфадан килгән вәкил Федор Ивановичка елмаеп карады.

— Я? Соңгы сүз синңа бирелә, Федор Иванович. Мин аны ишетеп кенә беләм. Аннан... миңа түгел, сиңа аның белән эшләргә.

— Ә соң ул үзе риза булырмы?

Мәгасумов елмайды.

— Юк, димәк...

Мәгасумов Федор Иванович ташлаган карандашны алды да кире төшерде.

— Димәк, ул үзенә таләпчән карый, һәм аннан менә дигән райсовет председателе чыгачак. Минем ише генә түгел. Хәтта синең ише генә дә түгел.

Федор Иванович, ике кулы белән өстәлгә таянып, урыныннан торды.

— Их, Мәгасумов... Мин сиңа көнеккән идем. Без районны мичәүләп җигелгән ат кебек өстери идек. Нишлисең бит, табигатьнең шәфкатьсез законы шулай — яшьләр зурая, олылар картая,— ул вәкилгә карап алды.— Ә Уфа риза булырмы?

— Хәл итүчеләр — сез, ә Уфа — киңәшче.

— Депутатлар ризалашса (аларның да күбесе фронтта үлеп бетте инде), мин дә риза. Низамова — тартырлык кеше.— Ул тәрәзә янына килде. Ә тышта зәңгәр май төне иде — табигать яшьлеген бәйрәм итә.

Сәгать икеләрдә генә арып өенә кайткан Гәүһәр, күңеле тыныч булмаса да, тиз йоклап китте һәм соң уянды. Ул, гадәттәгечә, җидедә уянган иде, бүген ял көне икәнлеген хәтерләп, башын ике мендәр арасына куеп, тагын йоклап китте. Һәм гаҗәп төш күрде. Имеш, аны Зәки шомырт чәчәкләре белән күмеп ташлаган, Зәки аны эзли, таба алмый, чөнки Гәүһәрне шомырт чәчәкләреннән аерып булмый — өстенә ап-ак туй күлмәге кигән икән.

— Гәүһәәәр!..

Гәүһәр башын күтәреп карый һәм... аның кырында Зәки түгел, мәрхүм ире Мәхмүт басып тора. «Нигә аптырадың? Мин бит

үлмәдем. Үлгән идем дә кабат терелдем. Миңа үлем юк, Гәүһәрем, ләкин син мине көтмә. Мин кайта алмыйм. Мин бит көлгә әйләндем, тик сине яратучы йөрәгем генә исән калды...» Гәүһәр күзләрен чытырдатып йомып ача һәм... Мәхмүт урынында, салкын елмаеп, Шомбаев басып тора: «Инде үзегезнең кем хатыны икәнлегегезне белдегезме, Гәүһәр Мозафаровна? Ә сез күрәләтә бер байгыш пленникка кияүгә чыкмакчы буласыз. Позор. Ха-ха-ха...»

— Китегез! Китегез!..— Гәүһәрнең тавышы чыкмый. Ул тамагын ярырдай итеп, «Китегез!!» дип кычкыра һәм үз тавышыннан үзе уянып китә. Уфф... Бая уянганнан соң кабат йокламаска иде...Фу-у, нинди мәгънәсез төш... Ә шулай да, иң элек, Зәкинең элекке репутациясен кайтарырга кирәк. Болай кеше алдында да, Мәхмүтнең истәлеге алдында да уңайсыз. Әгәр ул беркемгә билгесез бер хатын булса, җиңел булыр иде. Аны бит бөтен район белә, өстәвенә райком члены. Синең эштә йөрәк кушканча гына яшәмиләр, Гәүһәр Мозафаровна, башның киңәшен дә тыңлыйлар. Ә Зәкигә бу хакта әйтергәме? Үпкәләмәсме, суынмасмы? Ул акылсыз кеше түгел, аңлар. Аңлар, ләкин... йөрәгендә юшкын калыр. Юк, сөйләми генә эш итәргә кирәк. Дөрес. Хәзер Кулагин янына барам да... Әгәр Кулагин да хәл итә алмаса, ул чагында...

Ул ашыгып яхшырак киемнәрен киде. Гомумән, ул райкомга кергән саен дулкынлана һәм үзен канатланган кебек тоя.

Аңа ишек төбендә райкомның йомышчысы Сәхәп бабай очрады.

— Нихәл, карендәш. Әниең исән-саумы? Ярый, бик әйбәт. Сине Федор Иванович чакыра.

— Ә мин аның янына барырга дип чыккан идем,— диде Гәүһәр, Сәхәп бабайныңябык, кытыршы кулын кысып.

— Вәт әйбәт булган, әйдә, утыр, мин ат белән килдем. Әниең исән-саумы? Ярый, бик әйбәт. Уҗымнар әйбәт күренәме? Ярый, бик әйбәт.

Уттай эш вакытында өстенә чәчәкле ефәк күлмәк, кара лак туфли кигән баш агрономны күреп, өлкә вәкиле серле елмайды, Кулагин белән Мәгасумовка мәгънәле караш ташлады.

Бу караш: юк, мондый яшь һәм матур хатыннан «район хуҗасы» чыкмаячак, ә... иркә һәм шаян бичә генә чыгачак, дигәнне аңлата иде. Нигәдер, еш кына, матур кызларны акылга җиңелрәк һәм гамьсез була дип уйлыйлар. Имеш, аларның бөтен таянычы йөзләрендә дә зифа гәүдәләрендә. Әйтерсең, матур гәүдәдә матур акыл булмый. Ә Гәүһәр чынлап та исеменә хас гәүһәр иде. Бераз оялып караучы зур, соры күзләр, күзләргә ямь бирүче, аларны тагын да матурлаучы, менә-менә очарга әзер торучы нәзек кыйгач кашлар, ә өстәге ике теш арасында калын кәгазь сыярлык кына ярык, уртадан чокраеп һәм бераз алгарак чыгып торган кечкенә нәфис ияк. Шушы гүзәл баш язгы кояшта янган озын, килешле һәм көчле муенга утыртылган. Ә гәүдәсе... унҗиде яшьлек кызларныкы кебек нечкә, зифа иде. Һәм беркем дә, Гәүһәрнең йомшак, нечкә бармакларына ка-

рап, бу куллар көне-төне туфракны айкый дип уйламас иде. Күрәсең, табигать биргән гүзәллекнең кадерен белеп сакласаң — гомергә җитәдер.

Кулагин вәкилнең ни әйтергә теләгәнен шунда ук аңлады. «Ялгышасың, иптәш вәкил, мин дә башта Гәүһәр хакында синеңчәрәк уйлаган идем һәм, нигә яшереп торырга (райком секретаренең да күзләре дә, йөрәге дә бар бит), эчемнән генә аңа гашыйк булып та йөргән идем. Сугыш вакытында монда артполк торды. Ә артиллеристларны, үзең беләсең, берсеннән-берсе чибәр, таза халык. Кемнәр генә, «Гәүһәр» дигән крепостьны алырга тырышып, артподготовка ясап карамады, юк, рәт чыкмады. Үз хакын яхшы белә бу патша кызлары кебек горур, хур кызлары кебек гүзәл Гәүһәр. Тик менә кем генә аның йөрәгенә баш булыр икән...»

— Без сезне шундый мәсьәлә буенча чакырдык, Гәүһәр Мозафаровна,— Федор Иванович серле пауза ясады.

Гәүһәр башта яңа эш турында ишетергә дә теләмәде. Дөресрәге, ул ышанмады. Шаярталар дип уйлады. Аңа, әле үз хисләренә дә юньле-башлы хуҗа була алмаган япь-яшь хатынга, ничек итеп районга «хуҗа» булырга. Юк, бу мөмкин дә түгел, кирәк тә түгел. Зинһар, шаяртмагыз, ул бөтенләй башка эш белән килде бит. Эченнән ул шулай уйлады, ә үзе бөтенләй башка сүз әйтте:

— Ялгызым гына уйларга рөхсәт итегез, Федор Иванович...

— Уйлагыз, ләкин озак уйламагыз. Озак

уйлану кешене шикләндерә, икеләндерә башлый ул.

Гәүһәр, йомышын онытып, чыгып китте. Юк, онытмады, оялды. Ят кеше барында шәхси мәсьәләне кузгатырга тартынды. Өстәвенә, шундый зур, җаваплы пост тәкъдим итәләр. Уйлап карасаң акыл җитмәслек эш — Башкортстандагы иң эре районнарның берсенә председатель. Риза булуын булырсың, ә эшли алырсыңмы?.. Ә нигә эшләмәскә? Мәгасумов эшли бит әле. Аның кайсы җире Гәүһәрдән артыграк. Күпне аласың, Гәүһәр. Мәгасумов — тәҗрибәле работник, ир кеше, ә син... Нәрсә, мин? Теләсәм, Федор Иванович урынында да эшли алачакмын. Әйе, әйе. Эшли алачакмын! Хәзер үк керәм дә, ризамын, иптәшләр, дим. Әллә башта әни белән киңәшләшергәме? Һи-и, ул, шундый авторитетлы, шундый олы урынга дурак та риза булыр, бар, килеш, дип әйтер. Зәки!.. Аннан да төплерәк киңәшчесе булмаячак.

Ул «соңгы сүз»не ишетер өчен Зәки янына китте — Зәки ни әйтсә, шулай булыр.

Зәки, ярсыган, каушаган Гәүһәрне күреп, югалып калды. «Димәк, тәвәккәлләгән».

— Син кайда югалдың, Гәүһәркәем? Мин әллә ниләр уйлап беттем.

— Азак. Киңәш бир. Тик дөресен әйт, күзгә карап. Үз хәтереңне дә, минекен дә саклап торма. Яме.

— Я.

— Мине димлиләр.

— Кем?

— Кулагин, Мәгасумов һәм... Уфадан килгән вәкил... Фамилиясен оныттым инде.

— Минем турыда син аларга сөйләмәдеңмени?

— Юк ла... Мин чалгы белән, син дуга белән печән чабасың. Мине райисполком председательлегенә димлиләр.

Зәкинең кинәт төсе үзгәрде.

— Ну?

— Әйт, булдыра алырмынмы? Синең сүзең — закон.

Зәки Гәүһәрнең күзләренә текәп карады һәм анда яңа, моңача сизелмәгән ят чаткы күрде.

— Алырсың.

— Димәк...

— Димәк, ризалык бир.

— Рәхмәт, бәгърем. Мин синең шулай әйтерењә ышанган идем. Ә хәзер мин ычкындым. Көндезге поезд белән Уфага китәргә кирәк. Бе-се-дага. Озатып мәшәкатьләнмә. Вокзалда теге вәкил дә булачак. Ходай белә, әллә ни уйлавы бар. Бүген үк урап кайтам. Төнлә беренче яртыда. Каршы ал. Шомырт чәчәге алып килергә онытма. Яме. Зәки, очрашкан саен әйтергә җыенам да онытам. Өеңне сипләргә вакыт түгелме? Зур итеп терраса да эшләт. Мин террасалы өйне яратам. Түбәсенә калай яптыр. Яме. Материал табарбыз. Синең кесә ягың ничек? Җитәрлек булмаса, өстәрмен. Ә капканы русча эшләт. Яме. Бала чактан ук шундый капкалы йортта яшәргә хыялландым. Безнең авылда өч кешедә генә шундый капка иде: ике муллада да бер сәүдәгәрдә.

Зәки, нигәдер һәм нидәндер куркып, шат-

лыктан чәчи-чәчи сөйләнүче Гәүһәрнең күзләренә карап елмаеп торды.

— Ярый, хуш. Беренче яртыда. Онытма.

— Гәүһәр!

— Әүкәй?

— Ә хәзер сине үбәргә ярыймы?

— Ярый һәм кирәк, тилекәй.— Һәм ул, баласын үпкән ана кебек, үрелеп Зәкинең маңгаеннан үпте.

Гәүһәр юл буе Зәкие турында уйлап барды. Өлкә комитетында аның хакында да сөйләргә кирәк. Башта без аны үзәк МТСка баш механик яки МТМ мөдире итеп билгелибез, азак директор итәрбез. Дөрес, Шомбаев теше-тырнагы белән каршы төшәчәк һәм каршы әйткәндә дә йөзендәге дежурный елмаюы бетмәячәк. Нигә ул беркайчан да кашын да җимерми икән? Гәүһәрнең атасы, мәрхүм Хисами агай: «Бер тамчы да эчмәгән һәм гел генә елмаеп торган кешеләрдән сак бул, кызым. Андыйлар, фирештә булып күренергә тырышсалар да, шайтаннан да явызрак булалар», ди торган иде. Ә Хисами агай күпне күргән, күпне татыган карт коммунист иде. Сугыш башланган көннәрдә үк, яше иллегә җитсә дә, үзе теләп фронтка китте һәм киткәннән бирле бер генә хаты да, хәбәре дә килмәде. Суга төшкән таш кебек эзсез югалды. Дөрес, аның эзе калды. Ул оештырып йөргән колхозга «Партизан Низамов» дип исем куштылар; күпләр аны һаман телгә алып хәтерли, сагынып сөйли. Хисами агай: син, кызым, төс-башың белән әтиеңә, холкың-гадәтең белән әниеңә охшагансың дип кечкенә чагында аны иркәли торган иде.

Гәүһәрнең әлегә кадәр аңлый алганы юк: бу яхшымы, начармы? Дөрес, әнисе Хөснури ханым начар кеше түгел, бераз һавалы, эре — әйтерсең, кырык тартмачы Яркыбай кызы түгел, ә берәр алпавыт баласы. Ә Гәүһәр эреме соң? Артык вак булсаң да яхшы түгел бит ул — күзгә күренмәячәксең...

Гәүһәр Зәкинең язмышы турында обкомда сөйләшә алмады, вакыты булмады. Ә инде ачыктан-ачык әйткәндә, оялды. Соң бит әле аның яңа эшкә башы керсә, аягы кермәгән, ә дөресрәге, бер җире дә кермәгән. Ярый, гаепсез кешене яклау өчен вазифаның кирәге дә юк, ди. Әгәр обкомда: «Ул кемең — туганыңмы, якыныңмы?» — дип төпченә башласалар, ни дип әйтерсең. Туганым дисәң — алдашу булачак, ирем дип әйтү — уңайсыз. Юк, башта Федор Иванович белән киңәшергә кирәк. Райком барында нигә туп-туры обкомга сикерергә...

Кайткач, эшкә башлагач та, Гәүһәр Федор Иванович белән сөйләшә алмады: я бушамады, я онытты, я кыенсынды. «Нигә Зәки өчен ул кайгыртырга тиеш әле? Яратканы өченме? Юк. Һәркем үзе өчен үзе көрәшергә тиеш. Әгәр ул хәзер үзе өчен көрәшә алмаса, гаиләсенең бәхете өчен ничек көрәшер...» Бу дәлил белән ул үзен аклады һәм тынычландырды.

Шомырт күптән инде чәчәген койды. Сабан туйлары да үтеп китте; печән өсте, тәкәләр суя торган вакыт һәм алыша-бирешә торган көннәр килеп җитте.

Зәки өен сипләде, челтәрле тәрәзәле киң, озын терраса эшләде, бөтен осталыгын һәм

мәхәббәтен салып, искитәрлек нечкә һәм серле сырлар-чигүләр белән урыс капка эшләде. Капка төбенә ике кеше утырырлык яңа скәмья ясап, аны яшелгә буяды.

Зәки ябыкты, олыгаеп китте — әмма сүзендә торды — Гәүһәр кушканны вакытында эшләп бетерде. Дөрес, өй түбәсе тактадан булды; Зәки Гәүһәрне вак-төяк йомыш белән мәшәкатьләргә теләмәде. Ярап торыр, такта түбә дә 13—14 елга җиңел чыдый, ә аннан күз күрер.

Эш беткәч, Зәки урамның икенче ягына чыгып, йортына сокланып, сызгыра-сызгыра карап торды.

Тыкрык буе шофер Әхмәди үтеп китешли:

— Сәлам, күрше. Ну йортны эшләдең, малай, эчендә җаны гына юк,— диде, кызыгып.

— Җаны һәм кәләше юк,— диде Зәки, көлеп.

Әхмәди юлыннан туктады.

— Тартырга бармы? Да, син тартмыйсың бит әле. Карале, күрше, давай мин сиңа балдызны димлим. Ул төс, ул холык, малай... Калакка сал да каймак урынына йот. Ыһ.— Ул бармакларын укмаштырып чутылдатып үбеп алды. — Быел гына унынчыны бетерде. Башкисәр кыз инде.

— Балдызың минем өчен яшьрәк,— диде Зәки, хәйләләшеп.

— Син ничәдә? Егерме сигездә. Бичәләр ун-унбиш яшькә кечерәк булырга тиеш. Югыйсә, алар тиз картаялар. Күрше, бир кулыңны. Бүген үк сөйләшәбез, килешәбез һәм ярты белән ярәшәбез. Балдыз — во! Ул

төскә-башка, малай, ул холык-характер, ыһ. Соң синең аны күргәнең бар бит инде. Зилина исемле...

— Әхмәди... Мин көзсез өйләнмим әле,— диде Зәки, инде ничек котылырга белми.

Әхмәди көяләнмәде.

— Что же, көзгә чаклы гына көтәргә була. Тик, кара, берәр тол хатын башыңны әйләндермәсен. Хәзер алар эт тезеннән. Үзең беләсең: кыек булса да юл яхшы, кылый булса да кыз яхшы. Пока!

Фу... Шушы Әхмәди очраган саен берәр ахмак сүз әйтеп кәефне бозмаса, эче пошадыр ахры. Хәер, бәлки ул үзенчә яхшылык эшләргә телидер. Ә Гәүһәр нигәдер соңгы вакытта бөтенләй күзгә-башка күренми. Күренсә дә, төнлә, аяк тавышы басылгач кына килә. Әллә минем белән көндез күрешергә ояла инде... Пустяк. Гәүһәр — ни житте ирләрдән дә кыюрак хатын. Вакыты юк — менә сәбәп.

Һәм аның чынлап та вакыты юк та иде шул. Дөрес, ул эшләгән район, республикадагы күпчелек районнар кебек, сугыштан йончып чыкмады, яңа нефть ятымнары ачылу районга зур җиңеллек китерде. Ә шулай да хуҗалык шактый таушалган иде. Эшче көче һәм машиналарның аз булуы теңкәгә тиде.

Гәүһәр көне-төне колхоздан колхозга чапты, таң әтәчләре кычкырганчы бюро утырышларында, киңәшмәләрдә, актив җыелышларында, пленумнарда булды һәм, черем итеп алганнан соң, тагын район Советына йөгерде. Аның бер генә «буш» ял көне дә бул-

мады: колхозлардан озын көн буе шалтыраттылар, җиде төн уртасында Уфадан чакырдылар, иртәсен-кичен квартирасына килделәр, төшке ашны кырыкмаса кырык тапкыр бүлдерделәр. Мунчага китсә, анда да эзләп бардылар. Ә кино-картина карау хакында башка да китерергә ярамый, ул җиде күк өстендәге хыял иде. Тынгысыз, җаваплы һәм мәшәкатьле эш ул авыл хуҗалыгы районының «хуҗасы» булу. Аны җир дә, кешеләр дә, ат та, сыер да, ремонтланмаган күпер белән сипләнмәгән мәктәп тә, пенсия ала алмый этләнеп йөрүче солдат хатыны да, ботинкасы тузган укучы малай да, күкнең печән өстендә артык юмарт булуы да, арыш серкәгә утыргач, кояшның шәфкатьсез кыздыруы да — барысы да, барысы да борчый, уйландыра. Шулай булгач Гәүһәргә элекке кебек һәр төн Зәки белән очрашырга кайдан вакыт калсын. Зәки үпкәлидер, борчыладыр... Нишлисең бит — аның җилкәсендә зур район. Иртәгә ничек тә, вакыт табып, Зәки янына кереп чыгарга кирәк. Өен дә сипләткән дип сөйлиләр. Ул кушканча эшләде микән... Кызык, «Галиябану»ны куймасалар, алар очрашкан булырлар иде микән. Очрашырлар иде. Аның, укыганымы, ишеткәнеме бар — яраткан йөрәкләр бер-берсен гомер буе эзлиләр һәм, иртәме, соңмы, табалар, ди. Ә Зәкинең тавышы көчле түгел, әмма моңлы, йөрәгеннән өзелеп чыга.

«Галиябану, сылуым, иркәм,
Кемгә насыйп яр икән...»

Сиңа насыйп яр мин, Зәкием, бәгърем, сылуым, иркәм... Тик менә ничек сине батып-чумып йөри торган эшеңнән коткарырга...

Лирикага, сагышка тулган минутлар сирәк килде һәм кыска гомерле булды. Гадәттә аларны телефонның тәкатьсез звоногы өзде. Ә очрашулар көн саен кичектерелде һәм сирәгәйде.

Көтте, көтте дә, көтеп ала алмагач, Зәки Гәүһәрләргә үзе килде. Хөснури ханым аны артык ачык (димәк, чын күңеленнән түгел) каршы алды.

— Утыр дисәм, көтеп ала алмассың. Ул райкомга *радиоперекличкага китте. Мал азыгы әзерләү хакында бугай. — Һәм ул,* чын район «хуҗасы» кебек, колхоз председательләреннән зарланырга тотынды. — Элек, сугышка кадәр, терлек азыгы әзерләгез, чүп утагыз дип тә колак тукылдатып тормадылар. Председательләр үзләре белделәр, үзләре әзерләделәр. Хәзер халык бозылды. Бозылмый ни. Ун бичәгә бер ир заты. Алар да я бригадир, я кладовщик. Ә бөтен кара эштә хатыннар эшли. Шуңа күрә Гәүһәр бахыркаемның борылырга да вакыты юк.

— Кайчан кайтырын әйтмәдеме?

— И-и... Ул таң атмыйча кайтмый...

— Алайса, хушыгыз. Миннән сәлам әйтегез. Үзен бик бетермәсен.

— Самовар куяр идем дә күмерем беткән иде. Ярый, хуш. Коры булды, гаепләмә. Хуш, хуш.

Гәүһәр өйдә булмаса да, Зәки бераз тынычланып чыкты. Юк, Гәүһәр аны онытма-

ган һәм онытмаячак та. Шикләну кортларыңны йөрәгеңнән чүпләп ал да үтер, — Гәүһәр сине элекке кебек ярата. Яратмый башласа, куркып-өркеп тормас, ачыктан-ачык әйтер иде.

Әллә соңгы сеанска ике билет алыргамы? «Сугыштан соң кичке алтыда» дигән картина. Зәки аны ике тапкыр карады инде. Әйбәт картина. Жәл, шул картинаның сценаристы үзе сугыш беткәнне күрә алмаган...

Перекличка тиз бетте һәм Гәүһәр сәгать унда өенә кайтты.

Инде алтынчы дистәне кууына карамастан, киенергә яратучы һәм чәчен һәрвакыт кына белән юучы Хөснури ханым кызын тырт-пырт каршы алды.

— Бөтенләй кайттыңмы?

— Әйе.

— Бая теге пленнигың килгән иде.

— Әни!

— Нәрсә «әни»! Нигә җикеренәсең? Мин сиңа кем?

— Синең Зәки хакында алай әйтергә хакың юк.

— Хакым бармы, юкмы — анысы минем эшем. Ике ел пленда утыргынмы? — Утырган. Кызым... — Хөснури ханымның тавышы йомшарды һәм хәтта хәйләле яңгырый башлады. — Мин яшәсен яшәгән, ашасын ашаган. Яшәгән чаклы яшисем калмады. Мин синең өчен көяләнәм.

— Рәхмәт. Минем үз акылым үземә җитәрлек.

— Җитәрлек булмаса, районга баш итеп куймаслар иде дә, тик анавы...

— Капкаларга бармы?

— Хәзер җылытам. Синең вакытында ашаганың бармыни. Ярар, үзем җылытырмын, кулыңны пычратма, — Хөснури ханым кызының кулыннан шырпыны алды. — Эшэш дип үләсең инде. Хәзер иренеңне дә буямый башладың. Әллә район хуҗасына ирен буярга, йөзек кияргә ярамыймы?

Гәүһәр перекличкадан да күңелсез кайткан иде (кайсыбер колхозлар әле силос салырга башламаганнар да), өстәвенә әнисе ачуын китереп, кәефне бөтенләй бозды. Хәзер Гәүһәрнең каты сүз әйтәсе, кычкырасы, кемнәндер ачуын кайтарасы килде.

— Мин районга хуҗа түгел, ә председатель. Хуҗа — халык, — диде ул, күлмәген халатка алыштырып. Бу халат иренең Ригадан алып кайткан бүләге иде: ачык, эре бизәкле. Ә хәзер ул бизәкләр уңган, күренеркүренмәс кенә калган. Яңа халаты булса да, нигәдер, ул бу халатны ешрак кия һәм шуңа аякларын төреп диванда утырырга ярата. Әле дә ул диванга менеп утырды да, район, өлкә, үзәк газеталарын караштыра башлады. Ә Хөснури ханым «тәрбия эшен» дәвам итте.

— Халык хуҗа булса да, ул синең һәр сүзеңә колак сала, һәр адымыңны үлчәп тора.

— Шуның белән ни әйтмәкче буласың? — диде Гәүһәр, газеталардан аерылмый.

— Ә менә шуны әйтмәкче булам: теге плен... эһем... Зәкиеңне оныт.

— Мин аны яратам.

— Ул сиңа пар түгел.

— Анысын мин үзем беләм.

— Кая барма, бичә-чәчә синең хакта сөйли. Авторитетыңны әрәм итүең бар. Юк-бар белән аралашма, теләсә кемне өйгә чакырма.

— Беттеме?

— Син ни җитте кеше түгел, кечкенә генә губернатор. Кулагиннан кала икенче кеше. Үзеңә иш табарсың әле. Хәзер армиядән сөлек кебек эфицәрләр кайта. Нефть чыгарырга килүче инженерлар арасында да буйдаклар бардыр. Мужет, Уфадан килгән берәр уполномоченный...

— Җитәр, әни...

— Җитсә җитәр. Хәзерге балалар ата-анасыннан күбрәк белә бит ул, — Хөснури ханым яулык почмагы белән әллә юк яшен, әллә чын яшен сөртеп алды. — Мин синең язмышың өчен борчылам, бәбкәем. Район Советы председателе булу гына җитми, бала-чага да, гаилә дә кирәк. Әтиең мәрхүм дә эш-эш дип янды да, илле яшендә көйде. Аның кебекләр рәхәтләнеп броньда яшәде, ә ул... ни үзе рәхәт күрмәде, ни миңа күрсәтмәде...

— Әни... — Гәүһәрнең күңеле йомшарды.— Соң мин бит бүгеннән Зәкигә чыгам дип тормыйм, юкка көенәсең.

— Ана баласы өчен көяләнмәсә, кем көяләнсен, кызым... Сиңа хәзер унҗиде яшь түгел, ялгышырга ярамый...

«Әйе, бер ана да баласына начарлык теләми. Хәтта бала анасын кыерсытса да, ананың күңеле балада гына була. Дөрес, аңа ялгышырга ярамый. Егерме биштә булганы өчен генә түгел, ә...»

Һәрвакыттагы кебек, аның уйларын телефон звоногы тупас бозды.

— Бер минут та тынгылык юк,— ул ачуланып трубканы алды һәм мөмкин кадәр ачык, ләкин коры тавыш белән эндәште.

— Низамова тыңлый.

— Саумы, Гәүһәр. Бу мин — Зәки.

Гәүһәрнең йөзе ачылып китте.

— Саумы, син безгә килгәнсең икән...

— Әйе, әниең бик ачык сөйләште...

Гәүһәр, әнисенең җимерелгән кашын күреп, тавышына металл катыштырды.

— Зәки, син кайдан шалтыратасың әле?

— Үзебезнең конторадан. Нигә?

— Анда кеше бармы?

— Юк. Әй, бар икән. Хәерниса апа идән юып йөри. Нигә, Гәүһәр? Мин кинога билет алдым. Бушыйсыңмы?

Шикләнү, икеләнү һәм гаепле кешедәй җавап кайтару.

— Рәхмәт, Зәки. Бушый алмыйм. Син үпкәләмә. Мин бүген кич... төнлә синең янга барып чыгармын әле, яме?

— Алайса, мин дә кинога бармыйм.

— Бар, бар...

— Синсез миңа анда ямь юк...

Караңгы төшкәч түгел, ә сәгать икеләрдә, бөтен табигать йокыга талгач, Гәүһәр өстенә плащ киеп, анын башлыгын күтәреп Зәкиләргә китте. Йөрәк чыгардай булып типте. Сагындырган икән. Аның акыллы, сагышлы күзләрен, көчле кулларын, киң күкрәген, аның сулышын, аның тавышын сагынган ул. Тик эшкә күмелеп кенә искә алмаган икән...

Ул Зәкинең сипләнгән өен, яңа капкасын күреп, тын алмый торды: «Барысы да аның

өчен, барысы да ул әйткәнчә...» Хәтта скәмья дә яңа, артлы итеп эшләнгән...

Гәүһәр яңа скәмьягә утырды. Кызык, аңа кадәр монда берәрсе утырдымы икән?.. Район бакчасындагы скәмьяләрне дә алмаштырырга вакыт. Берсе чатан, икенчесенең аркасы сынган...

Җәйге төн бераз моңлы булса да, тавышсыз музыкага, күренмәгән мәхәббәткә чиксез бай иде. Мондый төнне йокыга алмаштыру — җинаять. Ә Зәки йоклый. Әлбәттә, йоклый, аны көтеп, иягенә таянып утырмый. «Берлек» колхозының председателен алмаштырмый булмый инде. Ике бармагын фронтка барып җиткәнче үк өздергән дә «Мин фронтовик, ватан өчен кан койдым», дип тамагын ерта. Әнә Зәки дә фронтовик, ә бер дә «мин орденоносец» дип күкрәк какмый. Әллә үзен уятыргамы? Килешерме? Ә нигә килешмәсен...

Ул бармак очлары белән, иплән кенә, эре яңгыр тамчылары чирткән кебек, тәрәзә какты.

Әлбәттә, иң элек Зәкинең әнисе уянды.

— Хту там? Кем ул?

«Эндәшергәме, юкмы?»

— Хту дим бит.

— Кем бар анда, әни? — Зәкинең йокылы тавышы ишетелде.

— Бисмилла... Миңа гына шулай тоелды ахры. Әллә саташтым.

— Зәки... Зәки, бу мин, — дип пышылдады Гәүһәр.

— Син? Хәзер...

Берничә минуттан алар таныш скәмьядә

кочаклашып утыралар иде. Зәкидән, күңелне кытыклап, йокы исе килә.

— Син миңа нык үпкәләдеңме, Зәки?

— Нык.

— Юкка.

— Уйлап та караганым юк, Гәүһәркәем. «Соң ул үпкәләсә дә сиздерә торган кешемени инде, Гәүһәр».

— Нинди уңган кеше син, Зәки. Сыерчык оясы кебек өй салгансың.

— Ә син...

— Сөйләмә инде. Көн юк, төн юк. Ябыкканмынмы?

— Әйе.

— Ямьсезләнгәнмендәме?

— Юк.

— Алдыйсың.

— Юк.

— Ни белән исбат итә аласың?

— Бу дөньяда сине ямьсезләндерерлек көч юк.

Зәки аның битләреннән, күзләреннән, колакларыннан, йомшак чәчләреннән үпте.

— Хәзер ышандыңмы?

— Ышандым.

— Әллә юкка җигелдем дип үкенәсеңме, Гәүһәр?

— Юк, Зәки. Эшем көннән-көн ныграк ошый. Тик кешеләр белән бик тиз уртак тел таба алмыйм. Әллә яшь дип, әллә хатын кеше дип, кайберәүләр санга сукмыйлар. Кайчак кычкырырга, кабинеттан куып чыгарырга туры килә.

— Ә син кычкырма, Гәүһәр. Кемдер, хәтерләмим инде, ачулы кешедән акыл көтмә

дигән. Һәркемнең үзенә генә хас холкы, йөрәге бар. Синең иң беренче һәм иң зур эшең шул йөрәкләргә ачкыч таба белүдән тора. Ләкин ул ачкычларны игәп, бер йозакныкын икенчесенә яратырга тырышма, һәр йөрәккә яңа ачкыч эзлә. Тап. Җитәкчелек эшенең бөтен яме-тәме һәм авырлыгы да шунда, Гәүһәр. Ә кайберәүләр бездә акыру-җикерүне җитәкчелек итү дип уйлыйлар.

— Ә син аларны кайдан беләсең, Зәки?

Гәүһәр аңа гаҗәпләнеп тә, сокланып та карады: «Нинди төпле, салмак кеше ул».

— Ишеткәнем, укыганым бар, — диде Зәки, ачык җавап бирми.

— Сводканы күрдеңме, терлек азыгы әзерләү буенча безнең район Башкортстанда беренче урынга чыкты. Их, бөтен күрсәткечләр буенча да беренче урынга чыгарга.

Зәки аны йомшак кына төзәтте.

— Беренче урынга чыгу гына аз, шул урынны бирмәскә дә кирәк. Моның өчен бөтен колхозларны да алдынгылар сафына җиткерергә кирәк. Ә безнең район алдынгы артельләр исәбенә алда тора.

Бу сүзләр Гәүһәргә әллә ошамады, әллә бу тема аның үзәгенә үткән.

— Куй, без эш хакында сөйләшер өчен очрашмадык. Зәки, син нигә «кайчан кушылабыз» дип сорамыйсың әле?

— Синдә өйләнү кайгысымыни, Гәүһәр. Уттай эш өсте бит.

— Анысы шулай, Зәки. Әллә туйны көзге байлыкка калдырабызмы?

Зәки ияк кага.

— Мин сине гомер буена күтәргә дә әзермен, Гәүһәр.

— Мин дә.

— Ә син «рядовой тракторчыдан» курыкмыйсыңмы?

— Мин синең кочагыңда үләргә дә әзермен, Зәки... — Ул бу сүзләрне озак үбү белән ныгытып куя. — Зәки... син безнең дуслык турында тиешле-тиешсез кешегә сөйләнмә, яме? Ни генә димә, мин бит «район хуҗасы». Илле мең халык миңа карап яши, үрнәк ала. Аннан... эш вакытында миңа шалтыратма. Якшәмбе көннәрен һәрвакыт шушы вакытта мин синең яныңа килермен, яме. Бу курку-өркүдән түгел. Теләсәң, мин хәзер үк синең хатының булырга әзермен. Мәхәббәтнең бөтен матурлыгы серле булуда. Син мине дөрес аңладыңмы?

— Аңладым, Гәүһәр...

Гәүһәр китәргә дип торгач, хушлашу өчен кулын сузгач, Зәкинең хәл-әхвәле турында сораша башлады:

— Сәгать буе утырабыз, эшләрең ничек дип тә сорашмыйм. Гафу ит, Зәки. Ничек яшисең?

— Минем ни... билгеле инде: иске күперләрне җимереп, яңаны салабыз, сикәлтәле юлларны тигезлибез.

— Ярый, хуш. Арыдым. Иртәгә бәйрәм түгел.

— Хуш...

Аңладым... Юк, аңламый башладым мин сине, Гәүһәр. Әгәр дөньяда иң яраткан кешең дә сиңа шикләнеп караса, халык алдында синең белән очрашудан оялса... Юк, Гәү-

һәр аннан шикләнми, аның положениесе шулай куша. Положение... Димәк, положение үзгәргәч, холык та, дус-иш тә үзгәрергә тиеш... Гәүһәрнең чынлап та, хәзер сөйләшүендә, хәтта атлап йөрүендә, көлүендә дә ниндидер үзгәреш бар. Нинди? Зәки үзеп кенә әйтә алмый. Ләкин үзгәреш бар. Ә-ә, төшендем. Гәүһәргә власть белән бергә горурлык, тәкәбберлек тә килгән. Инглизләр, кешене сынарга теләсәң, аңа власть биреп кара, диләр. Дөрес түгел, Зәки. Син боларны гарьләнүеңнән, шикләнүеңнән генә әйтәсең. Гәүһәр урынында булсаң... Нишләр идең?.. Ә ни өчен мин язмышыма баш иеп яшим әле? Ике ел буе «үлем лагерьларында» газап чигү җитмәгән, хәзер ниндидер Шомбаев аркасында да этләнергә тиешмен. Лагерьда бергә булган иптәшләргә хат язарга, гаепсезлекне исбат итәргә кирәк. Исбат итәргә... Шунсыз Гәүһәр дә аңа шикләнеп караячак. Гомумән, мәгънәсез шикләнүләргә чик куярга вакыт.

Зәки, Гәүһәр киткәч, йоклый алмады. Әле бер ягына, әле икенче ягына әйләнеп ятты да, торып киенде, елга буеннан урап килде, тау артыннан калыккан кояшка карап утырды. Аңа күптән Кулагин янына керергә кирәк иде, кул кушырып әллә ни көтеп утырды. Әгәр Кулагин да, Шомбаев кебек: «Сүзләреңне нинди фактлар белән дөресли аласың?» дисә. Ул вакытта... Ул вакытта Зәки лагерьдашларын эзләп, бөтен илне айкап чыгачак. Юл расходына өен, кием-салымын сатачак, ләкин ул лагерьдашларын эзләп табачак һәм үзенең сафлыгын исбат итәчәк.

Күптән әйтелгән мәкаль, кабатлап тора-

сы да юк: без капчыкта ятмый. Зәкинең Гәүһәр белән йөрүе турындагы гайбәт өйдән өйгә кереп, кабарып, ямьсезләнеп, майор Шомбаевның колагына да барып җитте.

«Моны ничек аңларга? Үзе район Советы башкарма комитеты председателе, бюро члены һәм... хәрби пленныйның сөяркәсе. Башка сыймый. Бу бит политик сукырлык. Үз инстинктыңа хуҗа була алмау. Ул-бу конфликт килеп чыкса, министр аңа кирәген бирәчәк. Һич кичектерми, райкомга сигнал итәргә кирәк».

Ә егетләре фронттан урап кайтмаган һәм шунлыктан «карт кыз» дигән ямьсез исем алган кызлар: «Их, алманың асылын корт ашый шул. Аңа җиләк кебек кызлар беткәнмени», дип уфтандылар. Усалраклары такмак та чыгардылар:

Нигә Уфага бармадың,
Әллә поезд киткәнме?
Тол бичәгә өйләнмәсәң,
Сиңа кызлар беткәнме?..

Шомбаев Кулагин янына бик борчылып һәм эшлекле кыяфәттә керде.

— Нигә кәефең начар?— диде Федор Иванович, аның хушбуй исе килеп торган дымлы кулын кысып.

— Күңелсез хәбәр алып килгәнгәдер, Федор Иванович.

— Сөйлә.

— Гәүһәр Мозафаровна... кияүгә чыгарга җыена икән.

Федор Ивановичның авызы ерылды — болай да түгәрәк йөзе тулган айга охшады.

— Шулмы күңелсез хәбәрең? Шельма кыз, нишләп ул миннән яшереп йөри икән. Хәзер үзен котлыйм әле. — Ул кулын телефонга сузды, ә Шомбаев аның беләгеннән тотты.

— Сез элек, булачак ире кем, дип сорагыз, Федор Иванович.

— Әлбәттә, син түгел. Тукта, тукта, син әллә аны... — Кулагин аңа мәгънәле караш ташлады.

— Сез уйлаганча түгел, Федор Иванович. Минем семьям бар. Мин тотнаклы кеше.

— Беләм, сузма.

— Ул доротдел тракторчысы Өметбаев белән чуала.

— Өметбаев, Өметбаев... — Федор Иванович такыр башын уа-уа Өметбаевны хәтерләргә тырышты. — Ә-ә... теге озын, таза егет. Бер каршылыгым да юк. Ә син ни өчен риза түгел?— Шомбаев торды.

— Беренчедән, ул рядовой тракторчы...

— Дәлил көчле түгел. Икенчедән?

— Икенчедән, ул пленда булган.

— Пленда? Аның орденнары бар түгелме соң?

— Анысын пленнан соң алган.

— Ә пленда үзен ничек тоткан?

— Үзенең сүзләренә караганда, яхшы. Ләкин минем коры сүзләргә ышанырга хакым юк.

— Ә сездә аны компрометировать итүче документлар бармы?

— Юк. Ләкин...

— Ә ни өчен ул вакытта ышанмаска?

— Әгәр ул азак...

Федор Иванович чыраен сытты.

—Әгәр шушы урында җир тетрәсә?..

— Бу абстрактно, Федор Иванович.

Кулагин яшел сукно җәелгән өстәлгә алты кырлы кызыл карандашын ташлый да аның тәгәрәп киткәнен карап тора.

— Һәр сугышта да пленныйлар була, майор. Бу — сугышның каһәрле законы. Ә ул... Өметбаев пленга ничек эләккән?

— Контузия... Һуштан язгач алганнар, ди, ләкин исбат итәрлек шаһиты да, документы да юк.

Федор Иванович яшел сукнода тәгәрәп киткән кызыл карандашка карап тора.

— Мин әле Өметбаевны якларга яки хурларга теләмим. Шуны әйтер идем, иптәш Шомбаев, сездә кешеләргә карата патологик ышанмау, шикләнү бар. Юк, юк, бу сезнең вазифагызга бәйләнмәгән. Бу — сезнең каныгызда. Сезнең бу хакта уйлап караганыгыз бармы? Булмаса, үзегезгә ревизия, анализ ясап карагыз. Әгәр сез бу гадәтегезне үзгәртмәсәгез, мин сезнең министрыгыз белән сөйләшәчәкмен. Юк, бу куркыту түгел, ә кисәтү. Бу хәтәр нәрсә. Бу зарарлы нәрсә. Бигрәк тә сезнең эштә. Аңлыйсызмы?

Шомбаев акланырга, боргаланырга тотынды.

— Федор Иванович... Мин сезгә ишеткәнемне информировать иттем. Моны минем положение шулай куша. Яхшы, әйдәгез уйлашыйк. Ярый, Өметбаев чишмә суы кебек саф, ди. Ә шулай да, ике ел пленда булу биографияне бизи торган деталь түгел. Низамова аңа кияүгә чыксын, ди. Райисполком предсе-

дателе, районның хуҗасы, рядовой тракторчыга һәм, ни генә димә, элекке пленныйга кияүгә чыга. Бу безнең өчен, район партия оешмасы өчен плюсмы, минусмы? Минемчә, минус. Ә халык ни әйтер? Гайбәтнең иң нигезсезе дә күләгә калдыра, Федор Иванович. Үзегез беләсез, күрше районның райком секретарен кияве пленда булган өчен эшеннән бушаттылар.

— Җитте! — Кулагин каты креслосына барып утырды.— Беренчедән, аның өчен генә түгел. Икенчедән, аның кияве власовчы булган.

— Аларын да беләм, Федор Иванович. Үзегез беләсез, озакламый Верховный Советка сайлаулар булачак. Бәлки, Гәүһәр Мозафаровнаның кандидатурасы да үтәр. Ә менә тракторчы Өметбаевка тормышка чыкса — шикләнәм. Биографиясендә тап була. — Ул утырды. — Сез аның белән сөйләшеп карагыз, Федор Иванович. Без, аңа ышанып, шундый пост тапшырдык, ә ул үзенең шәхси интересын югары куя.

Кулагин аны ачулы бүлдерде.

— «Шәхси интерес»... Таушалган лозунглар белән сөйләшәсең, майор. Кешенең шәхси бәхете булмаса, аны җәмәгать интереслары гына канәгатьләндерми. Без, коммунистлар, шәхси һәм җәмәгать интересларының тулы гармониясе өчен, бүленмәүче, бөтен бәхет өчен көрәшәбез. Ә син ул бәхетне, борчак кебек, икегә бүләсең: шәхси һәм җәмәгать... Их, майор, майор...

— Аңлыйм, Федор Иванович. Мин дә кеше. Мин, чекист буларак, сезгә сигнал би-

рергә тиеш идем. Сау булыгыз. — Ул, устав кушканча борылып, чыгып китте.

«Чекист...» Изге сүз белән спекуляция ясый. Ә, бер карасаң, майор сүзендә ниндидер дөреслек орлыгы да бар. Без бит Гәүһәр Мозафаровна белән рядовой эшчеләр түгел, ә җитәкчеләр. Безнең күңелләрдә һәм биографияләрдә аз гына да күләгә булырга тиеш түгел. Без — сафлык һәм... гүзәллек үрнәге булырга тиешбез. Безнең эштә эшләүченең күренер-күренмәс йомшаклыгы, җиңел уйлавы, яшен тизлегендә, башкаларда да чагыла башлый. Без халык уйларының һәм хәстәренең барометры булырга тиешле. Хәзер үк Гәүһәр Мозафаровнаны чакырам. Ләкин мондый мәсьәләдә саклык һәм үтә сизгерлек кирәк. Әллә башта Өметбаев белән сөйләшеп алыргамы? Дөрес...»

Ә Өметбаев аны алгы якта күптән көтеп утыра иде инде. Кабинетка озын, аю кебек, килбәтсезрәк гәүдәле, искиткеч ачык йөзле, чаллана башлаган чәчле кеше керде. Аның хәрәкәтендә, кыланышында һәм сөйләшүендә үзен тота белүче кеше икәне сизелә. Мондый кешеләр зур белемле һәм акыллы булалар.

— Узыгыз. Утырыгыз. Сез мине байтак көткәнсез икән. Гафу итегез. Тартыгыз.

— Рәхмәт, тартмыйм.

— Элек тә тартмадыгызмы?

— Авызыма да алганым юк.

— Яхшы... Иптәш Өметбаев, әйдәгез ачыктан-ачык сөйләшик. Мин сезне чакыртырга теләгән идем, ә сез, мине узып, үзегез килгәнсез. Үзегез турында сөйләгез әле. Ба-

лалар әйтмешли: тамчысын да калдырмый. Әтиегезгә сөйләгән кебек. Мин, мөгаен, сездән ике тапкырга өлкәнрәктер әле.

Зәки «тамчысын да калдырмый» үзенең кыска, ләкин авыр гомере турында сөйләп бирде.

...Бер сынык арыш икмәгенә интегеп үткән балачак... Сәнәк сугышы вакытында әтисенең һәлак булуы... Уңдүрт яшьтә авылдан чыгып китү... Пристаньда эшләп уку... Азак Ростовта институт бетерү... Сугыш. Яралану. Тагын фронт, тагын яралану. Хурлыклы, кешенең кешелеклеген мыскыллаучы, җанын һәм тәнен газаплаучы плен...

Гомеренең бер генә битен дә яшермәде, ике-өч битен берьюлы ачмады яки бөкләп калдырмады ул, сөйләде, тик Гәүһәрне ярату турында гына «онытты». Кыска, ләкин фаҗигале иде аның биографиясе. Мондый гомер кешене я корычка, я камырга әйләндерә.

— Ә сезнең белән лагерьда булган бер генә иптәшегез дә юкмы?

— Бар, әлбәттә, ләкин аларны кайдан эзләп табасың.

— Табарга кирәк, туган. Бездә бит әле, кызганычка каршы, формалистлар, кәгазь җаннар һәм куркаклар, карьеристлар очраштыргалый. Менә нәрсә, туган... сезнең хатыныгыз бармы? (Федор Иванович бу сорауны юри бирде.)

— Юк.

— Ә... кандидатурагыз бармы?

— ...

— Ярый, анысы минем эшем түгел. Бер-

кемгә дә бүлешми торган серләр дә була бит. Мин бүген үк Уфа белән сөйләшәм дә, сезне инженер-механикларның квалификациясен арттыра торган курска җибәрәм. Уфа бездән бер кеше сораган иде. Каршы килмисезме? Сез бит институтны тәмамлаганнан соң белемегезне практика белән ныгыта да алмагансыз. Килештекме? Курстан соң без сезне МТСка баш механик итеп билгеләрбез.

Зәкинең бугазына төер тыгылды, күз төпләренә рәхмәт яшьләре атылып чыкты. Кулагинның аңа ышануы, җылы сүзе аның күңелен тутырды. Күптән аңа райкомга кереп зарын сөйләргә кирәк иде. Нидер көткән булды: алма пеш, авызыма төш, имеш. Көт, төшәр. Аның хәзер үк Гәүһәр янына атылып кереп аны кочаклыйсы, күтәреп, ишеклетүрле йөртәсе, шатлыгын түгәсе килде. Юк, ярамый. Ул бит ике тапкыр: «Кеше алдында минем белән очрашмаска тырыш», дип кисәтте. Кеше алдында... Димәк, ябалак яки ярканатсымак төннәрен генә күренергә... Ышанмый ул Зәкигә. Ышанса да, гайбәттән курка. Бәлки, аның урынында син дә шулай эшләр идең, Зәки. Юк, эшләмәс идем. Ышансаң, курыкмыйсың да, шикләнмисең дә. Ярар, ярар, шундый шатлыклы көнне Гәүһәреңә үпкәләмә. Һәркемнең дә холкы-табигате бер төрле булмый. Ничего, Гәүһәр Мозафаровна, озакламый Зәкидән оялмаячаксың. Зәкиең дә, башкалар кебек, башын күтәреп, күкрәген киереп йөрер. Ул эшләгән МТС элек районда, аннан республикада иң алдынгыларның берсе булачак. Ул эшли белә. Тик аңа ышансыннар гына, тик аңа колач киереп

эшләргә ирек кенә бирсеннәр. Ул үзенең «хурлыклы табын» шундый юачак, хәтта эзе дә калмас.

Ә Кулагинны башка уйлар борчыды: ни өчен Низамова аңа Өметбаев хакында аз гына сиздермәде, сөйләмәде? Аның пленда булуы турында белмәде микән? Белергә тиеш. Ә бәлки Шомбаев гайбәт сөйләгәндер. Ләкин руслар, утсыз төтен булмый, диләр...

Низамованың бу кыланышы аны, йомшак әйткәндә, аптыратты. Ничек инде кешене яратырга һәм шул ук кешегә ярдәм кулы сузмаска. Аңламыйм, ышанмыйм... Тәрәзә янында, кулларын аркасына куеп, райком ишек алдында ат җигеп маташкан Сәхип картка карап торганнан соң, ул ашыгып өстәл янына килде дә, календарьның «Шимбә» дигән битенә «элекке пленныйларны җыярга» дип язды. Бәлки, районда Өметбаев кебекләр берәү генә түгелдер. Ах, Федя, Федор Иванович... кулың җитмәгән күпме эшләр бар. Ә моның сәбәбе шул: эшне хуҗалык һәм политик кампанияләр буенча гына алып барсаң да, «вак-төяк» мәсьәләләрне онытасың. Ә Ленин, партия эшендә вак эш юк, алар барысы да мөһим, дигән. Мөһим... Әлбәттә. Өметбаевның язмышы мөһим түгелмени... Армиядә рота командиры һәр солдатның винтовкасы, портянкасы өчен генә түгел, ә уйлары, кәефе өчен дә җаваплы. Райком секретаре да шулай булырга тиеш. Тиеш...

Зәки бу төнне, бәлки, өенә кайтканнан бирле беренче тапкырдыр, татлы, каты йокыда үткәрде. Иртән торганда ул үзен, бала чактагы кебек, җиңел, шат, гамьсез тойды.

Ә эштә аны яңа шатлык көтеп тора иде: Кулагин юл бүлеге мөдиренә шалтыраткан: Уфа риза. Өметбаев бүген үк юлга чыксын. Курсның башлануына инде ун көн, дигән.

Бүген үк... Мәскәү поезды килергә ике сәгать ярым вакыт бар... Әзерләнергә һәм... Әллә ни әзерләнәсе юк та. Хәзер үк Гәүһәрне күрергә кирәк.

Ул райисполкомга китте. Гәүһәр өйдә юк иде. Иң ерактагы «Бүре оясындагы» колхозга киткән икән. Кичә үк. Зәки сәгать буе телефонда «утырды», ләкин Гәүһәре белән сөйләшә алмады. Поезд килергә сәгатьтән аз гына вакыт калгач, ул кирәкле әйберләрен чемоданга эштер-өштер генә тутырды да Гәүһәргә озын итеп хат язды. Хат җыр кебек иде.

Ләкин ул хат адресатына барып җитә алмады, җырны Хөснури ханым җырлатмый утка якты.

Районнан Гәүһәр соң кайтты. Министрлар советы аңа яңа машина биргән иде, шуңа күрә ул машинадан бик канәгатьләнеп чыкты, ишеген игътибарсыз гына шап итеп япты. Машина киткәч тә, аның артыннан елмаеп карап торды: «Шә-әп...»

Ул арада өйдән Хөснури ханым чыкты.

— Өйгә кермисеңмени?

— Әзрәк һава иснәп килмәкче булам.

— Беләм мин синең «һаваңны». Йөрмә. Пленнигың башын алып чыгып качкан инде.

— Әни... Җитәр сиңа. Аның турында шундый тонда сөйләшергә мин сиңа рөхсәт итмим.

— Аба-ба-ба... «Рөхсәт итмим». Районга хуҗа дигәч тә, әллә әниеңә дә хуҗа булмакчы буласыңмы? Ышанмасаң бар да кара. Поездга утырып киткәнен үзем күрдем. Өстендә шул каткан фуфайкасы иде...

Гәүһәр кинәт әнисе ягына борылды.

— Кая барасың дип сорашмадыңмы?

— Бик. Шуның белән сөйләшеп телемне әрәм итәргә. Я Ташкентка, я...

— Ул үзе дә сиңа бер сүз дә әйтмәдеме?

— Ул мине күрмәде.

— Хат-фәлән дә калдырмадымы?

— Хат?.. Юк. Юк, юк.

— Ышанмыйм...

— Ул берәдәккә мин беренче күрүдә үк ышанмаган идем.

— Әни... Нигә син кешеләр хакында гел генә начар уйлыйсың?

— Нинди кеше бит...

«Барып әнисеннән сорашырга кирәк: кая, нигә һәм күпмегә киткән? Бәлки, берәр атнага гынадыр...» Гәүһәр ярты юлдан кире борылды. «Тукта, ни өчен мин аның артыннан йөрергә тиеш әле?» Юк, Гәүһәрдә «хатынкызлар горурлыгы» уянмады, ә... «Мин райисполком председателе, ә ул рядовой тракторчы. Ул минем эзләремне үбеп йөрергә тиеш. Китсә кайтыр әле. Гомерлеккә китмәгәндер» вазифасының дәрәҗәсе тыйды.

Ә шулай да төн тынгысыз үтте. Юк, телефон звонокларыннан түгел, ә башка көчләп кергән борчулы уйлардан йокы куркып йөрде. «Кая, нигә китте икән? Озакка булса, нигә аны күрми киткән?..»

Икенче көнне шикләнү болытлары тарала

төште. Ул райкомда, Кулагин янында булган икән, Кулагин Уфа белән киңәшеп, аны Ростовка берьеллык курска җибәргән. Бер елга...

Кулагин боларны юл уңаенда гына сөйләгән булды һәм әледән-әле Гәүһәр Мозафаровнаның күзләренә күз салды. Гәүһәрнең бу хәбәргә аз гына да исе китмәде — йөзе тыныч, хәтта салкын иде. Ә йөрәкне песи тырнады. «Бер елга... киткән, мине күрмәгән... Озын бер елга...»

— Сез аны беләсезме? — диде Федор Иванович, бер күзен хәйләкәр кысып.

— Беләм.

— Һәм яхшы беләсезме?

«Ни дип әйтергә? Бер елга киткән, мине күрмәгән. Ялындырмакчы булды микәнни? Көт...»

— Юк. Кайчандыр, спектакльдә бергә уйнаган идек.

— Шулай гынамыни?

— Шулай гына.

«Көтәргә вакыты булмаса, нигә кош теледәй хат, язу язып та калдырмаган? Үпкәләгәндер. Әлбәттә. Ә аның үпкәләргә хакы юк. Үзеңнән югарыга үпкәләмиләр».

— «Таллы елга» колхозында быел ашлык шундый яхшы күренә, — дип, эшкә күчте Гәүһәр...

Федор Иванович нидер сизенде, ләкин сизенгәнен сиздермәде, ә дөресрәге, ул әле үзенең ни нәрсә сизенүен ачык кына белми иде.

Юк, Зәки үпкәләмәде. Үпкәләү дигән нәрсә аңа бала чактан ук ят иде. Әле дә хәтерендә. Беренче класска укырга кергән елда

ул, ни өчендер, үпкәләп, өстәлгә куйган ашны ашамый, почмакка барып утырды. Әнисе, кил, балам, утыр, менә сиңа итнең зурысын салдым, дип аны юатып, көйләп тормады, аның ашын башка балаларына бүлеп бирде. Зәки ачуыннан нишләргә белми, борынын лышык-лышык тартып утырды да ач көенчә ятып йоклады. Менә шул көннән алып ул үпкәләүнең «зарарын» аңлады һәм башка беркайчан да үпкәләп карамады.

Ул Ростовка барып җитү белән, беренче төндә үк Гәүһәргә хат язды, нидер сизепме, әллә болай гынамы, хатны райисполкомга җибәрде. Бу хат та җыр кебек иде. Хат Гәүһәрнең тойгыларын уятты. Ул эшкә күмелеп утырганда, эшен онытып, хискә чумды, шомырт чәчәкләрен, «Галиябану» спектакленнән соң, тыгыз, тынчу сәхнә артында беренче тапкыр үбешүләрен хәтерләде. Нинди бәхетле минутлар иде... Кабат урап килер микән?.. Әллә тәүге үбешү шатлыгы беркайчан кабатланмый микән?..

Ул күкрәге хисләргә тулы вакытта хат язмакчы булды.

«Сөеклем Зәки...»

— Гәүһәр Мозафаровна, сезгә Уфадан шалтыраталар...

— Фу...

Хат башланды һәм ташланды. Кичен, инде тынычлангач, арыгач, ул: «Ярый, иртәгә телеграмма гына җибәрермен», дип уйлады. Ә иртәгәләр үтте дә үтте, беркемнән дә, хәтта район башкарма комитеты председателеннән дә рөхсәт сорап тормады.

Күңеле һәм куллар буш чагында Гәүһәр,

Зәкине искә төшереп, хат язарга да омтылып карады. Ә соң моңа кадәр җавап язмауны ничек аңлатырга? Вакыт юк дип акланырга тырышу берәүне дә ышандырмас. Аның ире ике атака арасында да өч сүзле генә булса да хат язып җибәрә торган иде. Ә ул фронтта түгел. Егерме дүрт сәгатьнең ичмасам ике сәгатен үзенә генә багышларга була бит инде. Гомумән, ни өчен акланырга? Хаты килеп тора: исән-сау... ә инде кәгазьгә «яратам, сагындым» дип язудан ни файда? Аннан сагынуың артмый да, кимеми дә. Үлмәгәнгә бер ел үтә дә китә ул. Кайтсын, яңа эштә үзен танытсын, партиягә керсен... Шул вакыт күз күрер. Ә хәзергә... бераз читтәрәк торып торсын. Саклангынны алла саклар, ди аның аллага беркайчан да юньләп ышанмаган әнисе.

Алда Верховный Советка сайлаулар тора, йөрәгеңә хуҗа була алмый, авызыңны ачып калуың бар. Бәлки, аны депутат итәрләр. Ә нигә итмәскә? Район алдынгы, хатын-кыздан райсовет председателе булып эшләүче кеше Башкортстанда бер-ике генә.

Үзеңнән яшереп булмый инде: аның бик депутат буласы килә. Алар белән институтта бер депутат кыз укыган иде. Заманында тракторчымы, комбайнчымы булган. Уртача гына укыса да, аны кая гына тыкмый торган иделәр... Һәр җыелышның президиумында — ул, комсомол комитетында — ул. Мәскәүгә Бөтенсоюз авыл хуҗалыгы күргәзмәсенә — ул... Менә хәзер Гәүһәр Мозафаровна да депутат булачак. Обязательно.

Һәм ул үзен-үзе онытып, ниндидер бер ашкыну, котырыну белән эшләде. Ял, йокы

дигән нәрсәне онытты. Кайда туры килде, шунда башын мендәргә ике-өч сәгать терәп алды да, тагын сикереп торды, тагын басуларга, МТСларга чапты, нефтьчеләрдән ялынып-ялварып, тракторлар, автомашиналар алды һәм, республикада икенче булып, дәүләткә ашлык тапшыру планын үтәде.

Федор Иванович Гәүһәр Мозафаровнаның дәртенә, энергиясенә сокланып туя алмады. «Мондый бетмәс-төкәнмәс көч, сүнмәс ут аның кай җирендә саклана икән? Әйтерсең, мәңгелек аккумуляторы бар...»

Ләкин Гәүһәрне, ни өчендер, депутатлыкка күрсәтмәделәр. Бу беренче һәм күз аллары караңгыланырлык удар иде. «Әйтерсең, өч класс белемле комбайнерка аннан яхшырак һәм лаеграк. Депутат булып, ни кыра инде ул? Сессияләргә йомшак вагонда буш йөри. Кул күтәрегез дисәң, күтәрә, төшерегез дисәң, төшерә. Менә аның бөтен депутатлык вазифасы. Дәүләт эшлеклесе имеш. Көлке... Ничего, алдагы сайлауда ул үзенекен итми калмаячак». Бу кайгы башка бөтен вак-төяк хәсрәтләрне этеп чыгарды һәм ул ниндидер вакытка чаклы Зәкиен бөтенләй онытты, хаты килсә, укып тормый, ертып ташлады. Әйтерсең, аның депутат булмавында Зәки гаепле иде.

Ә хатлар башта еш, атна саен килделәр, дүртәр битле булдылар, азак ул битләр саны икегә, бергә калды һәм атна айга алышынды, тора-бара бөтенләй юлларын югалттылар.

Хатлар килми башлагач, Гәүһәрдә ниндидер, аңлаешсыз борчылу башланды: «Нигә

язмый ул? Язмасын, ялынмыйм. Әллә үземә язаргамы? Юк, башта ул язсын әле, аннан күз күрер. Әгәр бу атнада хаты килмәсә, алдагы атнада алсам да, җавап язмаячакмын».

Хатлар килмәде. Бу атнада да, алдагысында да, алдагы айда да... Һәм курстан соң Зәки әйләнеп тә кайтмады. Суга ташланган таш кебек, югалды, тик күңелдә түгәрәкләр-дулкыннар гына торып калды. Хәер, аларны да вакыт таратып бетерде. Елга — Гәүһәр җәйге эссе көндәгесымак, бөтенләй тынычланды.

Шулай итеп, тагын, тагын шомырт чәчәк атты. Атты да коелды. Чәчәкнең, бигрәк тә шомырт чәчәгенең, гомере кыска була бит ул. Гәүһәр күзгә күренеп тазарды, йомрыланды һәм юанайды; атлап йөреше, тупасрак әйткәндә, ана үрдәкнекенә охшый башлады, тавышыннан власть, тимер ишетелде һәм, чакырылмаган, көтелмәгән кунак килеп житте — чәчләрдә ак җепләр күренде. Дөрес, алар салам төсендәге чәч арасында ярылып ятмый, ләкин аларны һәр көн иртән Гәүһәр үзе күрә. Ә бу башкалар күрүгә караганда хәтәррәк. Әгәр тәүге ак чәчләр ирләрдә олылык тойгысы уятса, хатыннарда үкенү, сулу хисләрен кузгата. Ә хатыннарның иң курыкканы — иртә картаю. Алар яшьли үләргә әзерләр, ләкин карчык булырга теләмиләр. Бу сүзне алар бигрәк тә кыз вакытта әйтергә яраталар.

Беренче тапкыр ак чәч бөртеген күргәч, Гәүһәрнең йөрәген кемдер учына салып, бар көченә кысты, күз аллары караңгыланды, ты-

ны куырылды, әйтерсең, үлем килеп, аны кочаклады. Ак чәч... Ярабби.. Ә бит әле аның ире дә, бер генә баласы да юк. Ә табигать хатыннарны кешелек ыруын дәвам иттерер өчен ярата. Шулай итеп ул шәхси бәхетеннән колак какты микәнни? Нигә соң моңача ул бу хакта аз гына да уйлап карамады? Эш, диде, дан, диде, ә кайда соң ул дан? Райсовет председателе булып, көне-төне колхоздан колхозга чабу, таң атканчы җыелышларда утыру, кул астындагы кешеләрне әрләү, начальниклардан үзең әрләнү... Бер генә көн, бер генә сәгать тә үзеңә үзең хуҗа түгелсең. Шулмы бәхет, шулмы ләззәт... Баш агроном булып эшләгәндә ул үзен нинди иркен, бәхетле тоя иде.

Бүген үк, хәзер үк Зәкинең әнисе янына барып, улының адресын алырга да, йөрәк әчесен түгеп, хат язарга. Яратса, гафу итәр. Алар бит бер-берсен яраталар иде. Гәүһәр әле дә аны элеккечә ярата. Бәлки, элеккедән дә ныграктыр. Мәхәббәтнең көчен, тирәнлеген аерылышып яшәми белеп булмый бит ул.

Менә Зәкинең үз кулы белән салган йорты. Чардак тәрәзәсе астына яшел буяу белән йортны сипләгән ел язылган: 1946. Ярабби, ничә ел үткән... Ә бит Зәки аны Гәүһәрнең кушуы буенча сипләгән иде. Көндез тракторда эшләде, ә кичен, төннәрен электр яктысында йорт салды. Гәрәбә кебек нарат тактадан эшләнгән капканың төсен җил-яңгыр бетергән. Хәзер ул күксел-соры төскә кергән. Террасадагы пыяла өлгеләре дә ватылгалаган.

Ишекне ят карчык ачты.

— Саумы, әби. Зәкинең әнисе өйдәме?

— И-и бәбкәм. Ул былтыр көз, бәрәңге алгач та, өен сатып, улы янына китте инде.

— Ә улы кайда? Адресын беләсезме?

— Оныгым белә бугай да, ул әле мәктәптә. Кичкә таба килеп чык. Син аларның кеме буласың?

— Минме... Мин авылдан килдем.

— Кайсы авылдан?..

— ...

Ә ул адрес белән нишләр соң? Нишләр... Гафу үтенер, үкенечен язармы? Юк, язмас. Үлгәндә дә язмас. Шулай булгач, Зәкинең адресы аңа нигә кирәк?

Гәүһәр башын күтәрә һәм, очраган кешеләр белән ияк кагып кына исәнләшеп, кайтып китә.

Горур, һавалы ул безнең Низамова, диләр берәүләр, илла бәхетле булды бу Гәүһәр, диләр икенчеләр, ә һичкем, хәтта иң якын дуслары да, Гәүһәрнең эчендәге янган ялкынны күрми дә, белми дә.

Кешеләр аны бәхетле дип саный. Кайчак Гәүһәр үзе дә үзенең бәхетле булуына ышана. Чөнки ул озак еллар омтылган теләгенә иреште: аны депутат итеп сайладылар, юбилей даталарының берсендә орден бирделәр. Ә күңел һаман Зәкине эзләп юксына. Зәкидән соң аның юлында шактый күп ирләр очрады, ләкин очрау беләнмени... Очраган бер кеше синең йөрәгеңә хуҗа буламыни. Мәхәббәт гаҗәп бер нәрсә бит ул: сөйләп тә, аңлатып та булмый.

Һәр яз саен ул шул йортта яшәүче карчыкка акча биреп, койма, капкаларны буяттыра. Төннәрен килеп, капка төбендәге скәмьядә утыра. Шомырт чәчәкләрен чаллана башлаган йомшак чәчләренә кадый, авызына каба... Күзләрен йомып, күптән, әйтерсең, моннан мең ел элек булган гүзәл сәгатьләрне хәтерли; кайтышлый шомырт чәчәге сындырып ала, кабинетына алып барып, салкын сулы вазага куя. Әгәр секретарь кыз аның суын алмаштырмаса, чәчәкнең, язның, яшьлекнең кадерен белмисең дип, аны кеше алдында әрли.

Еллар аяусыз рәвештә аның йөзен картайта, ә мәхәббәт эзләүче йөрәген яшәртә. Чынлап та, тәүге мәхәббәтне язгы күкрәү белән чагыштыралар. Ул табигатьне йокысыннан уята, кешеләрнең йөрәген җилкендерә. Ләкин язгы күкрәү нинди көчле булмасын, тиз үтә һәм онытыла. Ә менә җәйге яшеннәр гомергә онытылмый. Бишәр, унар ел үткәч тә, «Һаайй... Фәләненче елны көчле яшен булган иде, ун йорт янган иде. Ә ашлык шундый уңган иде, салырга буралар җитмәгән иде», дип хәтерлиләр. Гәүһәрнең мәхәббәте дә җәйге яшен кебек көчле һәм үкенечле булды. Ә аның үкенечле булуына кем гаепле соң? Майор Шомбаевмы, шул вакыттагы кайбер хата приказлармы, әллә фәкать Гәүһәр үзе генәме. Моны укучы үзе уйлап әйтер инде. Минем эшем — күргән-белгәнне төкми-чәчми сөйләп бирүдән тора.

Бәлки, шушы урында хикәяне очларга кирәктер. Юк, янә бер-ике сүз әйтми булмый.

Былтыр көз Мәскәүдә, Кремльдә, Гәүһәр

белән Зәки җаваплы бер киңәшмәдә очраштылар. Зәкинең түшендә урак-чүкеч төшкән алтын йолдыз иде. Ул зур бер заводның инженеры икән. Ә калганы... Калганын сорарга Гәүһәрнең батырчылыгы җитмәде. Әгәр Зәки, хатыным, балаларым бар, дип әйтсә, я ул кычкырып җибәрер, я һушыннан язар иде. Зәки дә аннан шәхси тормышы турында сорашмады: әллә кыенсынды, әллә кызыксынмады. Тик хушлашканда гына: язын, ял алгач, туып-үскән якларга кайтып киләм әле. Күптән кайткан юк бит, диде.

Инде шомыртлар чәчәк атты. Кайтыр микән?.. Кем белән кайтыр икән? Ялгыз булса ярар иде. Гәүһәр аның белән җәяүләп дөнья чигенә китәргә дә риза булыр иде. Юк. Ялгыз булмасын иде, сөекле хатыны, бала-чагалары белән гөрләшеп кайтып төшсен иде. Барыбер хәзер үткәнгә әйләнеп кайтып булмый бит. Ә нигә булмый... Чөнки табигатьтә яз ел саен килә, ә кешеләргә — бер генә.

Еракта, таулар-урманнар артында күк күкри. Бу быелгы тәүге күкрәү. Ә Гәүһәр Мозафаровнаның өстәлендә салкын сулы вазага куелган шомырт чәчәге тора. Зәкинең бакчасыннан бүген төнлә сындырып алган чәчәк ул. Зәки йөрәге кебек, аның Зәкигә булган мәхәббәте кебек ак һәм пакь чәчәк ул.

*

* *

— Иптәш Низамова үзендәме?
— Үзендә.
— Кәефе, сәламәтлеге ничек?

— Өстәлендә шомырт чәчәге тора...
— Шомырт чәчәге?..
— Нигә елмайдыгыз?
— Болай гына. Ниндидер бер өй каршында үскән шомыртны хәтерлим...
— Ел буе яз булса, нинди күңелле булыр иде, агай, ә?..
— Ул вакытта агачлар беркайчан да җимешләнмәс иде, туганым. Гәүһәр Мозафаровнадан сорагыз әле: керергә ярыймы икән?
— Ә сезнең фамилиягез ничек?
— Өметбаев.
— Өметбаев?..

САНДУГАЧЛАР РАЗЪЕЗДЫ

Зәки Нурига

Мине сандугачлар уятты... Каян килгән алар? Мин торып тәрәзә пәрдәсен күтәрдем— күз күреме җитәрлек һәр җирдә йокымсырап яткан сахра, аксыл яшеллектә җемелдәүче яшь арыш. Тик паровоз янында гына, ятим бала кебек, стрелочникның сары будкасы тора.

Нигә монда торабыз? Ә сандугачлар кайдан килгән? Безнең поездны каршыларга Дим ярындагы таллардан очып килмәгәннәрдер бит инде? Сорар кеше юк. Купедагы бердәнбер юлдашым Фәттәхов та әллә кая. Коридорга чыгам һәм тәрәзәне ачып карыйм. Тимер юлның бу ягыннан ерак түгел җирдән каенлык башлана икән. Менә шуны сандугачлар үзләренә сайлаганнар да инде. Аланнардан әле томан күтәрелә. Димәк, каенлык артында я елга, я эре әрекмәннәр үсә торган юеш чокыр бар.

Коридордан ут күзле, зифа буйлы, купшы проводник кыз үтеп китте.

— Хәерле иртә! Хәерле иртә!— дип ул пассажирлар белән ягымлы исәнләште.— Ничек йокладыгыз? Нинди төшләр күрдегез?

— Иптәш проводница, бу нинди разъезд?— дип сорыйм мин аннан.

— Сандугачлар разъезды,— ди ут күзле кыз, карашы белән ялмап.

— Искиткеч матур исем!

— Мин кушкан исем,— ди проводник кыз, күкрәгенә төртеп.— Болай аны «519» нчы дип йөртәләр.— Ул ачкычы белән күрше купеның ишегенә иплэп кенә шакыды.— Әй, йокы чүлмәкләре, бер сәгатьтән сезнең станция!— Ул минем якка борылды.— Москвадан алып Уфага чаклы мондый ямьле, күңелле разъезд юктыр. Ә менә шул разъездга исем бирмәгәннәр, номер белән йөртеләр. Көлке, шулай бит?.. Уфага кайткач та министрга хат язам. Үзегез уйлап карагыз, әгәр барлык шәһәрләр, станцияләр дә номер белән генә йөртелсә? Көлке, шулай бит? Их сайрыйлар, бәгырькәйләрем. Эһ тә итми торып калырыем.

— Ә без биредә озак торабызмы?

— Юк. Каршы килүче поездны көтәбез.

Ул «Сайра, сайра, сандугач» дип әкрен генә җырлап, вагонның икенче башына китте.

Паровоз, ут күзле проводник кызның сүзләрен дөресләргә теләгәндәй, тәкатьсезләнеп кычкырды. Ул арада минем юлдашым Фәттәхов та күренде. Ул урта яшьләрдәге, буйчан, сөйкемле кеше. Ял кебек озын, йомшак чәчләре артка сыпырган саен үзсүзләнеп кабат маңгаена төшә. Фәттәховның йөзе ачык, карашы шаян. Әйтерсең, бу матур йөз беркайчан да кайгы-хәсрәт күреп борчылмаган. Ул, килештереп, үз тавышына үзе соклангандай, җайлап кына сөйләшә.

— Хәерле иртә. Сез кайда югалдыгыз?

— Күрше вагонга барып, бер иптәшем бе-

лән хушлашып килдем. Москвада, күргәзмәдә дуслашканыек.— Ул әйберләрен җыя башлады.— Алдагы станциядә миңа төшәргә.

Мин, үземнең белдеклелегемне күрсәтергә тырышып, аннан сорадым:

— Сез бу разъездның законсыз исемен беләсезме?

— Сандугачлар разъезды.

— Проводник кыз әйттеме?

— Юк.

— Үзегез атадыгызмы?

— ?..

Фәттәхов тиз генә җавап бирмәде. Аның гамьсез йөзе уйчанланды. Күзләренә сагыш чыкты. Ләкин бик тиз арада ул күзләргә янә элекке дәрт һәм яшьлек кайтты.

— Каенлыкта бер генә сандугач булмаса да, мин бу разъездга «Сандугачлар разъезды» дип исем бирер идем.

Мин кызыксындым.

— Нәрсә, берәр легенда-фәләнгә бәйләнгәнмени?

— Әйе.

— Бәлки, сөйләрсез.

— Өлгерерменме?.. Хәер, минем станциягә чаклы ярты сәгатьтән артык вакыт бар әле.

Поезд кузгалды. Фәттәхов хикәясен башлады.

— Дөресен әйткәндә, бу легенда түгел, ә булган хәл.

...Каенлыкны күрдегезме? Әнә шул каен урманы артында зур бер авыл бар. Бер очыннан икенче очына чаклы биш километрдан артык. Сугыш вакытында дүрт колхозга

буленгән, ә хәзер янә бер артель — «Якты юл» дип атала. Бөтен районга дан тота. Ә утызынчы елларда колхоз бер генә ягы белән дә мәшһүр түгел иде. Мактамадылар да, хурламадылар да. Урта хәлле хуҗалык! Әмма аны Гәүһәр исемле бер чибәр кыз аркасында бөтен тирә-як белә иде. Зоотехник булып эшләде. Хәер, шаккатарлык чибәр дә түгел инде. Минем гомерем эчендә аннан да матуррак кызларны күргәнем булды. Ничек итеп аның төс-башын сөйләп бирергә икән? Хәтердә калырлык бер дә әллә ние юк. Йөзгә — каракучкыл, урта буйлы, нечкә билле. Күзләре чем-кара, карлыган төсле, тамам-тамам дип торалар; үзләре зурлар, үзләре шаяннар. Алай безнең якта кара күзле, шаян карашлы кызларга кытлык юк инде. Караш дигәннән, менә карашын һич сөйләп-аңлатып бирерлек түгел: я, ул сиңа, ана баласына карагандай, бик ягымлы, бик җылы итеп карый, я, сагынган кыз егетен күргәндәгедәй, өзелеп карый... Ул чакта аңа унтугыз яшьләр чамасы иде — гомеренең иң бәхетле чагы. Ә бу чакта кызлар җитез дә, назлы да була. Соң назлы булмаган кызлар буламыни инде...

Менә ул урамнан үтеп бара. Ашыксаң, син аңа игътибар да итмисең. Әгәр туктап, бераз сөйләшеп торсаң, кая, нигә ашыкканыңны да онытасың. Синең күңелеңә үзең дә аңламаган нindидер бер гаҗәп тойгы керә. Шушы көннән алып синең ашаганың аш, эчкәнең су түгел, һәм син аны күрергә җай гына эзләп йөрисең. Адәм ышанмастай сүзне чын булса да сөйләмә, диләр, ә менә мин

сөйлим. Колхозда нинди генә егетләр юк иде ул заманада! Береннән-бере чая, усал — утка да, суга да ыһ та итми керерлек малайлар. Колхоз председателе аларны тыя, тыңлата алмый торганые, ә менә шул нечкә билле, ипле тавышлы Гәүһәр күренсә... балавызга әйләнәләр дә китәләр.

Шул авылда Зөлкарнәй һәм Хәниф исемле ике дус яшәде. Авыл, бая әйткәнием инде, зур, биш мәхәлләле булган. Дуслар авылның төрле очында яшәсәләр дә, аларны аерым күрүе мөмкин түгел иде: көндез дә, кичен дә, эштә дә, кичке уенда да гел бергә. Өстәвенә алар, игезәкләр кебек, бер-берсенә шундый охшаганнар: икесе дә озын, таза гәүдәле, икесе дә кара күзле. Хәтта аюсымаграк атлап йөрүләре дә бер-берсенекенә охшаган. Алар бер-берсенә охшатып күздән яшьләр китерерлек әче, үткер самосад тарталар, фырт кына итеп теш араларыннан төкерәләр. Ә кызлар очраса, исән котылам дип уйламасын инде: я аңа күзе маңгаена атылып менәрлек исем атыйлар, я суганлы-борычлы такмак чыгаралар. Укырга аларның күңелләре тартмый — сигезенче классны ташлап китәләр. Авылда бу икәүне Ишәй белән Кушай дип йөртәләр. Берәүләр аларга соклана, икенчеләр мәгънәле елмая, ә өченчеләр кул гына селти: «Кеше чыкмаячак. Әчегән ялкаулар». Дөресен дә, аларны тракторчылар курсына да җибәреп карадылар. Хәниф салкын тидереп чирли дә курсны ташлап кайта. Ә Зөлкарнәй ахирәтеннән аерыла аламыни: «Керосин исе башыма каба» дип курстан кача.

Шуннан соң болар бригадир нәрсә кушса, шуны эшләп йөриләр: кышын басуга тирес түгәләр, кар тоталар, ә җәен ургыч машина белән урак уралар. Берсе, алда утырып, атларны йөртә, икенчесе, сәнәк белән урылган игенне пакоска ташлый. Бераздан урыннарын алышалар. Озын көн буе шулай. Ай буе шулай. Ә эш җиңел түгел! Әмма егетләр язмышларына сукранмадылар, боекмадылар. Дөресрәге, алар үзләренең язмышлары турында уйлап та бирмәделәр. Бер көнлек күбәләк шикелле яшәделәр: көн үтсен дә, төн үтсен, ә калганына кар яусын.

Көзен Хәнифне идарәгә хисапчы ярдәмчесе итеп тәгаенләделәр, ә Зөлкарнәйне сельпога урнаштырдылар. Үзсүзле, түземсез Зөлкарнәйнең сәүдә эшенә әз генә дә һәвәслеге юк иде. Ай да үтми, «күңелем яланга тарта, бүлмәдә чыдап утыралмыйм», дип сельподан чыгып китә. Соң ул киткәч, нишләп Хәниф түзеп торалсын инде. Фельдшердән «Бүлмә һавасы организмга ярамый» дигән справка ала да, дусына кушыла. Ата-аналары үгетли, председатель җайлап та, ачуланып та әйтеп карый, ләкин акыллы киңәшләр бу җилкуарларның бер колагыннан керә, икенчесеннән чыга.

Аларның бу гамьсез, күбәләк тормышы озакка барыр идеме, юкмы,— билгесез. Әмма көннәрнең берсендә...

Урак өстенең иң кызган чагы иде. Кояш бөтен эсселеген сыгып чыгарырга тырышып кыздыра. Яфрак селкенерлек тә җил юк. Әлсерәгән чикерткәләр дә тынганнар. Күк чиксез ерак һәм туры карарлык түгел — аксыл

зәңгәр. Челлә... Дуслар үзләре ясаган япма астында камылда әлсерәп яталар, ә атлар пошкыра-пошкыра яңа чыгып килгән нәфис курпыны йолкалар. Хәниф үзенең яраткан җырын ашыкмый гына, кычкырмый гына җырлый.

Яшь гомерләр килми ике,
Белегез кадерләрен...

Ә Зөлкарнәй учына яшереп кенә тәмәке тарта һәм урылган басуга карап сүзсез ята. Беркайчан да боега белмәүче, лыгырдаудан туктамаучы Зөлкарнәйнең моңаеп, сүзсез ятуы гаҗәп, хәтта килешми.

— Зөлкарнәй...

— Я?

— Син нигә күңелсез? Чирләмисеңдер бит? Юкка шундый эсседә кепкасыз фарсит итәсең.

— Эш кепкада түгел.

— Ә нидә соң?

— Гашыйк булдым мин.

— Гашыйк булдың?— Хәниф басу яңгыратып көлде.— Юләр! Мәхәббәт өчен боега торган егетмени син.

Зөлкарнәйнең хәтере калды.

— Син үзең юләр. Нигә, минем йөрәгем юкмыни?

— Барлыкка бар да, тик ул әтәч кычкырган саен үзгәреп тора. Исәпләле, быел ничә мәртәбә гашыйк булдың? Тимерче Фәхри кызы Сания артыннан хыялланып йөрдеңме? Бер. Әхнәфнең сеңелесе Фәһимә өчен җан аттыңмы? Ике. Сатучы Кәтибә белән хыял-

ландыңмы? Өч. Сыер савучы Гөлбану? Ә... ә монысы кем инде?

— Әйтмим.

— А-а, миннән дә яшерәсеңме? Алайса кузгалдык, атлар ашап туйды.

— Мин ул кызга, миңа кияүгә чык, дидем.

— Кияүгә? Сантый, әллә өйләнергә уйлыйсыңмы? Синең бит...— Хәниф, сикереп торып япманы аударды, кабат утырды да, тезләрен кочаклап, селкенә-селкенә көлде.— Соң синең абыең да өйләнмәгән бит әле. Сантый!

Зөлкарнәй бернәрсә булмаган шикелле ерак офыкка карап торды. Хәниф аның җилкәсеннән җилтерәтте.

— Юк, син чынлап та өйләнмәкче буласыңмы? Әллә...

— Юк, шаярып,— дип мыгырдады Зөлкарнәй.

— Чынлап булгач, нигә шулай боексың? Кияү булачак кешенең башы күккә тиярга тиеш. Әллә... капка ача да капка артына качамы? Х-ха-ха-а...

— Ю-ук... Соң кызлар барысы да азрак кына булса да кылана, назлана бит инде ул. Күр дә тор, мин аны кулымнан ычкындырачак түгелмен. Их, малай, кыз нинди бит. Дөньяда башка андый юктыр.

Хәниф авыз чите белән елмайды.

— Һә-әй, гашыйк булганда һәркем шулай ди. Ә ныклабрак карасаң, бер җилкуар булып чыга. Ярый, кузгалдык.

Гадәттә мәхәббәт кешене көчле, дәртле итә, ә безнең башкисәр Зөлкарнәй көннән-

көн күңелсезрәк күренде, юк-барга да кызып китте. Унике яшьтән мүк тарта башлаган «ата тәмәжник» Зөлкарнәй кинәт тәмәкенең зарары турында озын-озын итеп акыл сата башлады. Ыспай киенмисең, дип Хәнифкә бәйләнде, чәчеңне озын йөртәсең, дип сукранды. Сизелеп тора, Зөлкарнәйнең эче яна, башында нидер болгана, ләкин авыз ачып бер сүз әйтми. Юк-барга чабаланмаучы, пошмас җан Хәнифнең дә түземлеге бетте.

— Син нәрсә, телсез кешесымак, авыз ачып сүз әйтмисең? Дус булсаң дус бул, булмасаң әнә бара юлың. Берәүләр гашыйк булган имеш!

Зөлкарнәйнең җавабы аны таң калдырды.

— Кыз түгел ул, шайтан. Интектереп бетерде. Хәзер нишләргә дә белмим. Чакырган саен, ялындырмый, соңламый килә. Килгән саен көлә, шаяра, ә хушлашканда култыкка я берәр роман, я дәреслек кыстырып китә.

Гашыйк булган кешенең газаплануы чит кешегә көлке дә, кызык та тоела. Хәниф тә җай килгәндә чеметеп алырга булды.

— Ә син нишлисең?

— Нәрсә — мин? Мин дә көләм, шаярам.

— Бик әйбәт. Тормышыгыз уйнап-көлеп кенә үтәр.

— Тормыш! Андый көлү-шаярудан елыйсы килә.

— Карале, Зөлкарнәй, ташла син аны.

— Ташлап булса...

— Алайса, тәрбияләргә тырышып кара. Үзең бит тартуыңны ташладың. Такмакларны оныттың. Бәлки озакламый ничек ашарга да онытырсың?

— Ничава. Кияүгә чыккач басылыр әле. Мин аны,— Зөлкарнәй мәгънәле итеп бармакларын кысты.— Учта гына тотачакмын.

— Ай-һай, андыйлар ул, малай, үзләре ирләрен уч төбендә тоталар.

— Тоталмас. Безнең нәсел юаш түгел...

Менә соңгы камыл да киселде. Ялангачланып калган басу күңелгә сагыш сала. Дуслар, әнә шул каенлык янындагы тирән, дымлы чокырга төшеп, тәнне бөрештерерлек боздай чишмә суы белән билгә чаклы юындылар, әрекмән яфрагыннан чүмеч ясап су эчтеләр. Шифалы су аларның ару-талуын кул белән сыйпагандай итте. Кызлар уч төбе чаклы көзгегә карап, юеш чәчләрен тырышып тарадылар да авылга кайтып киттеләр.

— Беләсеңме,— диде Зөлкарнәй, ургыч машинасына утырып кайтканда,— теге кыз миңа чыгарга теләми.

Алда утырып баручы Хәниф атларны туктатты. Атлар, нигә урынлы-урынсыз җирдә туктаттылар икән дигәнсымак, акыллы, сабыр күзләре белән артка борылып карадылар.

— Нәрсә-ә? Авылда сиңа кияүгә чыгарга теләмәгән кыз бармыни? Гәүдәң генә ни тора! Ә җилкәң?..

— Бар икән шул. «Мин,— ди,— перс-пек-ти-ва-сыз кешегә кияүгә чыгарга юләр түгел». Аның уенча, мин ышанычсыз, юньсез кеше булып чыгам. «Мин һөнәрсез кешеләрне яратмыйм»,— ди.

— Әллә-лә-лә-ә... Соң үзе кем ул? Мин аны беләмме?

— Беләсең?

— Кем?

— Хәниф, зинһар, төпченмә.
— Синең эшең. Сер саклау үзе бер матурлык, диләр. Я, хәзер нишләмәкче буласың инде?
— Укырга китәм.
— Укырга? Һә-әй. Хәзер бездән башка да укыган кешеләр эт тезеннән. На-а, малкай.— Ул дилбегә белән ипләп кенә атларның кабыргаларына суктырып алды.— Менә мин бүген бер кыз белән күрешәм. Ул, ичмасам, кыз дисәң дә кыз. Синең назлыбикәң түгел. Акыллы кыз, төпле кыз. Андый ахмак сүзне беркайчан да әйтмәячәк.
— Кем ул?
— Сорама. Туйда күрерсең.
Кичен елга буенда таллыкта Зөлкарнәй, пыш-пыш сөйләнеп, сөйгәнен атлыгып көтте. Күптән караңгы төште, күптән авыл тынды, ә кыз һаман юк та юк. Гаҗәп, аның беркайчан да болай соңлаганы юк иде.
Шулай уйлап торганда гына яр буендагы куаклыклар арасыннан килүче кешенең сак адымнары ишетелде. Егетнең йөрәге «келт» итеп китте, башы җиңелчә әйләнде. «Бу юлы да карышып торыр микән?— дип борчылды Зөлкарнәй.— Аңа охшар өчен, ни кушса, шуны эшлим бит инде. Тәмәкене ташладым. Оятсыз такмаклар чыгармыйм, и сүгенмим, теш арасыннан төкермим. Буш минут булдисә, китап укыйм. Хәтта шахмат уйнарга өйрәндем. Аңа тагын нәрсә кирәк икән инде? Бәла. Үз башыма гашыйк булганмын икән. Ә мәхәббәтне шатлык, диләр». Көткән кеше урынына куаклыклар арасыннан Хәниф ки-

леп чыкты. Аның күзләре яна, авызы нәкъ колаклары янында.

— Сәлам! Тартабызмы?

— Юк, син мине аздырма, Хәниф.

— Я, Зөлкарнәй дус, соңгы атакаң барып чыктымы?

— Чыкты. Ә синең эшең пештеме?

— Майланды да, җайланды да, Зөлкарнәй дус. Укырга китәм! Механизаторлар мәктәбенә. Егет кешегә һөнәрсез ярамый.

— Укырга?— Зөлкарнәйнең күзләре шундый зурайды, әйтерсең, хәзер алар менә-менә атылып чыгалар.— Соң сине авылдан алла да аерып алалмый бит.

— Алладан да көчлерәк кешеләр бар икән, Зөлкарнәй дус.

— Кем? Колхоз председателеме?

— Юк. Колхоз зоотехнигы. Вәт кыз! Кая синең җилкуарыңа... Ә күзләре? Диңгез!— Хәниф ләззәтләнеп күзләрен йомып алды.

— Алдашасың, Хәниф!— дип ачуланып кычкырды Зөлкарнәй.

— Син нәрсә бугазыңны ертасың? Ни акыллы, ни тиле бер кызга күзең төшкән дә хәзер бар ачуыңны миннән алмакчы буласың. И-их, минем Гәүһәрнең күзләре, малай, океан...

Зөлкарнәй аның каршысына килеп басты. Хәнифнең тәмәкесен тартып алып озак-озак суырды да бик әкрен, ишетелер-ишетелмәслек итеп әйтте:

— Бел, ул «ни акыллы, ни тиле» кызның исеме дә — Гәүһәр.

— Ничек Гәүһәр? Безнең авылда башка

Гәүһәр юк түгелме соң? Юк. Район үзәгеннәнмени?

Зөлкарнәй йөзен җыерып, әче елмайды:

— Юк, монда туган. Өстәвенә зоотехник.

Хәниф, инде җитдиләнә төшеп, бармак янады:

— Син шаяртма, Зөлкарнәй...

— Син үзең шаяртма, Хәниф. Син минем Гәүһәрне яратуымны сизеп калгансың да ирештермәкче буласың. Килешми!

Хәнифнең күзләрендәге дәртле очкыннарны уйчанлык нурлары каплады.

— Тукта, тукта. Син теге вакытта Гәүһәр турында сөйләдеңмени, Зөлкарнәй?

— Юк, әбие турында.

— Ышанмыйм. Валлаһи. Ул бит шундый акыллы.

— Акыллы...— Зөлкарнәй онытылган гадәте буенча теш арасыннан төкерде.— Моның өчен әллә ни акыл кирәкми. Киресенчә, җиңел акыллылык бәласе. Син дөрес әйткәнсең икән, җилкуар ул.

Хәниф Гәүһәргә сүз тидертергә теләмәде:

— Аның турында алама сөйләргә хакың юк! Ишеттеңме?

Дусының боерык рәвешендәге тавышы Зөлкарнәйне тәмам чыгырыннан чыгарды.

— Син миңа җикеренгәнче «сөеклеңә» барып әйт, кеше йөрәге белән, туплы уйнаган кебек, уйнамасын.

Хәниф, әллә горурланып, әллә ачынып, әйтте:

— И-их, минем кулымнан килсәе, Зөлкарнәй. Үз йөрәгемә баш булалмыйм әле.

Әйтеләсе әйтелеп бетте. Алар тын гына, үз уйларына чумып, өйләренә юнәлделәр. Август төне дә тын иде. Карачкыл зәңгәр күк тә тын иде. Тик зур, юеш йолдызлар гына нәрсәгәдер сөенеп җемелдәшәләр, атылалар.

Чокыр янында Зөлкарнәй туктады. Чокыр төбеннән ялгыз чишмәнең чылтыраганы ачык ишетелә. Зөлкарнәй Хәнифнең таза, көчле беләгеннән тотты.

— Хәниф, әйдә без аны акылга утыртабыз.

— Ничек?

— Беренчедән, бу мәсьәләне комсомол җыелышына куябыз...

— Нәрсә, син әллә тилерә башладыңмы?

— Алайса, әйдә болай эшлибез: икебез дә хәрби училищега укырга китәбез, укуны бетергәч, парадный формада авылга кайтып төшәбез, кызларның күзләре тоздай булачак.

— Юк, теләмим,— диде дә Хәниф кузгалып китте.

Зөлкарнәй аның артыннан куып җитте.

— Туктале. Ә син нәрсә телисең? Нәрсә? Моннан соң да икебезнең башны әйләндереп йөрсенме, ә? Матурмын дигәч тә, техникум бетердем дигәч тә, аңа диплом белән бергә чикләнмәгән хокук та бирелгәнмени?

— Зөлкарнәй, әллә өчәүләп сөйләшәбезме? Кайсыбызны ныграк ярата икән, синеме, минеме?

— Әгәр сине дә, мине дә булмаса?

— Алай булырга тиеш түгел, Зөлкарнәй.

— Хәзер мин, Хәниф, аның бер сүзенә дә

ышанмыйм. Бүгеннән алып мин аны, ул мине белми. Сиңа да шуны боерам.

— Син җиңел уйлыйсың, Зөлкарнәй. Мин бит аны яратам.

— Ә мин шаярып йөримме? Юри генә төннәрне йокысыз үткәрәмме? Әмма егет егет булырга тиеш! Аңлыйсыңмы?

Дуслар разъездга килеп чыктылар. Алар яныннан шаулап озын буш товарный поезд үтеп китте.

— Разъездларны нигә эшлиләр? Син беләсеңме?— дип сорады Зөлкарнәй, Хәнифкә карамый.— Каршы килгән поездлар маңгайлары белән бәрелешми юл биреп үтәр өчен.

— Ярый, алайса без дә үз юлларыбызга китик,— диде Хәниф, дусының сүзен хуплап.

Хәниф сүзендә тора алмады, авылда калды, әмма егет сүзен җиргә ташламады һәм Гәүһәр белән башка очрашмады.

Төннәрен, авыл йокыга талгач, Гәүһәрләр өе яныннан үтеп киткәләде, туктап, таныш тәрәзәләргә, йөрәк төбендә яшеренгән җәрәхәтне кузгатып, озак кына карап торды. Кайчак сәгатьләр буе. Гәүһәрнең көлгән тавышы ишетелер кебек тоелды. Ә беләсезме ул ничек көлә? Башын кырын сала да дөньясын онытып, шундый ихлас көлә, юк, көлми, сайрый, нәкъ бая без ишеткән сандугачлар инде. Юкка гына аны бөтен авыл халкы «Сандугач» дип йөртмәде шул...

Җәйләрен Хәниф яланда эшләде. Кышларын өченче этәчкә чаклы дәреслекләргә күмелеп утырды. Ул бер елда унынчыны бетереп, читтән торып, авыл хуҗалыгы институтында укый башлады. Институтны тәмам-

лагач, үзен районга алмакчы булган иделәр, Хәниф туган авылына һәм... Гәүһәренә хыянәт итмәде.

Минем юлдашым тынды. Бераздан, үткәннәргә үрелеп карагандай, өстәп куйды.

— Тора-бара Хәниф Гәүһәр белән янә очраша башлый. Күп, бик күп мәртәбә алар шушы разъезд янына килеп, алар янында туктамый, яшендәй үтеп китүче ерак юл поездларын озатып калалар. Әнә шул каенлык артындагы чокыр буенда беренче яз чәчәкләрен — умырзаяларны өзәләр; салам аркылы җанга шифа бирүче каен суын эчәләр, дуслык, мәхәббәт турында бәхәсләшәләр, алдагы кичкә һәм... йөз елга планнар төзиләр. Каеннар ул чакта әле тәртә юанлыгы гына, ап-ак тәнле иделәр, хәзерге кара ямаулары да юк иде. Агачлар да, кешеләр шикелле, картаялар. Тик сандугачларның җыры да, хатирәләр генә элеккечә яшьләр, тынгысызлар.

Поезд станциягә якыная. Паровоз, каршы алырга килүчеләрне сөендерергә теләгәндәй, күңелле итеп кычкырып җибәрде!

Мин Фәттахов хикәясен сөйләп бетерә алмас дип курыктым һәм түземсезләнеп сорадым.

— Я, я, ничек булып бетте?.. Сезнең назлы Гәүһәрегез кемгә чыкты? Минемчә, ул Хәнифкә булгандыр.

Юлдашым серле елмайды.

— Нигә шулай уйлыйсыз?

— Чөнки... Хәниф Гәүһәргә бирелгәнрәк һәм үз сүзендә торучанрак кеше булып чык-

ты. Ә хатын-кызлар «сүзен сүз итүче» ирләрне яраталар.

— Һәрвакытта да түгел...

— Димәк, Зөлкарнәйгә чыкты?

— Юк. Кемне чын күңелдән яраткан, шуңа — морякка.

— Ә-ә... Моряк. Барлык хатын-кызларның һушын алучы моряклар. Кем ул? Офицермы, адмиралмы?

— Балта остасы. Флоттан кайткач, төзелеш бригадасының башлыгы итеп куйдылар. Йортлар төзи. Якты, нык итеп. Ә Хәниф хәзер «Якты юл»да председатель. Гәүһәр аның уң кулы — терлекчелек буенча. Гәүһәрнең туенда Хәнифтән дә шәбрәк биегән, җырлаган кеше булмаган.

— Ә дуслыклары ничек? Хәнифкә Гәүһәр белән эшләве җиңел түгелдер бит.

— Юк. Хәер, кем белә. Әмма дуслыклары, халык әйткәнчә, кара гүргә кергәнче.

Мин, вагонны яңгыратып, бот чабып көлдем.

— Менә ичмасам кыз! Егетләрнең икесен дә кеше иткән. Күрергә иде үзен...

Фәттахов тагын мәгънәле итеп елмайды.

— Бәлки күрерсез дә.

Миңа: «Сез кем: морякмы, Зөлкарнәйме, Хәнифме, әллә дүртенче берәүме?» дип соравы уңайсыз булса да, тәки тәвәккәлләдем.

— Иптәш Фәттахов, ике тәүлек бергә кайтабыз, ә исемегезне һаман белмим.

— Минем исемем — Зөлкарнәй. Танкист. Полковник.

Ул ашыкты. Кырыкмаса кырык төрле әйберләрен җыя-җыя:

— Кунакка кайтам. Шуңа күрә кытымытыны күп алырга туры килде. Дус-иш яргы авыл,— дип сөйләнде.

— Гәүһәрләргәме?

— Аларга да. Гомумән, Сандугачлар разъездына, яшьлеккә. Чокырга төшеп, эрекмән яфрагы белән чишмә суы эчәргә, сандугачлар моңын тыңларга, ерак юлга йөрүче поездларны озатып калырга.

— Ә нигә парадный формада түгел?— дип сорадым мин елмаеп.

— Заманы ул түгел. Гомумән, мин туган авылыма беркайчан да хәрби формада кайтмыйм. Башкалардан аерылып торасым килми. Аннары, болай кайту яшьлеккә кайту кебегрәк тә була...

Һәм менә станция. Перронда Фәттаховны байтак кеше каршылады. Кинәт мин сандугач сайравына охшаган ачык, дәртле, саф көлү ишеттем. Бәлки миңа шулай тоелгандыр...

Минем элекке юлдашым, күрәсең, мине хәтерләп, аны каршылаучы хатыннарның берсенә күрсәтеп, нидер кычкырды. Мин аның ни әйткәнен ишетмәдем һәм ул күрсәткән хатынны күрә алмадым. Хәер, күрмәвем дә хәерле. Эш бит Гәүһәрне юл уңаенда күреп калуда түгел...

Мин башы-азагы булмаган юллар — сукмаклар, көтелмәгән очрашулар һәм аерылышуларның мәгънәсе турында уйладым. Мин сагышлы хушлашулар һәм бәхетле күрешүләр хакында уйладым.

Мин, яшьлеге һәм гүзәллеге сандугач җырларында, каен урманында, салкын чишмә тавышларында, карны тишеп чыгучы беренче яз чәчәкләре — умырзаяларда, каен суларында һәм безгә бәхет коючы, шул бәхетне саклаучы кешеләрнең күңелендә мәңге картаймый яшәүче кыз турында уйладым.

Һәм, тәгәрмәчләрнең әдәпле генә шаулавы аша кабат-кабат сандугачлар тавышын ишеттем.

Ахры, гомерем буе мин аны ишетермен...

ТОРНАЛАР БИЕК ОЧА

«Торрыйк-торрыйк...»

Ерактан, аксыл-зәңгәр сентябрь күгеннән моңсу аваз ишетелә. Туып-үсеп кош булган җирләре белән хушлашып, торналар җылы якка китә. «Торрыйк-торрыйк...» Бу —«торыек, торыек әле» дигән кебек яңгырый. Ләкин алда баручы тәҗрибәле, ихтыярлы вожатый яшь кошларның сагышлы тавышына колак салмый. Ул, карлыгач койрыгы кебек, ике чатлы торналар төркемен чиксез-кырыйсыз күк диңгезеннән алга, берүзенә генә билгеле урынга алып бара.

«Торрыйк-торрыйк...»

— Хәерле юл!— дип ачык тәрәзәдән кул болгый озын буйлы, озынча битле самшит таяклы кеше.

— Язын шул торналар Тәзкирәмә канат алып килсә ярар иде,— дип пышылдый моңсу күзле хатын.

Озынча йөзле кеше диванга утыргач, күп еллар буе спирт белән юганлыктан шомарып беткән кулларын «Кавказны онытма» дип язылган самшит таякка куйды, киң соры кашларын җимереп, мамык ястыкта яткан чырайсыз кызга карап алды. Моңсу күзле хатын, бу кешедән күзен алмый, тилмереп нидер көтте.

Җиң кашлы кеше яңа укырга өйрәнгән бала кебек, ашыкмый, тотлыга-тотлыга сөйли башлады:

— Мең тугыз йөз... җиденче елның... әйе, әйе, җиденче елның көзендә (ул чакта әле миңа унөч яшь тулмаган иде), бер торна баласы безнең авыл янындагы «Камышлы күл» буенда торып калган. Канатын сындырган, мескенем. Абыем белән без аны өйгә алып кайттык. Үзебезчә дәваладык. Борчак ашаттык. Ул тора-бара безгә ияләште: артыбыздан иярен йөрде, әйткәнне аңлый башлады. Без аңа озын муенлы, озын аяклы күпер буе Сәмигулла абыйның исемен куштык.

«Сәмигулла!» дисәң, мескенкәй, «торрыйк!» дип кычкыра да янына килә торган иде. Бервакыт торнабыз исеме белән әйтмәсәң дә кычкыра башлады. Без, сарайда ятып ялыккандыр, дип, аны ишек алдына чыгардык. «Сәмигулла»быз һаман тынмый, биргәнне ашамый, озын нечкә аяклары белән, кәефе бозылган солдат кебек, арлы-бирле йөри.

«Мескен кошның очасы килә,— диде абыем, торнаны күзәтеп торганнан соң.— Кайгырма, «Сәмигулла», бездә генә кышларсың. Без сиңа җылы оя ясарбыз, ә язын «Камышлы күл»гә илтеп куярбыз. Я, килештекме?»

Торна, әйтерсең, шушы сүзләрне генә көткән... Абыема муенын сузып карады да «торрыйк» дип кычкырды һәм күккә күтәрелде. Без, әллә куркуыбыздан, әллә шатланып, «Сәмигулла! Сәмигулла!!» дип аның артыннан йөгердек.

— Кая ашкына ул?.. Хәзер егылып төшә инде... Төшә... Төшә!— Абыем үзе егылып төшкәндәгесыман куркып кычкырды.

— Абый, абый!— дип акырдым мин ярсып.— Торналар! Җылы якка китәләр...— Минем күзләрем томаланды, тамагыма таш утырды.

Абыем минем киндер күлмәгемнән эләктереп алды:

— Их, безнең «Сәмигулла» шуларны куып җитсә...

— Ә аны ияртәләрме соң, абый?— дип шикләндем мин.

— Куып кына җитсен әле. Әкрен оча башлады. Арыды, бахырың. Биек очалар шул. Алар бит биек очарга яраталар. Биек күкне...

— Хәзер егылып төшә инде... Төшә, төшә!

— Нигә соң аны күтәп тормыйлар икән?— Абыем йодрыгы белән капка баганасына сукты.

— Күрмиләрдер...

— Күрүен күрәләр.

— Әһә, кызуланды... Ишетәсеңме, кычкыра, хәбәр бирә...

— Җитә, җитә, җитте! Иярде! Иярттеләр! Ну батыр икән безнең «Сәмигулла».— Без сөенүебездән бер-беребезне куышып шаяра башладык.

Шул вакыт күктән «торрыйк!» дигән музыкаль тавыш ишетелде. Бу, күрәсең, «Сәмигулла»ның безнең белән хушлашуы булгандыр. Без дә киез эшләпәләрне болгап, «Хуш, исән-сау әйләнеп кайт, Сәмигулла!»— дип аңа хәерле юл теләдек.

Самшит таяклы озын кеше торды.

Күзләрен йомып яткан кыз йомшак күкрәк тавышы белән сорады:

— Ул бит барыбер Африка ярларына барып җитә алмагандыр.

— Барып та җитте, әйләнеп тә килде. Икенче елны яз көне үз күзем белән Камышлы күл буенда күрдем.

— Аның канаты гына сынган шул, профессор, ә минем йөрәгем...— дип пышылдады ак чырайлы кыз.

Профессор Сорур апага мәгънәле итеп карады.

— Мин сиңа, Тәзкирә, дөньядагы иң көчле даруны калдырам — медицинаның соңгы сүзе. Ул үлекләрне дә терелтә. Син дә терелерсең. Хәер, син бит шау таза дип әйтерлек, Тәзкирә. Ә хәзергә хуш. Боекма. Ишетәсеңме? Башыңны имә!

Профессор артыннан Сорур апа да чыкты.

— Бөтен ышанычым сездә, Абдулла абый,— Сорур апа күз төбендәге яшьләрен бармак очы белән сөртте.

— Юк, бөтен ышаныч кызыгызның үзендә, Сорур. Чирне врач дәвалый, ә авыру бетерә. Бигрәк тә нервыларга һәм... йөрәккә бәйле булса.

— Ә аның йөрәгенә ни булган, Абдулла абый?— дип куркып сорады Сорур апа һәм үзе дә сизмәстән йөрәген тотты.

— Коточкыч берние дә юк. Йөрәгендә азрак шау бар. Көчле кайгы яки чир калдыгыдыр. Борчылмагыз, андый йөрәк белән йөз ел җиңел яшәп була. Әгәр,— профессор сам-

шит таягы белән идәнгә сугып алды.— Әгәр дә аның яшәргә дәрте, ихтыяры булса... Ә хәзергә ул үзенең чире белән бик йомшак көрәшә. Кабатлыйм,— самшит таяк янә бер тукылдап алды.— Кабатлыйм, аның өчен иң шифалы дару — яшәү өчен ихтыяр. Көрәш! Ә көрәш бетсә — яшәү дә бетә. Тәзкирә үзенең апатиясен җиңеп чыгарга тиеш. Апатия, күңел төшенкелек — күп чирләрнең юлдашы, ярдәмчесе ул. Аны, ничек кенә булмасын, дәртләндерергә, күңелен күтәрергә кирәк. Радиолагыз бармы? Әһә, бу якта икән. Хәзер үк Тәзкирә янына кертегез. Күңелле пластинкаларыгыз, шаян җырларыгыз бармы? Булмаса, табыгыз. Бездән алып килегез.

— Ләкин...— Сорур апа кыенсынып кына каршы төште.— Врачлар аңа, дулкынланырга һич ярамый, диделәр.

Абдулла абыйның киң сары кашлары, соры күзләре өстенә егылып төшеп, ул күзләрне карачкыл соры төскә керттеләр.

— Абсурд. Буш сүз. Анда инфарк та, порок та түгел. Һәм,— самшит таяк тагы ачуланып шакылдап алды,— һәм, кызыңны тизрәк терелтәсең килсә, төрле врачлар чакырып мәшәкатьләнмә. Бу — бер. Икенче нәрсә, Тәзкирә янына дуслары-иптәшләре киләме?

— Йөр... йөргәләштерәләр.

— Ни өчен йөргәләштерәләр, ә йөриләр түгел?

— Элек күбрәк тә, ешрак та килә торган иделәр, хәзер мин үзем аларны кертмим. Врачлар бит...

— Тагы врачлар... минем ачулануым бар,

Сорур ханым. Бер генә минутка да, ишетәсеңме, бер генә минутка да ул үзенең күңелсез уйлары белән ялгыз калырга тиеш түгел. Ә хәзер аның уйлары гына түгел, төшләре дә буталчык. Утыр әле,— һәм профессор үзе дә утырды.— Көнчыгышның борынгы врачлары болай дигән: табипның кулында өч дәвалау коралы бар: сүз, үлән һәм пычак. Ә синең кызыңа беренчесе кирәк. Сүз, җылы, шифалы сүз.

«Сүз... шифалы сүз». Сорур апа дөньяда байтак кына яшәсә дә, андый сүз барлыгын белми иде әле. Ул шифалы сулар, үләннәр, мәтеләр турында белә, ә менә шифалы сүз хакында... Юк, аның моңарчы ишеткәне булмады. Әллә профессор шаярта микән? Күңелне тынычландырыр өчен... Хәер, халык җылы сүз — җан азыгы, ди бит. Шулай булгач... Әйтерсең, Сорур апаның уйлары күзгә күренмәгән җепләр буйлап профессорга да барып җитте.

— Әйе, Сорур ханым, сүз. Сүз! Врач кеше тәненең инженеры гына түгел, ә язучылар кебек, кеше рухының да инженеры булырга тиеш. Карап торуга юк кына исәпләнгән чир дә югары нерв системасына, кеше миенең кабыгына бәйләнгән. Бер үк яшьтәге, бер үк конструкцияле, ләкин төрле холыклы ике кеше бер үк чирне ике төрле үткәрә. Әйе, әйе. Ә син кызыңны кирәгеннән артыграк иркәләгәнсең. Беләм, ул синең бердәнбереең, ләкин... синең мәрхүм ирең дә ата-аналарының бердәнбер баласы иде бит. Егерме беренче елны ун баладан берүзе торып калды. Ә нинди кеше иде! Корыч ихты-

ярлы, корыч организмлы. Ярата идем мин аны...

Сорур апаның күзләренә чакырылмагач кунаклар — яшьләр атылып чыкты.

— Чамадан тыш ярсу иде шул. Давылсыман. Соң бит аңа сугышның азагына чаклы бронь тәкъдим иткән иделәр, тыңламады. Китте. Китте дә кайтмады.

— Давыл... Юк, ул яшен кебек иде. Аның гомере, яшен гомередәй, кыска һәм... күзең чагылырлык якты булды.— Профессор капыл ипләп кенә җырлап җибәрде:

Смело, товарищи, в ногу,
Духом окрепнем в бою...

Җырның калган яртысын ул авыз эченнән генә тәмамлады.

— Иреңнең яраткан җыры иде. Яхшы җырлый иде. Ихлас...

Профессор сәгатенә карады һәм хушлашып чыгып китте. Яшенле яңгырдан соң һава алышынган шикелле, бүлмә һәм күңел җиңеләеп китте. И-их, Сорур, Сорурхан... Тартынмыйча, оялмыйча, башта ук сиңа иреңнең балалык дусы янына барырга кирәк иде. Ә син каушап калдың. Башыңны югалттың. Хәер, аның урынында башкалар да каушар иде. Тәзкирә бит аның бердәнбер өмете, соңгы ышанычы, таң йолдызы.

Атасы фронтка киткәндә ул бөтенләй сабый гына булып калган иде. Аталары артыннан берәм-берәм агалары да китте. Җиңел булмады аларга. Сорур апа хәрби заводта еш кына икешәр смена эшләде, ә кечкенә Тәзкирә өйдә ялгыз калды. Күрше кар-

чыгы кереп кенә аны ашатып-эчертеп чыга торган иде. Калган вакытын Тәзкирә таза, матур, шат булып үсте. Тик аның артык нәзек күңелле булуы гына ананы азрак борчыды. «Иркәбикә»се салган ашны ашамаса да, ул сәгатьләр буе борчылып йөрде. Мәктәпкә ул алты яшеннән китте һәм беренчедән алып гел «бишле»гә укыды. Бигрәк тә ул математиканы «су кебек эчте». Дус-ишләре, укытучылары: «Безнең Тәзкирә мөгаен туган көнне үк хисап чыгара башлагандыр» дип, аның сирәк очрый торган зиһененә сокланып туймый торган иделәр. Унынчыны алтын медаль белән бетергәч, Тәзкирә капыл икенче төрле уйлады — гаризасын мединститутка илтеп бирде. Башта аның бу кыланышын аңламадылар да, ошатып та бетермәделәр. Көннәрнең берендә ул әнисен кочаклады да серен чиште:

— Әни, безнең иң әшәке дошманнарыбыз кем, беләсеңме?

— Кем дип ни... Сугыш ачарга йөрүче мәлгуньнәр инде.

— Алардан башка күзгә күренмәгән дошманнарыбыз күп әле.

— Кемнәр ул тагы?

— Чир. Күпме кешеләр чәчәк аткан вакытта гүргә керә... Барысына да чир гаепле, әни. Шуңа күрә кешенең гомере бигрәк кыска. Каргалар да өчәр йөз ел яши, ә ни өчен кеше өч йөз ел яшәмәскә тиеш? Син көлмә, әнием. Килер бер заман, кешеләр теләсә нинди авыруны җиңә белерләр. Юк, алай гына да булмас, авыру якынлаша башлагач та, аны куып җибәрерләр. Кешеләр

икешәр-өчәр йөз ел яшәрләр, йөз яшьлекләр китапны күзлексез укырлар, балалар белән волейбол уйнарлар... Син көлмә, әнием, бу әле хыял гына,— әмма тормышка ашарлык хыял. Соң хәзер дә икешәр йөз ел яшәгән кешеләр бар бит. Көньяк Америкада бер хатын 214 ел яшәгән. Әни, ышан, без үлемне барыбер җиңәчәкбез. Җиңәчәкбез дигәч җиңәчәкбез. Кеше атомны авызлыклады, аңа боера ала. Һәм без үлемгә дә: «Бар, кит безнең юлдан», дип боерачакбыз.

Һәм... аяз көнне яшен суккансыман, бәхетсезлек килде!

Их, аналар, ниләр генә күрми аналар!.. Ниләр генә кичерми аналар... Аның өч улы, ире сугыштан әйләнеп кайтмады. Өч ай эчендә ул военкоматтан дүрт каһәрле «хәбәр» алды. Кайгы шулчаклы зур булды — хатыннар түгел, ирләр бөгелерлек иде. Ә аналар түзә, иң авыр кайгыны да җиңә, коточкыч авырлыкларны да күтәрә белә.

Һәм менә тагы аның чал башына кара кайгы төште.

Әгәр Тәзкирә терелә алмаса, Сорур апа нишләр... Юк, ул бу кайгыны күтәрә алмас. Их, бала, бала... Мөмкин булса, үз гомерен биреп, кызын терелтер иде ана...

Башта Тәзкирә чирен аягүрә генә үткәреп җибәрмәкче булды, анасына да сиздермәде, дару да эчмәде; элеккечә көлде, җырлады, шаярды. Ләкин үзеңне алдасаң да, аналарны алдап булмый ул. Ана күңеле — иң сизгер барометр.

Сорур апа кызының күзендә сәерлек, сулышында үзгәреш сизде.

— Кызым, әллә чирләргә уйлыйсыңмы?— диде ул янып.— Шәһәрдә теге яңа... вируслы грипп башланган, диләр. Аллам сакласын, шуны эләктерә күрмә тагы. Сарымсак аша.

— Сарымсак... сасып йөрергәме? Миңа чир эләкми ул, әни, иммунитет.

Ләкин чир Тәзкирәдән рөхсәт сорап тормады. Дөресрәге, эләккән иде инде. Көннәрнең берсендә аның борыныннан гөжләп кан акты һәм кичкә таба температурасы кырыкны узып китте. Бер атна ул үзен-үзе белми ятты. Көн саен аның дуслары, институтка барганда һәм кайтканда тәрәзә төбенә килеп, хәлен белешеп, юатып киттеләр. Инде Тәзкирәнең хәле арулана башлагач, Тәзкирә янына шаян һәм күп сөйләнүче Фәрит килде.

— Син курыкма, Тәзкирә. Мин...— ул бугазына чиртте,— сарымсак изеп, йөз грамм «акбаш» агайны кактым. Ну тәмсез, зато йөз процентлы гарантия. Мин кичә сиңа багышлап шигырь яздым. Укыйммы? Тик көлмә, ярыймы?

Ул һич туктамый сөйләнде дә сөйләнде һәм Тәзкирәнең хәл-әхвәлен дә сорашмый чыгып китте дә бераздан атылып кире керде.

— Гафу ит. Хәлеңне дә сорашмадым. Я, терелəсеңме?

— Аруланам. Тик һаман баш әйләнә, йөрәк дерелди. Нигә Катя күренми? Әллә ул да чирлиме? Нигә дәшмисең? Әллә каты чирлиме?

— Улмы? Ул... юк, ул чирләми. Ул Москвага киткән...

— Москвага? Уку вакытындамы? Алдаша белмисең, Фәрит. Дөресен әйт.

— Син борчылма, Тәзкирә. Ул... вокзалдан җизнәсен озатып кайтканда, автомобиль катастрофасына очраган...

— Исән калдымы?— Тәзкирә сикереп торды. (Катюша, Катенька... Аның иң якын дусы, ахирәте.)— Исәнме, дим? Нигә телеңне йоттың?

— Кичә кич үлде. Һушына да килә алмады.

Һәм Тәзкирә дә һушыннан язды. Фәрит нишләргә дә белмәде. «Ашыгыч ярдәм» чакырырга чыгып йөгерде... Их, Фәрит, Фәрит, булачак врач... Авыру кешегә шундый дәһшәтле хәбәрне сөйләргә ярамаганлыкны белмисеңмени...

Коточкыч хәбәрдән Тәзкирә өзлегеп китте һәм бер ай больницада ятты. Ике атна буе ул ахирәте Катя белән саташты.

Ябыккан, хәлсезләнгән һәм ямьсезләнгән Тәзкирәне Сорур апа моннан унбиш көн элек өенә алып кайтты. Врачлар авыруга саф һава, яхшы ашау һәм тынычлык кирәк, диделәр. Ләкин Тәзкирә аз ашады һәм бик әкрен савыкты. Аның күңеле төшенке, кан тамырлары күгәреп яткан ак куллары көчсез иде.

Летят перелетные птицы,
В осенней дали голубой,
Летят они в жаркие страны,
А я остаюсь с тобой..:

Бу җыр аның башыннан көндез дә, төнлә дә чыкмады. Хәтта беркөнне ул, Катяның кошка әйләнеп, җылы якка очып киткәнен дә күрде. Бу — Катюшаның яраткан җыры иде... Һәркемнең бер өзелеп яраткан җыры

була шул. Мәсәлән, аның атасы «Телеграмм баганасы»н гел җырлый торган иде. Ул яхшы хәтерли. Атасы фронтка киткәндә, вагон баскычыннан да «Телеграмм баганасы»н җырлаган иде.

Телеграмм баганасын
Түбән очка кем куйган,
Сагынасыңмы, дип сорыйлар —
Туган җирдән кем туйган...

Ә аның яраткан җыры бармы?.. Әлбәттә. Берәү генә түгел, күп. Ә иң, иң яратканы? Иң, иң...

Тормыш үзенекен итте — Тәзкирә әкренләп йөри башлады, курка-өркә генә басып, көзге бакчага чыгып утыргалады, тик дуслары гына килмәде, алар совхозга бәрәңге алырга киткән иделәр.

Һәм менә шундый көннәрдә күптәннән бирле күренмәгән участок врачы тыны-көне бетеп килеп керде. Аның кып-кызыл табак бите шабыр тиргә баткан, авызыннан, кулыннан спирт исе аңкып тора. Ул утырмады, баш яулыгы кебек зур кульяулык белән тирен сөртә-сөртә ишекле-түрле йөрде.

— Ай-яй-яй... Ишетмәдем. Белмәдем. Мин бит ай ярым кымыз эчеп авылда яттым. Былтыр да отпускыда булмаган идем. Кешеләр дәвалый-дәвалый, үземне онытып ташлаганмын. Мин өйдә булган булсам, Тәзкирәне мондый хәлгә төшермәс идем. Хәзер аңа карарга куркыныч бит. Ай-яй-яй... Каты чирләдеңме, акыллым? Ай-яй-яй... Пешкән алма кебек кыз мичтә пешерелгән алмага охшап калган бит. Ай-яй-яй. Ничево, ничево.

Без сине менә диган итеп ремонтларбыз.— Ул, сумкасыннан дүрт кырлы ялпак шешә чыгарып, кулына, авызына спирт койды да, стетаскоп алып, Тәзкирә янына килде. Стетаскопның зуррак эшләпәле башына өреп җылыткач, Тәзкирәгә халатын салырга кушты. «Тын ал, тирәнрәк. Тагын да тирәнрәк. Алма, алма. Ал...» һәм ул мәгънәле итеп, «М-м-да» дип куйды. Кыска юан бармагын киң, калын иягенә терәп торганнан соң (әйтерсең, аның кызыл, кыска муены карбыз кебек йомры башын тоталмый) ул янә бер тапкыр «м-м-да» диде дә, Сорур апаны ияртеп, алгы якка чыкты.

— Мин, үзегез беләсез, Сорур ханым, врач,— диде ул, чәнчә бармагын селкеп.— Минем миссия, үзегез беләсез, кешеләр тергезү, но... но, дигәч аңлашыладыр дип уйлыйм. Мин алдашырга яратмыйм. Эш йөрәктә. Ә йөрәгендә чехарда. Ягъни, шау. Ә йөрәкне, үзегез беләсез, дәвалап булмый. Ну, дәвалавын дәвалап була, но... но, дигәч аңларсыз инде. Мин түгел. Сорур ханым, ме-ди-ци-на гаепле. Ә безнең ме-ди-ци-на әле...— Ул чәнчә бармагын күрсәтте.— Сызлавыкны да тиз генә бетерә алмыйбыз. Жәл, жәл, кыз матур, яшь, но... Но, дигәч сезгә аңлашылыр дип уйлыйм. Озак дәваларга туры килер. Ә иң мөһиме, тынычлык, кроватьтан тормасын. Бер кешене кертмәгез. Радиоланы теге якка!

Ә Тәзкирә нәкъ шушы минутта бакчага чыгарга дип урта ишекне ачкан иде. Врачның шәфкатьсез сүзләре аны тетрәтеп җибәрде. Ул, үзе дә сизмәстән, йөрәген тотты.

Пульсен санады... Әйе, аның пульсе тигез түгел иде. Йөрәге я ярсып типте, я арыган кешедәй, туктальп торды. Бәлки йөрәк тигез дә типкәндер, ләкин Тәзкирәнең үзенә шулай тоелды.

Икенче көнне ул тынычлана төште, әмма врачның сүзләре әрсезләнеп күңелгә керде. Уң кулы белән ул әледән-әле сул ягын тотып карады, һәм караган саен йөрәк яңача типкән төсле тоелды. Төн урталарында ул дерт итеп уянып китте һәм, күзен йомарга куркып, пульсен санады.

Аның йөрәгенә шикләнү корты оялады һәм, келәмгә төшкән көясыман, өмет утларын ашарга тотынды. Тәзкирә тамактан язды, якты дөнья караңгы булып күренә башлады.

«Озак дәваларга...» Димәк, аңа әле укырга ярамый. Ул иптәшләреннән артта калачак. Институт бетергәч, Казахстан далаларына врач булып китү турында ул нинди хыялланган иде. Шәһәр кызы булса да, аны дала тартты. Бәлки атасы дала якларында туып-үскәнгә, аны да дала тартадыр.

Шундый авыр көннәрнең берсендә Сорур апа, иренең балалык дусты профессор Абдулла Кәримовичка барып, аһ-зарын сөйләде. Профессор, башта ук киләләр аны, нәрсә тартынып-куркып торырга, дип Сорур апаны шелтәләп алды да Тәзкирә янына китте. Ничек диде әле профессор: «Иатрогенная болезнь»... халыкча әйткәндә, врач күңелгә сеңдергән чир.

«Андый врачларны медицина дөньясыннан арт якларына тибеп куарга кирәк. Юнь-

сез. Ахмак. Акылсыз». Профессор участок врачын бик озак сүкте. Сорур апа профессорның андый каты сүзләргә сәләтле икәнен белми иде. Сүзләр каты булса да, Сорур апа ачуланмады, киресенчә, йомшарды һәм, профессор киткәч, ачык йөз, тыныч күңел белән кызы янына керде.

— Кызым, Абдулла абыең калдырган даруны эчәсеңме?

— Әни, теге торна баласы әйләнеп кайтты дип профессор дөрес әйттеме, әллә?

— Профессор башы белән алдашмас инде, кызым. Алар, торнаның сул аягына кызыл җеп бәйләгәннәр. Яз көне шундый аяклы торнаны күл буенда күргәннәр.

— Ә торна аларны таныганмы?

— Менә анысын сорашмадым, кызым.

— Әни...

— Кызым, хәзер мин сиңа бик матур күлмәклек алып кайтам. Терелгәч тә тектерерсең.

— Ни төслене, әни?

— Җирлеге аксыл яшел, аллы-гөлле күбәләкләр очып йөри... Сиңа шундый килешер...

— Элек булса килешер иде дә... хәзер белмим шул...

— Хәзер дә килешер. Борчылма. Син, элекке шикелле, бик матур. Тфү, тфү, күз тимәсен. Кассадан акча алам да магазинга барам. Ә син, даруыңны эчкәч, бакчага чыгып утыр.

— Әни, җирлеге зәңгәр булса, миңа ныграк килешер иде, минем күзләрем төсле...

— Син ниндине теләсәң, шундыйны алырмын, кызым.

— Әни, кирәкми, акчаңны әрәм итмә...

Бик еш ул стенага таба борылып ятты. Әнә шулай булды: Тәзкирәнең күңелен күренер-күренмәслек ышаныч чаткысы аз гына яктыртып торды да сүнде.

Әнә шундый күңелсез, сөремле көннәрнең берендә аларга кызларныкы кебек кечкенә борынлы, сипкелле, күзлекле бер шат егет керде. Аңа карасаң, елмаймыйча түзеп булмый иде. Егетнең өстендә шакмаклы пиджак, ап-ак күлмәк, янып торган ачык галстук.

— Сәлам, иптәшләр!— диде ул кергәч.— Танышыйк: мин — Янтимеров. Исемем — Һади. Фамилиямә караганда исемемне ныграк яратам. Шулай булгач, аңларсыз инде.

— Сезгә кем кирәк?— диде Сорур апа, ачык егеткә сокланып карап.

— Барыгыз да. Мин яңа участок врачы.

— Врач? Ә теге...

— Аны, йомшак әйткәндә, кудылар. Мин сезнең өйдә авыручы кешеләр юктыр дип ышанам.

Сорур апа бер кызына, бер зифа гәүдәле врачка карап алды да:

— Аллага шөкер, икебез дә исән-сау,— диде.

— Бик яхшы. Тазалык — зур байлык, дигән борынгылар. Хушыгыз.

Врач шул чак, чынаяк кебек ак йөзле, зур зәңгәр күзле, алкаланып торган кара бөдрә чәчле Тәзкирәне күреп алды. «Нинди

матур... Анасы да кыз чакта шундый булгандыр».

— Гафу итегез, сезнең кызыгызмы?— Ул шыпырт кына сорады.— Хәле ничек?

Сорур апа ышанычлы итеп:

— Аллага шөкер, әйбәт,— диде һәм, инде йомшара төшеп,— утырыгыз, хәзер чәй хәзерлим, дип өстәде.

— Рәхмәт, кергән бер җирдә чәй эчеп китсәм, участокны бер тапкыр да әйләнеп чыга алмам,— диде. Ә үзе эчтән, тагын бер «утыр» дисә, бер самовар чәй эчәргә дә ризамын, дип уйлый иде. Ишекне ачкач, Һади чәчәкле халат кигән кызга тагын бер карады. «Нигә табигать бер кешегә шулчаклы матурлык биргән... Борынгы греклар матурлык идеалын, классик фигураны мәрмәрдә сынландырырга тырышканнар... Әгәр алар мондый кызны күргән булсалар, Венера Милосскаядан да гүзәлрәк статуя эшләп калдырган булырлар иде. Ә-әһ... матурлык кешегә нигә шулкадәр тиз һәм тирән тәэсир ясый соң. Һәм капыл аңа начар уй килде.— Их, нигә Сорур апа «кызымның хәле шәп түгел» дип әйтмәде икән. Мин аның янына иртә дә, кич тә, көндез дә, төнлә дә килер идем. Тын алганын, керфек какканын карап, баш очында утырыр идем... Их, врач... Оятсыз эскулап. Авыруларны дәвалаучы имеш. Син бит үзең чир чакырасың... Бар, бар тизрәк чыгып кит, сине сәламәт кешеләр түгел, авырулар өметләнеп көтә».

Врач чыгып киткәч, Тәзкирә гаҗәпләнеп анасыннан сорады:

— Нигә аны алдадың, әни? Әллә минем хәлем...

— Ярар, әллә ни уйлама. Хәзер бер врачны да якын китермим. Берсенең дә сүзен тыңламыйм. Абдулла абыйны гына тыңлыйм.

Ләкин врач сумкасы урынына ике йозаклы зур күн портфель тотып, Һади икенче көнне үк килеп җитте.

Сорур апа сагайды: «Әллә ул врач дип алдашып йөри микән? Әллә... Документын сорасаң инде...» Юк, сорый алмады, кыенсынды. Ул мөмкин чаклы ачык һәм... салкын булырга тырышты. Ә врач әллә моны сизмәде, әллә белдермәде. Ул гамьсез сөйләнде дә сөйләнде.

— Ике-өч көн саен участокны әйләнеп чыгарга кушалар. Дөрес, участок кызык түгел. Авырулар юк. Безнең халык бит ул мәзәк. Мәсәлән, бер врач каты авыруны карагач, коллегасына, бүген миндә бик кызыклы авыру булды, дип сөйли. Ләкин минем участокның «кызыклы» булмавына исем китми. Ни чаклы авырулар аз булса, шулчаклы сезгә һәм безгә рәхәт. Бөек физиолог Мечников шулай дигән...

Тәзкирә яшереп кенә, «юл уңаенда» гына аңа сирпеп карады һәм нигәдер кып-кызыл булды: ул шундый ямьсез һәм шундый сөйкемле иде.

Ана күңеле нидер сизенеп капыл йомшарды.

— Утырыгыз. Чәй эчәрбез.

— Рәхмәт. Миңа китәргә вакыт. Менә шул Мечников шулай дигән...

— Эчкәч рәхмәт әйтерсең. Утыр, утыр, кичә дә эчмәдең.

Һадига шул гына кирәк иде. Ул күзлеген салып сөртте. Тәзкирә аның кара гәрәбә төсле күзләренә карап алды. Күзләр, күзләр... Бер карасаң, бөтен кешедә дә бер төсле күз бит: я кара, я зәңгәр, я соры, я коңгырт... Ә җентекләп карасаң, һәр кешедә фәкать үзенә генә хас, кабатланмаслык күз була. Һадиның күзләре дә карап туймаслык матур һәм акыллы иде. Бер күрсәң, гомергә аларны онытa алмассың. Җәл, күзлек кия.

Һади көн саен сәгать өчтә «профилактика өчен» Сорур апаларга килде. Көн саен, Тәзкирәгә күтәрелеп карарга да кыймый, тирләп-пешеп чәй эчте. Сорур апа аның гамьсез, һәрвакыт елмаеп торучы йөзенә, пөхтә киеменә карап: «Күренеп тора, бәхетле, мул семьяда туып үскән бала»,— дип көнләшеп тә куйды.

— Ата-анаң бармы, Һади?

— Бар.

— Эшлиләрме?

— Эшлиләр...

— Кайда?

— Кайда?..

Һади чак чәчәмәде.

— Әтием инженер, әнием врач.

— Гаиләгез зурмы?

— Юк. Мин баш бала да, төпчек тә.

— Бәхетле җан,— Сорур апа аңа үз баласына карагандай сокланып карап торды.

Ә салкын чәй белән аз гына аска төшеп торган калын иренен чылатып утыручы Тәзкирә Һадига күтәрелеп тә карамады. Аның

күзләре уйчан иде. Ни уйлагандыр Тәзкирә, белүе кыен. Һади аңа берничә мәртәбә күзлеге аша карап алды, ләкин Тәзкирә моңа игътибар итмәде.

Һади урыныннан торды.

— Рәхмәт, Сорур апа, күптән шундый тәмле чәй эчкәнем юк иде.

— Сезнең халык кофе дә какао эчә бит,— диде Сорур апа, әллә кызыгып, әллә аны кызганып.

— Әйе, интеллигенция чәй яратмый ул. Тагы бер тапкыр рәхмәт сезгә. Хушыгыз.— Һади бөгелә-сыгыла рәхмәт әйтеп чыгып китте.

— Әни, әгәр ул тагы килсә, кертмә.

— Килешеп бетмәс бит. Ул шундый акыллы, ягымлы...

— Һәм мактанчык. Безнең институтта шундый бер тип бар. Роберт исемле.

Ә Һади, әйтмәсәң дә, килмәде. Атна, ун көн үтте... Тәзкирәне бу хәл аз гына да борчымады. Ләкин Һадиның гәрәбә кебек күзләре күз алдыннан китмәде.

«Нигә ул һаман килми? Килмәсен. Кирәге юк. Килсен. Бер генә. Юк, бер дә килмәсен. Кил... кил, бәгърем. Мин сине сагындым. Бик. Килеп кенә кара, куып чыгарырмын». Һәрбер яшь кыз йөрәге кебек, аның йөрәге дә каршылыклардан тора иде. Юк, ул Һадига гашыйк булмады. Аның кем беләндер юк-барны сөйләнеп, такылдап утырасы гына килде. Ә дуслары һаман совхоздан кайтмый. Сау-сәламәт булса, ул Һадины урамда искә алмый үтеп китәр иде. Ә хәзер...

Шул, әлеге дә баягы тел... Әшне хур итүче дә тел, эшне хөр итүче дә тел. Ул кайчак әремнән дә ачырак, кайчак балдан да татлырак. Ашыгыч йомыш белән кергән күрше Хәсби апа сәгать ярым утырып чыкты. Башта өендәге, аннан соң урамдагы, тора-бара шәһәрдәге хәлләр турында сөйләнде. Хәтта Африкага да барып җитте.

— Ни, теге Египетның президенты кем әле... Әй, Египет дигәннән безнең яшь врач искә төште... Кызым булса, үзенә ике куллап бирер идем. Шундый матур, шундый акыллы... Ходай бирсә, бирә икән. Кичә үзенең янына барып килдем әле. Авырып ята, бичаракаем. Әллә бавыры, әллә бөере инде. Мин бит аларны юньләп аера алмыйм. Ашарына хәзерләп, керләрен юып кайттым.

— Йортта йөрүче кешеләре юкмыни?

— Һи-и... кайдан килгән ди. Алар бит ятимнәр. Аталары фронттан ранен булып кайткан да бер елдан үлгән. Ике елдан аналары вафат булган, Сорур апакай гынам. Дүрт малай — дүрт яшь имәнмени. Берсеннән-берсе матур, берсеннән-берсе акыллы. Кызларым булган булса... Ходай бирмәде шул. Сорур апакай гынам, мин нинди йомыш белән кергән идем әле? Ә, исемә төште...— Чыгарга дип ишек ачкач та әле ул ярты сәгатьләп телен чарлап торды.— Өс-башларын юучы, аш-су хәзерләүче әбиләре бар иде, ул да үткән атнада вафат булды. И-и... бу фани дөнья... Фани дигәннән, чәнчелеп китсен, төпчек улымның ботинкасын мастерскойга илтәсем бар икән. Ярый, чыгыйм әле. Кызына күз тимәсен, рәтләнә башлаган бит.

Хәсби апа чыгып киткәч, Тәзкирә урынынннан торып утырды: «Нигә Һади аларны алдый икән? Әллә Хәсби апа алдыймы? Әллә Һади Хәсби апаны юри өйрәтеп куйганмы? Юк, ул ятим балага охшамаган. Мөгаен, бәһасен арттырыр өчен ул Хәсби апаны юри котырткандыр». Ә Һади ике атна буе аларга килмәде. Һәм ике атна буе Тәзкирәне шикләнү-икеләнү борчыды. «Бәлки ул чынлап та чирлидер. Бәлки аңа җылы аш пешереп ашатучы да юктыр. Хәсби апа көн саен бара алмый, үзенең мәшәкате дә башыннан ашкан. Әни... әллә син...» Юк, ул анасына әйтергә батырчылык итмәде. Һәм менә ишекне ачканчы ук сөйләнә-сөйләнә Һади килеп керде. Ул элеккечә шат, гамьсез иде. Тик чырае гына качкан.

— Тәмле чәегезне эчәргә килдем, Сорур апа. Исән-сау гына торасызмы? Ачуланмагыз, мин сезгә кечкенә генә күчтәнәч алып килдем. Монысы сезгә, Сорур апа, ә монысы, ачуланмасагыз, сезгә, Тәзкирә!

Беренче тапкыр аларның күзләре очраштылар. Ә күзләр очрашып бер-берсен аңлашса, башка нәрсә кирәк инде...

Тәзкирә: «Терелдеңме, Һади?»— дип сорамакчы булган иде, Сорур апа күз кысты.

— Күренми башладың, Һади, үзеңне сагынып беттек.

— Авылга, бәрәңге алырга җибәрделәр.

— Ничек соң, быел бәрәңге шәпме?— дип сорады Сорур апа, ышанган булып.

— Шә-әп. Гектарыннан мең поттан ким чыкмый.

Капыл Тәзкирә кычкырып көлеп җибәрде. Борынгы сәгатьнең агач күкесе түгәрәк ишектән чыгып өч тапкыр кычкырды. Сорур апа элек күп көләсең, ирләр кебек көләсең, дип кызын шелтәли торган иде. Ә менә хәзер аның күзеннән яшьләр атылып чыкты. Тәзкирәнең күптән шулай ихлас көлгәне юк иде. «Аллага шөкер, аллага шөкер», дип пышылдады ул. Ә Һадиның йөрәге «келт» итеп китте, колак яфракларына күренер-күренмәслек тир чыкты. Әмма ул моны сиздермәскә тырышып гамьсез сорады:

— Нигә көлдегез, Тәзкирә?

— Былтыр булган бер хәл исемә төште.

— Мин әллә миннән көлдегезме дип торам... Сорур апа, әйт әле, шундый тәмле чәйне сез ничек әзерлисез? Рецебе сер түгелме?

— Әниең килсә, өйрәтермен.

— Ул... ул Сочида.

— Кайткач, син аны безгә алып кил.

Һади ашыкты, каушады һәм урыныннан торды:

— Ярый, исән-сау булып торыгыз. Участок зур.

Һади чыгып киткәч, Тәзкирә анасын янына чакырып алды, аның вакытсыз агарган йомшак чәченнән сыйпады.

— Әни, син нигә бая күз кыстың? Мин аны кызык итмәкче идем.

— Кирәкми, кызым. Үзенә ничек ошый, шулай сөйләшсен.

— Ә нигә ул гел алдаша?

— Белмим. Бәлки аңа шулай ошыйдыр, бәлки... Белмим, кызым.

— Әни...
— Әйе...
— Ярар инде...
— Минем барып кайтасы җирем бар. Син күңелсезләнеп, борчылып ятма, кызым. Әнә Һадидан үрнәк ал.

Тәзкирә ялгыз калгач Һади турында бик озак уйланып ятты һәм елмайган килеш йоклап китте. Сорур апа, кызының елмаеп йоклаганын күреп, өч айга беренче тапкыр шатлыгыннан елады.

Икенче көнне Тәзкирә иртүк торды, ашыкмый, көзгегә бик еш карый-карый киенде дә: «Әни, мин дус кызларым янына барам»,— дип чыгып китте.

Юк, Тәзкирә дус кызлары янына китмәде. Ул Хәсби ападан Һадиның адресын белде; магазиннан ике кисәк кер сабыны, бер әчмухә Һиндстан чәе сатып алып, Һадиларга юл тотты. Ярсый-ярсый өченче катка күтәрелде дә, ишек кагарга кыенсынып, йөгерә-йөгерә аска төшеп китте. Урамның икенче ягына чыгып, ул Һадиларның тәрәзәсен табарга тырышты. Бу көнне ул, Һадиларга керергә кыймый, өйләренә кайтып китте. «Иртәгә оялып тормыйм, керәм. Керсә, ни гаеп? Кайткач, әниемә сөйлим дә бирәм. Килешми. Нигә? Кызлар янына егетләр килсә гаеп түгел, ә менә кызлар егетләр янына барса — гаеп. Кызык кына. Барыбер түгелмени соң? Ул бит әллә ни уйлап бармый... Ни чаклы үзен тәвәккәл итәргә тырышмасын, Тәзкирәнең икенче, өченче көнне дә Һадиларның ишеген кагарга кыюлыгы җитмәде.

Тәзкирә шулай озак йөрер иде микән — билгесез. Көннәрнең берендә Һади аны үзләренең ишек төбендә очратты. Һадиның гамьсез йөзе капыл җитдиләнде, тавышы калтыранды.

— Тәзкирә... Безгә килдегезме?

— Юк. Әллә бу сезнең квартирагызмы?

— Әйе. Менә, алтынчы номер.

— Ә-ә... Мин дус кызым янына килгән идем дә, өйдә юк икән.

— Дус кызыгыз янына? Бу катта кызлар юк.

Тәзкирә ничек тә судан коры чыгарга тырышты.

— Һи-и, бу өченче катмыни? Мин икенче дип торам.

— Тәзкирә, әйдә безгә керәбез.

— Юк... Рәхмәт. Мин... ата-анаңнан оялам.

— Алар бит өйдә юк.

— Сочидамыни?

— Юк, еракларак. Алар бөтенләй юк...

— Беләм...

— Беләсез? Кем әйтте?

— Мин барысын да беләм, Һади...

— Тәзкирә...

— Һади, сез нигә безне алдадыгыз?

Һади елмайды. Аның бу елмаюында сагыш та, мәхәббәт тә бар иде.

— Әгәр мин сезгә әти-әнисез, дүрт малай гына яшибез, дисәм, сезнең әниегез көяләнә башлар иде. Ә нигә аны юкка көяләндерергә? Ул бит болай да үз гомерендә бик күп кичергән.

Тәзкирә чак-чак аны кочаклап үпмәде.

— Нинди яхшы кеше син, Һади...

— Яхшы буласы килә, Тәзкирә. Бик яхшы. Ләкин әле булып булмый. Яхшы булуы, күрәсең, җиңел түгелдер. Безгә кирәбезме?

Тәзкирә ризалык белгертеп елмайды.

Һади ике йодрыклап ишекне кага башлады.

— Әй, малайлар!..

Ишекне чәче-башы тузган, уникe, унөч яшьлек малай ачты. Аның бите, куллары кара майга буялып беткән иде. Ә өстәлдә, урындыкларда радиоприемник частьлары ята.

— Таныш булыгыз,— диде Һади театрально кулын сузып:— минем иң кече энем: фантазер һәм фанатик. Инде өч радиоприемник ясады. Ләкин әле берсе дә Марсны тота алмый. Һәй, малай, исәнләшергә кулыңны сузганчы, кырык кат сабынлап ю! Без менә шушында торабыз инде, Тәзкирә... Әй, малай, кунакка урын бир.

Бүлмә ничаклы җыйнак һәм таза булмасын, хатын-кыз кулының җитмәгәнлеге ишектән кергәч тә сизелеп тора иде.

Шушы көннән алып Тәзкирә көн саен «дус кызлары» янына барды. Көн саен иртән үк көзгегә еш карый-карый киенде, авыз эченнән генә җырлады, элекке кебек кычкырып, ихлас көлде. Башта аны «буйдакларны» җәлләү, хәстәрлек тартты. Ул көн саен аларның бүлмәсенә һәм ашына яңалык кертергә тырышты. «Домоводство», «Йорт энциклопедия»ләрен укыды, ә тора-бара... анысы инде безнең эш түгел. Сорур апа профессорга рәхмәт әйтеп туймады, даруы килеште, кызым аякка басты, аллага шөкер, дип сөенде ул. Ә бит профессор

калдырган дару водопроводтан агызган коры су гына иде. Һади исә Абдулла абыйның приказын үтәп йөрде. Дөрес, ул профессорның приказын арттырып үтәде. Соң планны арттырып үтәгән өчен кемне әрлиләр...

Биектән, бик биектән, зәңгәр язгы күктән дәртле аваз ишетелә: «Торрыйк-торрыйк».Ерактан, бик ерактан Африка ярларыннан торналар бала чыгарып үстерер өчен Уралга киләләр. Алдан иң көчле, иң тәҗрибәле торна-вожатый һава ярып бара. Арыса, аны икенче торна алыштыра, ә ул иң артка күчә.

— Хуш килдегез, — ди эшләпәсен болгап, самшит таяклы озын буйлы кеше һәм Агыйдел яры башында җитәкләшеп торган егет белән кызга сокланып та, көнләшеп тә карый. Язгы йомшак җил аларның чәчләрен тарый...

— Тәзкирә... Рәхмәт, бәгърем. Син миңа көч, дәрт бирдең.

— Ә син минем йөрәгемә канат куйдың, Һади...

— Канат... Ә кеше дөньяда иң канатлы җан иясе ул...

Агыйдел, гашыйк булган кешеләрнең хисләре кебек, ташып, ярларыннан чыгып ага. Зәңгәр күктән очучы ике чатлы торналар төркеменең күренер-күренмәслек шәүләсе суга төшә.

«Торрыйк-торрыйк...»

— Нинди биек очалар. Тавышлары чак-чак ишетелә. Яратам биек очкан кошларны.

— Һәм кешеләрнеме?..

«Торрыйк-торрыйк...»

ДУСЫМ КИЛДЕ БҮГЕН ЯНЫМА

(Нәсер)

Йокы алмый...

Йоклый алмыйм...

Йокым кайдадыр адашып йөри. Ә уйларым, картая һәм арый белмәүче уйларым, иярсез атсыман, дөнья гизә. Минем гомер юлларымнан һәм сукмакларыннан сәяхәт ясый.

Йоклап булмый...

Бүген туган илем, туган җирем 16 тапкыр җиңү көнен бәйрәм итте. Зәңгәр, төпсез май күгенә 16 тапкыр халкымның шөһрәте һәм кодрәте булып җиңү салюты ургылды. 16 салют... Ә мин ул чәчәкләр фонтанына сокланып һәм сагышланып карыйм, чөнки янымда син юк. Син аны карый алмыйсың. Ә без бит аны ел саен бергәләп карарга дип хатлар аша сүз куешкан идек, ләкин ел саен мин аны ялгызым карыйм. Мин бит синең кабереңнең кайда икәнлеген дә белмим, сабакташым, окопташым.

Йокысыз күзләремне ачам һәм каршыма син килеп басасың. Бит очларыңны чокырайтып елмаясың, тавышсыз гына көләсең. Мин торып утырам.

...Дускай, хәтерлисеңме? Әлбәттә, хәтерлисең. Синең хәтерең минекеннән шәбрәк иде

бит. Без бер-беребезнең беләкләреннән тотып, кан тибешләребезне саный идек. Синең йөрәгең һәрвакыт минекеннән ашыгыбрак тибә торган иде.

Хәтерлисеңме? Әлбәттә, хәтерлисең. Кем озаграк күзен йоммый дип без бер-беребезнең күзләренә текәшеп карап тора торган идек. Синең күзләрең бүгенге май күгедәй күк һәм җылы иде.

Без бер урамда туып, бер чишмә суын эчеп үстек һәм бер урам кызларына беренче тапкыр гашыйк булдык. Без икәүләп аркаларга берәр капчык арыш сохарие асып, сай чалбар кесәләренә унар тәңкә акча салып, Уфага бергә килдек һәм тау башындагы зур шәһәрдә безнең юллар аерылыштылар да, уч төбендәге сызыклар кебек, башка очрашмадылар. Хатлар гына безнең йөрәкләребезнең җылысын бер-беребезгә китереп торды.

Армиядә икенче ел хезмәт иткәндә очрашу айларын, көннәрен саный-саный ярсып көттек һәм көтеп ала алмадык. Сәгатьләп якынайган көн кинәт упкынга төшеп китте. Ул упкын фашист бомбасыннан хасыйл булган иде.

Соңгы хатыңны син эшелонда язгансың. Ул хатны мин югалттым, әмма аның сүзләре, ташка казып язган кебек, минем йөрәгемдә.

«Дускай! Мин бу көнне көткән идем һәм бу көнгә гомерем буе әзерләнгән идем. Чөнки фашизм ул — сугыш. Ә сугыш ул — җимерү, үлем. Мин үләрмен, гомерем ярты юлда өзелеп калыр, дип курыкмыйм һәм үкенмим. Яши белгән кебек, үлә белсәм дә ярар иде. Соңгы сулышны алганда калтырамасам ярар иде. Үтенәм: кем исән кала, шул икебез өчен дә

яши. Икебез өчен дә эшләргә, икебез өчен дә көрәшергә, икебез өчен дә яратырга. Үтенәм: юк-барга көчеңне әрәм-шәрәм итеп вакланма, ваклама. Йөрәгеңне һәм башыңны югары тот. Тормышың җыр кебек булсын...»

Менә унсигез ел инде мин синнән башка яшим. Ә бит без аерылышканда безгә дә унсигез генә яшь иде... Мин әле уларга җыенмыйм. Өлгерермен. Ләкин язын да, көзен дә, кышын да, җәен дә һавада озон исе белән бергә дары һәм атом бомбасының дәһшәтле исе борынга керә. Җир шарының әле бер, әле икенче почмагында сугыш ялкыны күренеп кала. Әмма без беркайчан да сугышны кәсеп яки күңелле эш дип санамадык. Сугыш безнең өчен иң явыз дошман. Безнең барлык исебез-уебыз, сугышны юк итеп, тату яшәүдә. Шулай булгач, бәлки улларыма мылтык тотарга туры килмәс тә. Ләкин кемгә булса да, улларымның улларынамы, «Интернационал»дагы припевның беренче ике юлын җырларга туры килер. Ышан, еракта калган дусым, кайтмаска киткән урамдашым, коралдашым! Ул җырны синең өчен дә җырларлар.

Йокы алмый. Инде май таңы ата. Мин синең язмышың, үземнең һәм балаларымның, Туган илемнең һәм Туган җиремнең язмышы турында уйлыйм.

Йокы алмый. Таң ата. Май таңы. Бәхетлеләр таңы.

ГАҖӘЕП ТӨШ КҮРДЕМ МИН БҮГЕН...

Имеш, миңа егерме яшь тулган икән. Имеш, мин беренче тапкыр «яратам» сүзен әйтергә җыенам икән.

Әйтә алмадым шул, хатынкай уятты.

— Атасы... тор. Телефонга чакыралар.

Мин татлы йокымны, матур төшемне бүлүче «таң сандугачы»на сукрана-сукрана трубканы алдым...

— Тыңлыйм...

— Котлыйм, дускай. Бәйрәм белән!

— Бәйрәм белән?! — Мин, трубканы учым белән каплап, хатынымны чакырдым. — Кил әле, кил. Бүген нинди бәйрәм?

Хатыным авызын ера. Җитмәсә телефоннан да көлгән тавыш ишетелә.

— Оныттыңмыни, дускай, бүген сиңа кырык тулды бит.

— Юк. Нишләп үземнең туган көнемне онытыйм инде, — дигән булам.

Ә дөресен әйткәндә, оныткан идем. Менә гел шулай. «Быел туган көнне искә алырга кирәк әле», дип алдан уйлап йөрим дә көне килеп җиткәч истән чыга да китә.

Кырык яшь...

Мин тугач, кырык тапкыр шомырт чәчәк аткан, кырык тапкыр кошлар җылы яктан килеп киткән.

Мин тугач, кырык тапкыр яңа ел карлары яуган һәм шул карларны тишеп кырык тапкыр умырзаялар баш калкыткан...

Кырык яшь...

Мин тугач, җир мине утыртып кырык тапкыр кояшны әйләнеп чыккан.

Шатлыклы да, сагышлы да көн. Шул ягы белән шатлыклы: син кырык ел буе кояш чыкканны, чишмәләр акканны күргәнсең; кырык ел буе күк күкрәгәнне, кошлар сайраганны ишеткәнсең, сагышлы шул ягы белән: яшәгән чаклы инде яши алмаячаксың. Яшәсәң дә, икенче кырык ел бөтенләй икенче булачак.

Кырык яшь...

Шулай ук булды микәнни?..

Булгандыр да шул. Маңгаемда чирәм ертып үткән сабан эзләре кебек борылмалы буразналар ята, кара чәчләремне төртеп, ак бөртекләр баш калкыта.

Кызлар да, элекке шикелле, елмаеп карамый, ә игътибарсыз караш белән генә үтеп китә. Кырык тулгандыр да шул...

Ә төшемдә миңа ни бары егерме яшь кенә иде. Нинди мәгънәсез төш. Юк, нинди мәгънәсез өн.

Ә кайчан, кайда миңа егерме тулган иде әле?

Тбилисидә. Армиядә. Ул көнне без авыр походта булдык. Кичен кино карадык. «Зур вальс» дигән фильм. Иоһанн Штраус турында.

Хәтерлим. Энәсеннән-җебенә чаклы хәтерлим. Штраус Вена урманыннан сандугачларга кушылып җырлап барганда, минем йөрәгем «келт» итеп китте. «Чү! Бүген бит миңа 20 тулды лабаса!..»

Мин Штраусны сөйгәне белән Вена урманында калдырып чыгып киттем.

Тышта җиләс Грузия төне иде. Кара-кучкыл зәңгәр көньяк күге җылы һәм йолдызларга бай иде.

Мин, устав таләпләрен оңытып, кулларымны чалбар кесәсенә тыгып, лагерь буйлап йөрдем. Һәрнәрсә: йолдызлар, агачлар, хәтта телеграмм баганалары да: «Сиңа егерме яшь. Егерме яшь сиңа»,— дип дәртле җыр җырлый иде. Мин дә юк тавышымны бар итеп аларга кушылып җырлыйм: «Бүген егерме тулды миңа, егерме...»

Егерме яшь.

Яшьлекнең җитлеккән, гомернең чәчәк аткан чагы... Ә яңадан шулчаклы яшәп булырмы? Нигә булмасын... Кырык яшь бит ул... Шаярма. Күктә болытлар көннән-көн куера бит. Фашизм, тәртәләрен сындырып, авызлыгын өзеп дулаган ат кебек, котырына. Ә сугыш яшьләрне аеруча ярата, дөресрәге, яратмый. Димәк, алда безне яшәлмәгән гомер генә түгел, казылмаган окоплар һәм каберләр көтә...

Җиңдек. Барысын да. Авыр сугышны да, авыр елларны да. Инде без казыган окоплар җир белән тигезләнгән, без аткан патроннарның гильзалары тутыгып черегән...

Һәм менә миңа янә бер егерме өстәлде.

Көндезге шау-шулар тынгач, без кичен

дүртәүләп: хатыным, ике улым — ике кулым урамга чыктык һәм... бу нәрсә, язмышның шаяруымы, әллә алла бармы? Кинотеатрлар «Зур вальс»ны күрсәтәләр.

Кердек. Карадык.

Шул ук Штраус...

Шул ук Вена урманы...

Шул ук Зәңгәр Дунай...

Бернәрсә үзгәрмәгән, бернәрсә картаймаган: җыр да, табигать тә... Тик миңа гына янә бер егерме өстәлде.

Төнге урамнан кайтабыз. Ерак күктәге сирәк-мирәк йолдызлар салкыннан калтыраналар, тротуарга саргайган яфраклар тавышсыз гына өзелеп төшә. Көзге җил исә һәм мине ирештерә: «Сиңа инде хәзер кырык яшь, абзый, кырык. Яшеңне онытып, уңга-сулга каранма, абзый, сиңа хәзер егерме түгел, кырык».

Мин бирешмәскә тырышам: «Булсани. Кырык яшь ирләрнең чәчәк кебек чагы ул».

Ә җил һаман үчекли:

«Чәчәккә кошлар куна. Ә сиңа? Чәчәктән умарта кортлары бал җыя. Ә синнән?»

Җил мине җиңә, мин башымны иям. Шушы вакыт минем зур улым Штрауcның «Вена урманы әкиятен» сызгырырга тотына. Кинәт мин әллә нишләп китәм. Чигәмә көчле кан ташуы ургыла. Күз иярмәслек арада тирә-як танымаслык булып үзгәрә: агачлар яфрак коймый, ә яңа яфрак яра, йолдызлар өшеп калтыранмый, ә күз кысып шаяра.

Мин ике кулымны ике улымның җилкәсенә куям һәм без өчәүләп «Вена урманы әкиятен» сызгыра башлыйбыз. Ә ягымлы, җылы җил

минем чәчләрем белән уйный һәм: «Сиңа кырык түгел. Түгел. Сиңа ни бары ике тапкыр егерме генә әле», — дип юата.

Гаҗәеп, юк, сокландыргыч төш күрдем мин бүген.

Егерме ел үткәч янә кабатлансын иде ул төшем һәм шушы өнем.

БАЛЫК ТОТКАНДА

Хатыным белән кара-каршы утырып, чынаякка өрә-өрә чәй эчәбез.

— Өф, өф-ф... Нигәдер Низами кияүдән, өф, өф... хат-хәбәр юк әле, Шиһаб.

— Өф, өф-ф... Сочига курортка киткәндер. Өф-ф, начальство Кавказга йөрергә ярата бит, Зөбәрҗәт.

— Ә безнең авыл Кавказдан киммени? Бер ягында тау, икенче ягында наратлык, өченче якта Агыйдел.

— Начальствога Агыйдел генә җитми шул, хатынкай. Аларга диңгез кирәк. Өф-өф-ф...

Без матур итеп, җайлап кына сүз көрәштерә башлауга, капка төбенә чия төсендәге «Победа» килеп туктады. Хатынкай уйлап-нитеп тормады: «Уфадан килделәр», — дип кычкырып та җибәрде. Гомумән, минем хатынның мәрәкә ягы бар: ул иң элек әйтә, аннан уйлый.

— Бәлки Бәләбәйдәндер, — дидем мин, өстемә пинжәк кия-кия.

— Юк, Уфадан. Күңелем сизә.

Ах шул хатыннарның күңеле: белсә дә сизә, белмәсә дә...

Без бәхәсләшә-бәхәсләшә ишек алдына чыкканчы, кунаклар өйгә килеп тә керде.

— Миллионер Шиһаб каенагага һәм аның гадел хатыны Зөбәрҗәт җиңгигә Уфа егетләреннән...

Дүртесе берьюлы: «Сәлам!» — дип кычкырды.

— Бу егетләрнең егетләре егет булганнар инде, — диде сүз көрәштерергә яратучы Зөбәрҗәт. — Рәхим итегез, мактап йөрисез икән.

— Сезне дә мактамагач, кемне мактарга соң, җиңги, җиңгәчәй, синнән шикәр, миннән чәй.

— Хатыннарыгыз кайда, кияү?

— Их, җиңги... Тулага самовар төяп бара-лармыни... — Низами өй яңгыратып көлде. — Иптәшләр, түргә узыгыз. Югыйсә, алар кунакны ишек төбеннән уздырмыйлар... — Низами иптәшләренә күз кысты да, мине култыклап, читкәрәк алып китте.

— Каенага, ачуланмыйсыңмы?

— Ачуланам, кияү.

— Нигә?

— Хәбәрсез-нисез киләләрмени. Магазинда юньле аракы да юк.

— Төкер аракысына. Сунарга киттек. Агыйдел буена. Ямьле Агыйдел буйлары, бетерәдер хәсрәтне, уйларны... Давай, хәзерлән.

— Син күңелләләнеп тә алгансың, кияү.

— Юлда бер кызга гашыйк булдым. Их... — Низаминың көлүенә өстәлдәге чынаяклар чыелдады. — Ял иткәндә кеше дөньясын онытырга тиеш. Тал бөгелә, тал бөгелә, матур бөгелүләре...

— Кияү, юлдашларың кемнәр?

— Кешеләр.

— Ә теге юаны, күзлеклесе?
— Безнең хуҗа.
— Министрмы?
— С-с-с...
«Их, мин уйлыйм, җай китереп, министрдан электр җиһазлары сорарга. Югыйсә, закон, наряд буенча тиз генә алып булмаячак». Мин хәйлә-капкын корам. Ә хатынымның үз кайгысы. Алар бит эштә, укуда сынатудан курыкмыйлар, әмма өйдә, аш-су янында хур булу алар өчен үлем белән бер. Минем Зөбәрҗәтнең дә аяклары җиргә тими, кулларына күз иярми.
— Аш ашатмый бер җиргә дә җибәрмим.
Борыны, күзләре белән Кавказ халкына охшаган Давыт исемле кеше минем хатыным алдына басты да ике учын бергә кушып ияге астына куйды.
— Зөбәрҗәт ханым, сезнең якты йөзегез, татлы сүзегез любой аштан да тәмлерәк. Рәхмәт.
Тиз генә җиңәрсең хатыннарны.
— Ашагач рәхмәт әйтерсез.
— Без бая гына ашадык.
— Аш ашка, урыны башка.
Үзен Әсгать Хөсәенович дип таныштырган шактый юан, шактый озын, күзлекле кеше, старшина кебек, команда бирде.
— Зөбәрҗәт ханымның сүзе — закон. Башта тавык шулпасы авыз итәбез, аннары сунарга.
Ике сәгатьтән без ике «Победа»да Агыйдел буена сыптырдык. Чия төсендәге машинаны Низами алып бара, ә минекенә Давыт һәм Әсгать Хөсәенович утырды. Мин аны шу-

лай эшләдем, әмма министр минем янга түгел, артка утырды.

Давыт бер генә минутка да тукталмый сөйләнде, көлдерде, төрле тавыш белән көлде, матур хатын-кызлар очраса, машинаны туктатырга кушып ялынды, бер җырны башлады, икенчесен ташлады. Ә Әсгать Хөсәенович аскы иренен салындырган, башын артка ташлаган — онытылып утыра.

Ни генә димә, министр булып эшләве уен түгел, арыгандыр. Тик һаман озын Давыт тынмый:

— Давыт, акрынрак, —дип мин аның җиңеннән тартып алам.— Иптәш йокларга тели.

— Йокы өчен төн бар, — дип көлде дә Давыт чирәм җирләрнең уңышы турында такмак җырларга тотынды.

Моны бажа янына очырсаң инде, дип уйлыйм — алар икесе дә пар килгән — лыгырдыклар. Машинаны туктатам. «Мотор шаяра, кызды ахры» дигән булам. Ул арада озын Давыт машинадан ялт итеп чыга да капотны ача.

— Юк, юк, — мин әйтәм. — Үз машинама мин беркемнең дә кулын тыктырмыйм. Үзем рәтләрмен. Ә сез бәлки Низами янына күчеп утырырсыз.

Тыңлады. Күчте. Кузгалдык.

— Яхшы, Әсгать Хөсәенович.

— Яхшы булса, яхшы, — ди Әсгать Хөсәенович һәм тына. Агыйдел буена барып җиткәнче ул иренен дә кыймылдатмады. Күзләрен йомып, әллә уйланды, әллә йоклады.

Яр буена барып туктарга өлгермәдек, юлда ук чишенә-чишенә килгән озын Давыт машинадан атылып чыкты да суга сикерде.

— Э-эһ... Ай-й, рәхәт... У-у... Әсгать Хөсәенович, нигә чишенмисең? Су май кебек... А-аһ-һ...

Әсгать Хөсәенович башта чалбарының балакларын кайтарып куйды, иплән кенә яр буена барды, чәнчә бармагын суга тыгып бутады.

— О-о... салкын.

— Әй... Низами, әйдә Агыйделнең теге ягына чыгабыз.

— Киттек... Агыйделне иңләп-буйлап, йөзәрсең, үрдәккәем...

Кечкенә гәүдәле, очлы сакаллы, кызларныкы кебек матур кечкенә борынлы Сафар калын тавыш белән көлде.

— Һо-һо-һо, абзыең җиде ел диңгездә йөзгән кеше. Һа-ап... Әйдә ярышабыз...

Мин хәзер, кияү әйтмәсә дә, кемнең кем икәнлегенә төшендем. Әсгать Хөсәенович — министр, бу җирән сакал — я аның ярдәмчесе, я бухгалтер, ә теге озын Давыт — шофер...

Озак кына уйланып торганнан соң, министр да чишенә башлады.

— Коенырга булдыгызмы, Әсгать Хөсәенович?

— Әйе, шундый карарга килдем.

Мин, йөзә белмәгән кеше кебек, ярдан читкә китми, министрны күзәтеп йөрдем. Кирәк була калса дип, багажниктан тәгәрмәч камерасы алып хәзерләп куйдым. Бераздан Низами, озын Давыт, Сафар абый өшеп, арып судан чыкты.

— Хуҗа, давай безне җылыт әле.

Министр, хәзер чәй кайнап чыга, диде.

— Һы... Чәй... Шиһаб, катырак чәең юкмы?

— Барлыкка бар да, кызыл баш кына.

— Миңа димәгәе яшел баш булсын, давай, тизрәк ач. Әсгать Хөсәенович, син нигә безнең янга килмисең?

— Кызыл башлы аракыда купорос күп. Әллә инде коньяк булса...

Мин акланырга тотындым.

— Зинһар, гаепләмәгез, алдан белгән булсам...

Озын Давыт минем җиңемнән тартты.

— Гаеп үзе гаеп булган, Шиһаб. Давай, өйрәт, кайда балык яхшы каба?

— Низами, башла әле «Ямьле Агыйдел буйларын».

Министр каршы төште.

— Иптәшләр, үзебез балык тотарга килдек, үзебез шаулашабыз. Алай ярамый бит инде. Охотада да дисциплинаны онытырга ярамый.

Озын Давыт кул селтәде дә миңа баш какты:

— Киттек.

— Гафу ит, Давыт, мин кунакны ташлый алмыйм. Низами, Давытка балыклы урынны күрсәт.

Без Әсгать Хөсәенович белән яр буендагы ике таш өстенә менеп кунакладык. Унбиш минут, ярты сәгать, бер сәгать утырабыз, ә Әсгать Хөсәеновичның чиләге буп-буш. Нишлисең бит, балыкларны бергә җыеп, сез күбрәк министр кармагына эләгегез, дип ин-

структтаж ясап бумый. Мин кармакны салган саен я алабуга, я ташбаш килеп чыга, ә аның кармагы я буш була, я тамырга эләгеп өзелеп кала. Күреп торам, министр яна, көя. Ләкин сер бирми, аскы иренен салындырып, мышнап тик утыра.

Мин бер чиләк балык тотканчы, министр дүрт ташбаш эләктерде.

Ул арада мактанчык Давытның тавышы ишетелде .

— Ну, бүгенгә җитте. Киттек, егетләр.

Хәзер нишләргә? Ничек министрны хурлыктан коткарып калырга? Мин тиз генә ике чиләкне бер иттем дә, балык шулпасы пешерергә хәзерләнә башладым. Давыт бик мактана-мактана килгән иде, безнең балыкларны күргәч, авызы ябылды.

— Да-а...

Министр нидер әйтмәкче булган иде, мин әдәпле генә итеп аны бүлдердем.

— Сез шаулап балыкларны куркытмаган булсагыз, без ике чиләк тота идек.

— Да-а...

Балык шулпасы эчтек, җырладык, бәхәсләштек һәм эттәй арып, ятып йокладык. Таң атар алдыннан, йокының иң тәмле вакытында, мин иплэп кенә тордым да, озын Давыт чиләгендәге ике зур шамбаны ике чуртанга алмаштырып, министр чиләгенә салып куйдым.

Иртән балык тотып маташмадык, Әсгать Хөсәенович, баш авырта, температура бар, тизрәк кайтыйк, дип ашыктырды. Башкалар каршы килмәде. Өйгә кайткач та, министр төренеп ятып йоклады, ә мин кунаклар белән

басуларда йөрдем. Фермада булдык, колхозчыларның өйләренә кереп чыктык. Озын Давыт, күрәсең, авылда туып-үскәндер. Колхоз эшләрен ул яхшы белә, кызыксына, төпченә. Без урап кайтуга, министр минем хатыным белән карта уйнап утыра иде — димәк, терелгән.

— Хатынкаем, мин әйтәм, ашарга хәзерлә, — һәм әкрен генә өстим, — кучтәначкә бал җибәр. Күзлеклесенә күбрәк куй.

— Нигә авыз аерырга, барысына бертигез куям.

Гомерем эчендә беренче тапкыр хатынны алдадым.

— Аның ашказаны авырта, — мин әйтәм. — Даруга.

Хатыным килеште.

Кунакның килүе ни чаклы шатлык булмасын, аның китүе күңеллерәк бит. Менә шул күңелле минутлар да килеп җитте.

Хушлашабыз, андый вакытта әйтелә торган сүзләрне әйтәбез: «Тагын да килегез», «Гаепләштән булмасын», «Что сез, күп рәхмәт, үзегез гаепләп калмагыз», «Сәлам әйтегез» һәм башкалар.

Әсгать Хөсәенович минем пинжәгемнең якасыннан тота:

— Сезнең хатыныгыз электр җиһазлары житешми дип зарланып торды. Кайткач та база директоры белән сөйләшеп карармын... Ничек тә этмәлләрбез, дип уйлыйм.

Мин рәхмәт әйтергә дә өлгермәдем, ул резин трубкага өрде дә канистрдан машинага бензин агыза башлады.

Мин кияүне ымлап чакырдым.

— Кил әле, кил. Син нигә мине алдадың?

Кияүнең чәчләре үрә торды.

— Мин?.. Сине?

— Син Әсгатьне безнең хуҗа, дидең, ә ул нибары шофер.

Кияү бот чаба-чаба көлде:

— Әлбәттә, хуҗа. Әгәр ул чирләп китсә, без ни туды, ни сюды. Министр машина йөртә белә дә, правосы юк.

— Ә соң кайсысы министр?

— Иң шәбе.

— Теге озын Давытмы?

— Әйе. Иң гадие, иң акыллысы...

Кунакларның «Победа»сыннан соң күтәрелгән тузан бураны таралгач, үземне үзем әрләп, үземнән үзем оялып өйгә кердем.

«Соң ял иткәндә, кемнең министр, кемнең шофер икәнлеге мөһиммени?.. Соң су кергәндә без барыбыз да бер халык түгелмени?..»

Хатынга күтәрелеп карарга да кыймый, кара-каршы утырып чәй эчәбез.

— Өф, өф-ф... Зөбәрҗәт, кунакларның кайсысы министр иде, белдеңме?

— Нигә белмәскә, теге... Давыт исемлесе.

— Үзеннән сорадыңмы?

— Юк. Күңелем сизде. Әллә син белмәдең?

Хатынга ничек сер бирәсең инде.

— Минем өчен барысы да бер — кунаклар, — дип чирттерәм. Ә үзем салкын чәйгә өрәм. — Өф-өф-ф...

ИРЕМНЕ НИЧЕК АКЫЛГА УТЫРТТЫМ

Ирләрне мактарга ярамый ул — тиз бозылалар. Менә минем иремне, «Башкортстанны чарлап чыксаң да Ногман кебек кешене таба алмассың. Ногман абыйдан да уңган кеше юк ул — ни тотса, шул кулыннан килә», дип күзенә карап мактадылар-мактадылар да харап иттеләр.

Бәй, аек вакытта мәчедән дә юашрак кеше, эчеп алса, алмашына да китә: ни сөйләгәнен, ни кыланганын белми. Такмак әйтә-әйтә бии, җырлый, мин икенче Шаляпин булмасам да, Мәгафур Хисмәтуллиннан уздырыр идем, дип очына, Брянский фронтында миннән дә батыррак герой булмады, дип шапырына. Аның батырлыгы ташка үлчим инде, егет вакытында ике ел ярым минем белән йөреп, язылышмыйча үпмәде дә. Иртән үзенә кичен кыланганнарын әйтсәң, бернәрсә дә белмим, дип кул гына селти. Белмәгәч, нигә дүртенче каттан сикерми, нигә тәмәкесен авызына кабасы урынга, борынына тыкмый, — белә ул, башын юри диванага сала. Инде бу ирне нишләтергә? Бәй, бервакытны улыбыз үсеп җитәр, кызыбызны кияүгә бирербез. Ногман балаларының туенда да: «Мин икенче Хисмәтуллин, мин Брянский фронтының беренче герое булдым», дип очы-

на башласа, җир тишегенә кер дә кит. Кодалар кызарыр, килен көләр, кияүнең күңеле кителер.

Берсенә дә әйтми генә, психиатр дигән врачка бардым. Врач:

— Эчүен ташласа, барысы да бетәр, — ди.

Мин әйтәм:

— Ул болай да аракы белән дус түгел, бәйрәмнәрдә генә эчә.

Врач:

— Значит, бәйрәмдә дә эчәргә ярамый, — ди.

Мин әйтәм:

— Эчмәгән кеше юк: тавык та эчә, — дим.

Врач:

— Значит, нельзя, — ди.

Шулай, төнлә ят йортта йокысыннан уянгач ишек табалмый йөргән кунак кебек, уйларыма чумып, аптырап кайтып килгәндә, янагамны очраттым.

— Патефон алгансың икән, тегесен саттыгызмыни? — димен, кулындагы төргәккә күрсәтеп.

— Патефон түгел, җиңги, магнитофон, — ди янагам. — Улымның теле ачыла башлады. Кызыклы сүзләрен яза барырга кирәк.

— Шуннан аны нишләтәсең?

— Улым үсеп җиткәч, өйләнгәч, туенда теле ачылган вакытта сөйләнгән сүзләрен сөйләтәм.

— Китче. Тавышы шул гомер бозылмый сакланырмы?

— Кирәк икән, йөз, мең ел сакла — берни

булмый, — ди янагам. — Әйдә, безгә керик әле. Үзеңнең тавышыңны язып алам.

— Син минем тавышымны язма, әнә абыеңның җырлаганын яз, димен.

Янагам көлә:

— Соң ул бит сыер кебек кенә мөгри.

Түзмәдем, врачка нигә барганымны сөйләп бирдем. Янагам аз гына кашларын җимереп торды да шаркылдап көлеп җибәрде.

— Шаулама. Без аны акылга утыртабыз, — ди.

Күп тә үтмәде, яңа ел килеп җитте. Ә яңа елны каршылаганда кем эчми дә, кем азрак исерми инде. Барыбыз да эчәбез, әмма Ногман кебек кыланучылар сирәк буладыр. Кызып алгач, кунакларны стройга тезде, «смирно!» дип команда бирде дә тотынды Брянский фронтындагы батырлыклары турында сөйләргә. Түзсәң — түз, түзмәсәң — башыңны ал да чыгып кит. Икенче көнне иртән иpләп кенә тордым да магнитофонны ачып җибәрдем. Ирем башын юрган астыннан чыгармый гына:

— Хатынкай, радионы выключать ит әле, пажалуйста, — ди.

— Радио түгел ул, карт, магнитофон, — дим.

Ирем сикереп торды:

— Ул нинди магнитофон?

— Эчкән кешеләрнең кыланганнарын яза торган машина, — дим, аның каршысына басып.

— Хатынкай, зинһар, пажалуйста, туктат. Балаларның ишетүе бар.

— Алар кичә ишеттеләр инде.

— Кунаклар да ишеттеме?

— Ишетми, саңгырау кунаклар җыелмаган иде лә.

Картым коелды да төште.

— Хатынкай...

— Нәрсә?

— Зинһар, пажалуйста туктат. Мине газаплама.

— Ә син нигә мин әйткәндә туктамыйсың?

— Хатынкай, кайчан минем синең сүзеңнән чыкканым бар...

Ә мин магнитофонны ныграк ачып җибәрдем.

«...Смир-рно!.. Мин Брянский фронтының командующие булган кеше. Нигә көләсез? Командующий төрепкәсен көйрәткәнче, мин аның телефон трубкасын тотып тордым. Их, бар иде заманалар, командующий беләи безгә любой генерал честь бирә торган иде... Смелого пуля боится, смелого штык не берет... «Атасы, Ногман, чыгырдан чыгасың». — Хатынкай, демократияне кысма, хәзер андый заманалар тфью-фьют... бетте-китте... Әннием, кайтырмын, көт мине... Минем тавыш баритон... Юк, бас. Поль Робсон булып җырлыйммы? Вчера приснился мне чудный сон... О-о-о... яшь вакытта уку тигән булса, мин хәзер народный артист СССР булыр идем...»

Магнитофондагы Ногман ярты сәгатькә якын мактанды, шапырынды. Ә кроватьта башын кочаклап утырган Ногман миңа күтәрелеп карарга да кыймый, шабыр тиргә чумып утырды.

Менә шул көннән алып ирем акылга утырды.

———

ЭЧТӘЛЕК

Йолдызлар атыла (повесть) 3
Бер мәхәббәтнең язмышы (повесть) 71
Сандугачлар разъезды 131
Торналар биек оча 150
Дусым килде бүген яныма 177
Гаҗәеп төш күрдем мин бүген 180
Балык тотканда 185
Иремне ничек акылга утырттым 194

И. Абдуллин

ЗВЕЗДОПАД

(на татарском языке)

Редакторы *С. Сибгатуллина*

Тышлык художнигы *Л. Анисимов*

Художество редакторы *Б. Альменов*

Техник редакторы *Ә. Трофимова*

Корректоры *Ә. Хәлилова*

Наборга бирелде 23/XII-1963 ел. Басарга кул куелды 5/II-1964 ел. ПФ 08018. Кәгазь форматы 70 × 90¹/₃₂. Уч.-изд. табагы 6,98. Басма табак 6,25 (7,31). Заказ Е-465. Тираж 7000 экз. Бәясе 21 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең „Татполиграф“ типографиясе. Казан, Миславский ур., йорт № 9.

ӘДӘБИЯТ СӨЮЧЕЛӘР ИГЪТИБАРЫНА

Татарстан китап нәшрияты соңгы вакытта түбәндәге китапларны бастырып чыгарды:

Һади Такташ. Сайланма әсәрләр. Шигырь һәм поэмалар.

Муса Җәлил. Моабит дәфтәрләре. Шигырьләр.

Р. Гамзатов. Биектәге йолдызлар. Шигырьләр.

Мөхәммәт Гали. Сайланма әсәрләр. Пьеса һәм хикәяләр.

Нәби Дәүли. Юлда очрашулар. Шигырь һәм поэмалар.

Зыя Мансур. Ак розалар. Шигырьләр.

Р. Фәизов. Беренче адымнар. Хикәяләр.

Г. Хуҗиев. Яшәү мәгънәсе. Шигырьләр.

С. Сөләйманова. Кыр казлары. Шигырьләр.

ПРОВЕРЕНО
17 АВГ 2016

Бәясе 21 тиен

30242

ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
1964